Министерство образования и науки Российской Федерации
федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение
высшего профессионального образования
«Тобольская государственная социально-педагогическая академия
им. Д.И. Менделеева»

**Ф.С. САЙФУЛИНА, Л.Ф. ЗАМАЛИЕВА**

# УСТНОЕ НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

**ТОБОЛЬСК 2013**

УДК 800.87
ББК 81.05
С 12

Печатается по решению
кафедры филологического образования

Сайфулина Ф.С., Замалиева Л.Ф. Устное народное творчество: учебно-методическое пособие. – Тобольск: Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева, 2013. – 199 с.

Данное учебно-методическое пособие предназначено для студентов национальных отделений вузов, аспирантов, а также для широкого круга читателей, интересующихся проблемами развития и жанрового разнообразия татарского фольклора. Пособие содержит теоретические положения, задания и вопросы для подготовки к семинарским и практическим занятиям, а также образцы фольклорных жанров, собранные студентами Тобольской государственной социально-педагогической академии им.Д.И. Менделеева и Казанского (Приволжского) федерального университета во время фольклорной практики.

**Рецензенты:**
***Бакиров М.Х.*** – д.ф.н., профессор истории кафедры татарской литературы ИФИ Казанского (Приволжского) федерального университета
***Галямова Г.С.*** – к.ф.н., доцент Научно-образовательного центра «Лингва» ТюмГНГУ

*Работа выполнена в рамках финансирования долгосрочной целевой программы «Основные направления развития образования и науки Тюменской области» и конкурса научно-исследовательских проектов среди аспирантов, молодых ученых и научных коллективов федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего профессионального образования «Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева»*

© ТГСПА им. Д.И. Менделеева, 2013
© Сайфулина Ф.С., Замалиева Л.Ф., 2013

# КЕРЕШ

Фольклористиканың фән буларак формалашуы аерым халыкларның авыз иҗаты үрнәкләрен язмада теркәү һәм җыю эшчәнлегеннән башлана. Галимнәр бу өлкәдәге беренче тәҗрибәләр дип Ибн Фадланның Болгарга сәяхәте турындагы китабын (X йөз) һәм М.Кашгарыйның «Диване лөгат эт-төрк» (XI йөз) сүзлеген саныйлар. Бу чорлардан бирле татар фольклоры мирасын туплаган йөзләрчә җыентыклар басылды, күпсанлы фәнни хезмәтләр язылды.

Татар фольклоры әсәрләреннән махсус әзерләнгән һәм фәнни таләпләргә нигезләнеп төзелгән «Татар халык иҗаты» дип исемләнгән беренче антология 1951 елда дөнья күрә. Хәмит Ярминең татар фольклорына багышланган күләмле кереш мәкаләсе бирелгән, халык авыз иҗатының әкият, мәзәк, җыр, бәет, мәкаль-әйтемнәр, табышмак кебек төп жанрларын эченә алган әлеге антология 1954 елда яңадан басыла һәм күп еллар дәвамында югары уку йортларының филология факультетлары өчен уку әсбабы буларак кулланыла.

1967 елда Х.Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» дип аталган күләмле монографиясе басыла. Татар фольклористикасы тарихын яктырткан, әкият, бәет, җыр һәм башка жанрлар турында махсус мәкаләләр урын алган әлеге хезмәт тә югары уку йортлары, мәктәпләр өчен дәреслек вазифасын башкара.

Узган гасырның 70-80нче елларында Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторы галимнәре тарафыннан «Татар халык иҗаты» күптомлыгының 13 томы дөнья күрде. Татар фольклористикасының гаять зур казанышы булган әлеге хезмәтнең һәр томында аерым бер жанр үрнәкләре тупланган. Һәрберсендә әлеге жанрга багышланган күләмле фәнни кереш мәкалә, җыентыкның ахырларында җентекле аңлатмалар бирелә. Бу саллы хезмәт бүгенге көнгәчә халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр өчен бик бай чыганак булып тора.

Татар халык авыз иҗаты буенча югары уку йортлары өчен «Татар халык иҗаты» дип аталган беренче махсус дәреслек Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, фольклор галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Фатих Урманче тарафыннан язылып, 2002 елда басылып чыкты. 2004 елда автор филология фәннәре докторы, профессор Ким Миңнуллин белән бергә әлеге дәреслекнең хрестоматиясен дә әзерләп бастырды.

Ф.Урманче дәреслегенең методологик нигезен татар халык иҗатына халыкчанлык, милли-мифологик, тарихи һәм тарихи-этнографик яссылыктан якын килү тәшкил итә. Дәреслектә татар халык иҗаты аерым

тарихи чорларга бүлеп өйрәнелә. Шушы ук принциплар хрестоматиядә дә сакланган.

2008 елда татар фольклоры буенча күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы, дистә еллар дәвамында югары уку йортында «Халык авыз иҗаты» курсын укыткан Казан дәүләт университеты галиме, филология фәннәре докторы, профессор Марсель Бакиров «Татар фольклоры» дәреслеген бастырып чыгарды. Аның дәреслеге материалны аерым жанрларга бүлеп өйрәнү һәм бәян итү принцибына нигезләнеп төзелгән. Һәр жанр тоташы белән үзенә багышланган аерым бер бүлектә генә бирелә һәм аның чорларга бәйләнешле үзенчәлекләре, конкрет әсәрләре дә шул бүлек эчендә карала. Бу исә үз чиратында студентка яки укучыга һәр жанрны, бүленмичә, берьюлы үзләштерергә ярдәм итә.

Тәкъдим ителә торган укыту-методик ярдәмлеге авторлары соңгы елларда әлеге ике галимнең дәреслекләре белән укыталар һәм бу хезмәтне әзерләгәндә дә, беренче чиратта, аларның китапларына таяндылар.

Укыту-методик ярдәмлеге халык авыз иҗатын аерым жанрларларга бүлеп өйрәнүне күздә тота. Һәр тема буенча белешмә формасында мөһим теоретик төшенчәләр бирелә. Студентларга гамәли дәресләргә мөстәкыйль әзерләнү өчен сораулыклар бирелә. Һәр темадан соң төп һәм өстәмә әдәбият исемлеге тәкъдим ителә. Шул ук вакытта аерым темалар буенча махсус теоретик хезмәтләрнең яки фольклор әсәрләренең текстлары да тәкъдим ителде. Студентларга билгеле бер тема буенча гамәли дәрескә әзерләнгәндә материалларны төрле чыганаклардан эзләп торасы юк, әһәмиятле дип саналган текстлар ярдәмлектә тәкъдим ителде. Һәр тема янында төп һәм өстәмә әдәбият исемлеге, реферат һәм курс эше темалары да тәкъдим ителде.

Хезмәтнең тагын бер яңалыгы шунда, аерым темалар буенча бирелгән фольклор үрнәкләре соңгы елларда Казан дәүләт университеты, Тубыл дәүләт социаль-педагогик академиясе студентларының кыр фольклор практикасы вакытында тупланган һәм беренче тапкыр басыла. Бу студентларга Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче, аерым алганда, Себер татарлары фольклорының бүгенге яшәешен күзәтергә һәм чагыштырырга ярдәм итә.

Ярдәмлек соңгы елларда кабул ителгән Федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре буенча эшләнде.

## ТЕМА № 1. ФОЛЬКЛОР ҺӘМ АНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ. ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ ТАРИХЫ

Халык иҗаты ул- халык вәкилләре тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар буе халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә һәм шигъри әсәрләр җыелмасы. Халыкара практикада халык иҗатын билгеләү өчен фольклор атамасы да кулланыла. **Фольклор** сүзе 1846 елда галим Вильям Томс тарафыннан фәнгә кертелгән халыкара термин. Ул ике өлештән тора: folk – халык, lore – акыл, хикмәт дигәнне аңлата. Димәк, фольклор сүзен шартлы рәвештә халык акылы, халык хикмәте дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

XX гасыр башында бездә халык иҗатына карата *халык әдәбияты* термины кулланыла. Г.Тукай халык җырлары турында 1910 елда Шәрык клубында укыган лекциясен Халык әдәбияты дип атый. Әдәбият галиме Гали Рәхим 1914 елда Халык әдәбиятымызга бер караш дип аталган мәкаләсен бастыра. 20 еллар уртасыннан фольклор, 30 нчы еллардан халык иҗаты термины да әйләнешкә кереп китә. Фольклор терминына синоним буларак хәзер халык сүз сәнгате, халыкның поэтик иҗаты, халык авыз (тел) иҗаты атамалары да кулланыла.

Фольклорның төп үзенчәлекләренең берсе – ***аның телдән иҗат ителүе*** белән бәйле. Шуңа да без аны икенче төрле халыкның авыз иҗаты дип атыйбыз. Бу үзенчәлек бик борынгы, әле язу булмаган ук чорлардан килә. Ул вакытларда мифология һәм фольклор, халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүче бердәнбер иҗат төре буларак җәмгыять тормышында әһәмиятле роль уйнаган. Әмма бу һич кенә дә язу барлыкка килү белән фольклор юкка чыга икән дигән сүз түгел. Чөнки язма мәдәният башлангыч чорда үзе дә халык иҗатына таяна.

Г.Тукай үзенең “Халык әдәбияты” дип аталган лекциясендә халык иҗаты әсәрләренең иҗат ителүен туган тел берәмлекләренең барлыкка килүе белән бер үк типтагы күренеш дип саный. Моннан чыгып, халыкның туган теле яши икән, аның шигъри иҗаты- фольклоры да яши дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Халык авыз иҗатының мәкаль, әйтем, такмак, такмаза, кыска җыр, җор сүз, мәзәк кебек төрләренең тарихи язмышларында бу процесс бигрәк тә ачык күренә. Чөнки туган телне фольклорның күрсәтелгән төрләреннән тыш күз алдына да китереп булмый.

Халык иҗатының тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге – аның – ***күмәк, коллектив иҗат нәтиҗәсе*** булуында. Профессиональ сәнгать әсәрләреннән аермалы буларак, фольклор әсәрләрен иҗат итүдә, аларны камилләштереп халыкка таратуда бер генә түгел, бик күп кешеләр катнаша. Нәкъ менә шуның өчен дә ул халык иҗаты дип атала. Дөрес, фольклор әсәренең һәрберсен башта аерым бер кеше иҗат итә. Шушы

аерым кеше тарафыннан әйтелгән хикмәтле сүз, мәкаль, әйтем, кемдер иҗат иткән көй, җыр, бәет, ниндидер бер үзенчәлеге белән игътибарны җәлеп итсә, бу әсәр халык арасында тарала. Халык иҗаты әсәренең төп кыйммәте, барыннан да элек аның халык арасына таралуы белән бәйләнгән. Ә инде халык теленә кереп китү өчен, фольклор әсәре билгеле бер шигъри югарылыкка ия булырга тиеш. Бик борынгы чорлардан ук фольклор әсәрләрен иҗат итүдә, аларны халыкка таратуда җитәкчеләр - оста телле ыру яки кабилә башлыклары, чичәннәр, шаманнар зур роль уйнаганнар.

Халык иҗаты әсәрләренең тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге – аның ***вариантлылыгы.*** Фольклор әсәрләре телдән телгә, берәүдән икенчегә, өченчегә тапшырыла. Бу үзенчәлек бер үк әсәрнең бер үк вакытта берничә кеше телендә яшәргә мөмкин булуын күрсәтә. Шул ук вакытта фольклор әсәрләре халык күңелендә гасырлар дәвамында яши. Зур күләмле әсәрләрнең сүзен-сүзгә кабатлау мөмкин түгел. Шул сәбәпле халык телендә яшәү дәвамында бер үк әсәрнең аерым вариантлары һәм версияләре барлыкка килә. Халык авыз иҗаты әсәрләренең вариантлылыгы аларның иҗат ителүен, халык арасында яшәвен, таралу киңлеген өйрәнүдә бик җитди роль уйный.

Фольклорга хас төп үзенчәлекләрнең тагын берсе – аның синкретик ***характерда*** булуы. *Синкретизм* ул – грек сүзе, кушылу мәгънәсендә, әдәбият һәм сәнгать үсешенең башлангыч чорына хас булган бөтенлек, бүленмәгәнлек, ягъни, төрле тармак, төр һәм жанрларның үзара органик кушылган хәлдә булуы. Икенче төрле әйткәндә, синкретизм ул - бер әсәрдә төрле жанрларга хас сыйфатларның укмашуы, сүз-поэзиянең, көй-музыканың, бию-хореографиянең, драматик уенның, йола-ритуалларның берләшүе.

Синкретизм – халык сәнгатенең бик борынгы чорларыннан ук килүче үзенчәлек. Кайбер жанрларда, әйтик, уен-бию җырларында, яки туй йола иҗатында сәнгать формаларының барысы да катнаша. Ләкин халык авыз иҗатында төп оештыручы үзәк рольне, һичшиксез, сүз уйный.

Мәсәлән, халык җырларында шигъри сүз дә, көй дә бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле. Шуның өстенә халык җырының бөтен мөмкинлекләре аны җырлап башкарганда гына ачыла. Уен-бию һәм туй җырларын башкарганда исә, билгеле бер драматик хәрәкәтләр дә кулланылып, әсәрнең синкретизмы, төрле сәнгатьләрнең үзенчәлекләрен укмаштыру тагын да көчәя. Бу үзенчәлек әкиятләргә дә хас. Аларның эчтәлеге оста әкиятче башкарганда гына ачыла ала. Әлеге үзенчәлек халык дастаннарында да күзәтелә. Борынгы заманнарда халык арасында дастанчы- чичәннәр, импровизаторлар булган. Әсәрне оста чичән музыка, җыр элементларын кертеп башкарганда, ул бик матур яңгырап, тыңлаучыга көчле тәэсир иткән.

Халык иҗаты әсәрләрен эчтәлеге, төзелеше-композициясе, образ-персонажлар системасы һәм башкарылу үзенчәлегенә карап өч зур төркемгә, (русча родка) бүлеп карыйлар: эпос, лирика, драма. Язма әдәбият әсәрләренең дә шундый ук төркемнәргә бүленүе фольклор традицияләреннән үк килә.

Эпос грек сүзе, ул сүз, сөйләм, хикәя дигән мәгънәгә туры килә. Эпос көнкүреш хәлләрен, көндәлек тормыш вакыйгаларын чагылдырган шигъри хикәяләүне аңлата.

Лирика шулай ук грек сүзе, lirikos тан алынган, лира дип аталган музыка коралының авазына кушылып җырлау дигәнне аңлата. Лирик әсәрләрдә иҗатчы яки башкаручының эчке дөньясын ачып салу төп максат итеп куела. Лирик әсәрләрнең төп вазифасы – кешенең эчке кичерешләрен мөмкин кадәр тәэсирлерәк итеп гәүдәләндерү.

Драматик әсәрләр исә (грекча drama - эш-хәрәкәт)диалогларга корылган яки рольгә кереп башкарыла торган хәрәкәтле уен-тамашага нигезләнәләр.

Күренекле фольклор һәм әдәбият галиме Марсель Бакиров татар халык иҗатының һәм традицион классик жанрларының төрләргә мөнәсәбәттә түбәндәгечә төркемләүне тәкъдим итә:

1) эпик жанрлар: әкиятләр, риваятьләр, легендалар, героик эпос-дастаннар, мәзәкләр.

2) лирик жанрлар: йола җырлары, лирик җырлар, уен-бию җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр.

3) лиро-эпик жанрлар: бәетләр, тарихи җырлар, мәхәбәт яки көнкүреш дастаннары.

4) драма башлангычы белән үрелгән иҗат төрләре: йола поэзиясе, халык уеннары һәм уен-бию җырлары, балалар фольклоры.

Халык иҗатының яшәү үзенчәлегенә, ягъни йола катнашу-катнашмауга бәйле рәвештә төркемләнү:

1) йола фольклоры: календарь (хуҗалык) йола иҗаты, гаилә-көнкүреш йола иҗаты, ырымнар. Йола иҗатын “йола поэзиясе” дип тә йөртәләр. Һәр төр йола иҗатының яки поэзиясенең үзенә хас жанрлары бар.

2) йола белән бәйләнмәгән фольклор: алда исемләнгән төрле эпик һәм лирик жанрлар.

Текстның кыскалыгына һәм табигатенә карап, аерым төркем тәшкил итүче кече яки афористик жанрлар: мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар һәм кулланылыш даирәләре таррак булган тагын берничә ваграк жанр (антлар, каргышлар, алкышлар һ.б.) [Бакиров, 2008:10].

Фольклористика – фольклорны, халык авыз иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнә торган фән. Халыкның сүз, музыка, хореография, драма иҗатларын, шулай ук әлеге сәнгать башлангычларын берләштерүче

фольклор жанрларын һәм әсәрләрен өйрәнә. Фольклористика нигездә өч компонентны үз эченә ала:

1) халык иҗаты әсәрләрен җыю-туплау эшчәнлеге;
2) аларны тиешле фәнни принцилар нигезендә дөньяга чыгару;
3) шул материалларны фәнни-теоретик өйрәнү эшчәнлеге.

Фольклор фәннең һәм сәнгатьнең күп кенә төрләре белән турыдан-туры бәйләнештә тора.Чөнки фольклор, инде алда әйтелгәнчә, синкретик иҗат төре санала, шуңа да ул фәннең һәм сәнгатьнең күп үзенчәлекләрен үзендә туплаган.

Халык иҗаты, беренче чиратта, әдәбият белән бәйләнештә тора. Фольклор һәм әдәбият сүз сәнгатенең ике төре. Аларның уртак һәм аермалы яклары бик күп. Халык авыз иҗаты язма әдәбиятка караганда күпкә алдарак туган. Чынбарлыкны образлар аша сурәтләү ысулы, тел-стиль чаралары, жанрлар системасы да фольклорда формалаша. Максим Горький: «Халык вакыт ягыннан да, иҗатының матурлыгы һәм гениальлеге белән дә дөньяда беренче философ һәм шагыйрь ул» дигән.

Халык авыз иҗатын халыкның тарихыннан башка да күз алдына китерү мөмкин түгел. Беренчедән, конкрет бер халыкның трихын белми торып, аның фольклорын белеп булмый. Икенчедән, халык иҗаты тарихны өйрәнергә ярдәм итә. Кайбер очракларда кайчандыр тарихта билгеле булган күренешләр заман үтү белән тик фольклорда гына сакланып калучан була. Бу очракта фольклор тарихны өйрәнү өчен бердән-бер чыганак була. Халык иҗаты әсәрләрендә күп кенә тарихи вакыйгаларның дөрес сурәтләнешен, аларга халык биргән бәяне күрергә мөмкин. Ләкин тарих белән фольклор арасына тигезлек билгесе куеп булмый. Чөнки халык иҗаты әсәрләре тарихта булган теге яки бу вакыйганың күчермәсе түгел, ә аның халык аңлавыннан һәм бәясен килеп чыккан образлы гәүдәләнеше һәм чагылышы ул.

Халык авыз иҗатының күп кенә жанрлары этнография (этнос- халык, графо- язам ) сүзләреннән алынган; ул халыкның килеп чыгышын, материаль һәм рухи культурасын өйроәнә) фәне белән бик тыгыз бәйләнештә тора. Фольклорның кайбер төрләре һәм жанрлары, үзләренең туу һәм яшәү шартларын исәпкә алып өйрәнүне таләп итә. Бу очракта этнография ярдәмгә килә.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең теле татар әдәби теленең нормаларын тудыруда да мөһим чыганак һәм җирлек булып санала. Халык иҗаты сәнгатьнең музыка һәм хореография кебек төрләре белән дә тыгыз бәйләнештә.

## *Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:*

**Тема*:* Татар фольклористикасы тарихы**

**1. Татар фольклористикасының аерым фән буларак оешуында Каюм Насыйриның роле**

1. Галимнең татар фольклорын өйрәнү тарихындагы беренче махсус фәнни хезмәтләрнең берсе булган “Казан татарлары тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр” (1880) мәкаләсе. Әлеге хезмәттә татар мифологиясенә, ырымнарны һәм йола фольклорына караган фикерләре.
2. Борынгы риваятьләр һәм легендаларны җыеп бастыруы һәм үзенең тарихи-этнографик хезмәтләрендә файдалануы.
3. Халык җырларын тематик төркемнәргә бүлүе һәм аларның сәнгатьчә эшләнешенә күзәтү ясау (“Кырык бакча” (1880), “Фәвакиһел-җөласа фил әдәбият” (1884)).
4. К.Насыйриның татар фольклорындагы афористик иҗат төрләрен җыеп, аларга билгеләмә биреп бастыруы (еллык өстәл календарьлары һ.б.).
5. Беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен башка халыкларның фольклоры әсәрләре белән чагыштырып өйрәнүе, фольклор әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп бастыру (“Сказки казанских татар в сопоставлении их со сказками других народов” 1900; “Образцы народной литературы казанских татар (загадки, пословицы, песни)” һ.б.).

**2. Г.Тукайның татар фольклористикасындагы урыны**

1. 1910 елда Шәрык клубында ясалган “Халык әдәбияты” лекциясендә фольклорга хас үзенчәлекләрне һәм аның язма әдәбияттан аермасын билгеләү. Фольклорның таралу мөмкинлеген күрсәтү. Халык җырларының лирик табигатенә, милли үзенчәлекләренә игътибар итү. Комик бәетләр иҗат ителү җирлеген күрсәтү.
2. Тукайның халык иҗаты үрнәкләрен җыю эшчәнлегенең күрсәткече буларак “Халык моңнары” (1910) җыентыгы.
3. Г.Тукайның халык авыз иҗатына нигезләнгән әсәрләре: “Шүрәле”, “Су анасы”, “Кәҗә белән Сарык” һ.б.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

# ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ

## ЯЗУЧЫДАН

Бу хәзерге кулыңызга алдыгыңыз Халык әдәбияты моннан аз гына мөкаддәм мәйданга куелган Халык моңнары исемендәге рисаләмә (әсәр) тәмамән багълыдыр.

Бу ике рисалә бер-берсенә тәгаллекъта (бәйләнештә) берсе ачкыч вә икенчесе йозак кабиленннәндерләр.

Шул сәбәпле бу рисаләләрнең берсен алып укырга тәнәззел боерган (түбәнчелек иткән) мөхтәрәм кариэләремнән (укучы) икенчесен дә әлдә (кулда) итмәкләрене үтенер идем.

Халык әдәбияты намендәге бу рисаләм Казанда Шәрекъ клубында, ушбу сәнә 15 апрельдә укыдыгым (итлакъ җаиз исә (әйтергә яраса) лекциямнең мәзмуненнән (конспект) гыйбарәттер.

Лекциядә җыруларымызның берничәсе генә, анчак лязим (бары тик кирәкле, тиешле) урында мисал өчен алынганнары гына зикер ителде (телгә алыну). Анда, әлбәттә, «Халык моңнары» нам бөтен бер мәҗмуга тәшкил иткән җырларымызның барчасын укып чыгарга тугъры килмәде.

Менә хәзер җырларымыз хакында байтак мөляхәзәне җәмигъ булган (фикерләрне эченә алган) «Халык әдәбияты»ны укыганда, шактый күп мөнтәхәб (сайланган) җырларымызны эченә алган «Халык моңнары»ны да алга ачып кую файдасыз булмаса кирәк дия, сүзне бетердем.

*Г. Тукаев*

### ИГЪТИЗАР (гафу үтенү)

Халык әдәбияты хакында хәзер сөйләячәгем лекция сымак нәрсәм өчен мин алдан озак тәхкыйкат вә тәдкыйкат (тирәнтен тикшерүләр) илә хәзерләнмәгән идем.

Көннәрдән бер көн бер иптәшемә уйнап кына: Мин халык әдәбияты тугърысында лекция укыйм, – дип әйткән идем. Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, мөгътәбәр гәзитәләремезнең берсенә язып та өлгергән.

Мин, ул иптәшем яныннан чыкканда, уйнап әйттем, ышанып калма тагы, дип әйтергә онытканмын.

Менә шулай итеп, яңлыш, уеннан уймак чыгып куйгандай булып, мин, теге гәзитә хәбәрен тәкзибкә-фәләнгә (ялганга чыгару) керешмичә, чынлап та халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм (батырчылык итү).

Бу эш миңа көтелмәгәндә генә килеп чыккан булганга, җырулар вә көйләремез тугърысында тарихи вә әсаслы (төпле, нигезле) мәгълүмат бирә алмыйм.

Безнең җырланмакта булган көйләремезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да,

мәгаттәссеф, аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал булмады.

Җырларымыз вә көйләремезнең тарихын вә мәнбәгъләрен (чыганак) тикшерергә берзаман махсус хезмәт куярмын да, шаять, халыкка шул тугърыда әсаслырак мәгълүмат бирермен дигән өмидем бар әле.

Хәзер сөйләгән сүзләремнән исә бер-бер төрле тирән мәгълүмат көтүчеләр булса, бик каты алданырлар шикелле тоела.

Озын вә кыска көйләремез тугърысында халык авызында төрле сүзләр сөйләнә. Аның барчасын да җыеп язу шактый озак заман эстидер. Шулай да сүз арасында халык авызындагы сүзләрнең үземә ишетелгән кадәресен бераз язып китәргә ярый.

## ТӘФКИЛЕВ КӨЕ

Борынгы Тәфкилев фамилияле бер мөфтинең урысча укый торган бик матур бер кызы бер француз җегетенә гашыйк булган була. Кыз француз җегетен, ата-анасы күрмәгән чакта, өенә дә китерә.

Бервакыт шулай, мөфти хәзрәт өендә кыз белән җегет күрешеп торган чагында, өстләренә мөфти хәзрәт үзе килеп керә.

Кыз, аптырауда калып, үзенең мәгъшукын зур пыяла шкаф эченә яшерә.

Алай да мөфти хәзрәт җегетне күрә. Таягын алып, җегетне кыйнарга килә башлый.

Җегет исә, тиз генә шкафны ватып чыгып, тәрәзәдән сикереп кача.

Шкафны ватканда, җегетнең битенә вә кулына пыялалар керә. Идәнгә җәелгән хәтфә паласлар өстенә каннар тама...

Минем исемдә шулкадәр генә калган.

Аннан соң җегет белән кыз арасында нинди маҗаралар булгандыр, миңа мәгълүм түгел. Ләкин Тәфкилев көенең моңлылыгына караганда, җегет белән кыз арасында мотлак (шиксез) бер фаҗига булгандыр дип фикергә килә.

## АШКАЗАР КӨЕ

Гыйшык вә мәхәббәт сәбәпле кияүгә барган бер башкорт түрәсе кызының кияве, Ашказар дигән суның буена ау ауларга китеп, шунда суга батып үлә. Моның вафат хәбәре мәгъшукасына ишетелгәч, ул бик кайгыра. Хәсрәтен ничек изһар итәргә (тышка чыгарырга) дә аптырый.

Беркөнне бу кыз, башкорт кызлары арасындагы барча җырчы кызларны чакырып, алардан вафат булган кияве хатирәсенә бик моңлы бер көй чыгаруларын үтенә. Әгәр дә күңеленә муафикъ бер моңлы көй чыгара алсалар, аларга әллә ничә баш төяләр һәдия (бүләк) итмәкче була.

Кызлар төрлечә көйләр чыгарып карыйлар, ләкин берсе дә түрә кызының күңеленә ошамыйлар..

Бу җырчы кызлардан бернәрсә дә чыкмагач, түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашказар» көен җырлап җибәрә. Җырчы кызлар хәйран калалар.

## САК-СОК КӨЕ

Сак-Сок бәете вә көенең нидән чыкканлыгы Сак-Сокның үз бәетләреннән дә күренә.

Бәетләрдән әңлашылдыгына караганда, бер ана үзенең ике баласын: «Сез Сак-Сок булсагыз иде», – дип каргый. Шул ук минутта балалар, Сак-Сок дигән ике кош сурәтенә кереп, кара урманга очып китәләр.

Балаларны каргаганда, аталары өйдә булмый бугай. Ул, кайткач, балалар кайда, дип, хатыныннан сорый. Хатын: «Каргап очырдым», – ди дә үкереп җылый башлый. Ире шелтә итә.

Балалар исә искән җилләр аркылы гына аталарына үзләренең хәсрәтле сәламнәрен җибәреп торалар.

Менә бу шуннан чыккан көй.

## КАСИМСКИЙ ИБЫРАЙ

Бу – Касим шәһәрендәге чамадан тыш мөсриф (исраф итүче, мал, акча туздыручы) бер байга чыгарылган көй, Касимский Ибырай гуләйт итә-итә дә актык тунын да сата. Ахыр гомерендә бик хосранлы (үкенечле) рәвештә вафат була. Касимский Ибырай көе шул сәбәптән чыга.

## ҖИЗНӘКӘЙ

Бу көй бер кияүнең үзенең балдызына гашыйк булуыннан чыга. Кияү, хилафе шәргы (шәригатькә каршы) рәвештә, балдызын да никахлап алып, ике кардәшне бергә җыймакчы була.

Агач башы азыктыр
Балдыз алу языктыр;
Язык булса– ни миңа,
Язык казык башына–
шушыңар дәлаләт итә (дәлил булу).

## БАШМАК КӨЕ

Бу Башмак көе дә мөфти вә мирзаларымыздан зур фамилияле бер кешегә чыгарылган көй булырга кирәк.

Ләкин тәгъйин (тәгаен) кемгә вә ни хосуста чыгарылганын, мәгаттә-эссеф, тәфтиш итә (тикшерү) алмадым.

Бу көй, зан идәрсәм (уйлыйм ки), берзаман хөкүмәт тарафыннан җырланырга мәнгы да ителгән (тыелу) иде бугай.

Көйләр тарихы хакында бар белгәнем шушы кадәр генә булганга, хәзер мин аннан күчәм дә максудым булган халык әдәбиятына киләм. Шул тугърыда булган мөляхәзәләремне (фикер йөртү, уйларымны) сөйләмәкче булам.

## ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ

Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче (чыгаручы) шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга (мәсәл-әкиятләр) әйтеләдер.

Бу нәүгы (төр(е) әдәбият, әле дөньяда язу сәнгате булмаган чактук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан – атага, атадан балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбияттыр. Әгәр дә су, чиләк, бүрек, арба дип әйткән сүзләрне иң әүвәл кем чыгарган дигән сөальгә җавап биреп булмаса, Аклы ситса күлмәгеңне кигәнеңне күрмәдем җыруын яки Эт симерсә, иясен тешләр мәкален иң элек кем чыгарган дигән сөальгә дә җавап биреп булмыйдыр.

Халык әдәбияты, бер дә кәгазьгә язылмаса да, буыннан буынга ишетелеп, халык күңелендә бер дә онытылмый торадыр.

Халык әдәбияты китапка керсә дә, язылса да, анчак (тик, фәкать) бер, халык җырларын вә әдәбиятын җыеп, китап рәвешендә таратуны теләүче бер кеше тарафыннан гына кертеләдер. Шул кеше үзе ишеткән вә тапкан кадәр җыр вә масалларны язып нәшер итәдер.

Халык әдәбиятының ничек булганын күрсәтер өчен, мин монда халык авызындагы кыска гына бер хикәяне алып яздым.

Бер авыл кешесе, төн буе ашасын өчен, урманга атын җибәрә икән. Иртә берлән, эшкә җигәргә дип атны алырга барса, ни күзе белән күрсен: атын шапырма тиргә баткан, төн буе әллә ничә йөз чакрымнарны бер дә туктамастан чапкан кеби, тәмам хәлдән тайган көе таба. Бу кеше, атны алып кайтып, ничек кирәк алай эшләтә дә, кич булгач, тагы шул ук урманга җибәрә. Иртә берлән урманга барса, атны тагын шулай эштән чыккан килеш таба. Атның бу хәлгә төшүенә һичбер сәбәп тапмый гаҗәпләнә. Бичара кеше, атының шулай газапланып арыгаюыннан тәмам гаҗиз калгач, авылда бер ак сакаллы карттан бу тугърыда сораша башлый. Карт бу кешегә киңәш бирә: Син, – ди, – бүген кич атыңны урманга җибәргәндә, аркасына сумала ябыштырып җибәр, – ди. Теге кеше карт кушканча эшли.

Кеше иртә белән атны алырга барыйм дип капкасыннан чыкса, күрә ки, ат үзе кайтып килә. Өстенә ат аркасындагы сумалага чытырдап ябышып каткан Шүрәле атланган. Беленә ки, төн буена атны чаптырып газаплаучы шушы Шүрәле икән. Дәрхаль (шунда ук, шул ук вакыт) авыл халкын чакырып, Шүрәлене ат өстеннән алалар. Шүрәлене күсәкләр белән бик каты кыйныйлар. Шүрәле үлми. Авыл халкы, бу усал Шүрәлене ни рәвешчә, ничек итеп үтерү тугърысында күп киңәштән соңра, аны базга салып, өстенә керосин сибеп яндырып үтерергә карар бирәләр һәм шулай эшлиләр. Шүрәле бичара яна, кычкыра, фөрьяд итә (ялвару), ахырында янып көл була. Ләкин җаны чыкканчыга кадәр бу авылны каргый: Ярабби, бу авыл утыз өйдән артмаса иде, – ди.

Менә Казан артында бер авыл бар, ул авылның салына башлаганына йөз елдан артык бер заман булса да, һаман да 25-30 өйдән артмый. Теге Шүрәлене яндыручы авыл шушы авыл, имеш. Бу авылга Шүрәленең үләр алдындагы каргышы төшкән, имеш.

Менә бу кеби хикәяләр халык хикәяте, халык әдәбияты дип аталалар. Чөнки моны сөйләүче кем? Гайнетдинме? Сәйфетдинме?

Котбетдинме? – асла (бөтенләй) мәгълүм түгел. Бу – фәкать гомумхалык хыялы, халык хикәясе.

Ихтар (искәрмә): әгәр дә шушындый ук хикәя бер-бер мөхәррир йә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул халык әдәбиятылыктан чыга. Бу җөмләдән Пушкиннең «Алтын балык» вә «Алтын әтәч» кеби хикәяләрен санарга мөмкин. Мондый хикәяләрнең башта халык авызында сөйләнүе дә вә халык рухынча язылуы да аның халык әдәбиятылыктан чыгуына манигъ була алмый. Чөнки, бәя әйткәнемезчә, халык әдәбияты дип, язылган вә мәзбут (язу белән беркетелгән) нәрсәләргә әйтелмичә, авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтеләдер. Бу булды халык хыял вә хикәясенең бер нәмүнәсе. Яхшы. Менә сезгә халык шигырьләреннән дә бер нәмүнә (үрнәк):

Минем сөеп җиккән атым
Кара берлән тимеркүк;
Сагынганда айга карыйм –
Ай да ялгыз минем күк.

Менә бу – шигырь, һәм дә хәкыйкатән (чын-чыннан) шигырь. Ләкин кем моны инша иткән? Һич тә билгеле түгел. Моны инша итүче, сөйгәненең йөзен искә төшереп, айга карый да, соңра бик матур рәвештә, шагыйранә генә: Ай да ялгыз минем күк! – дип куя.

Сүз башында әйткәнемезчә, менә мондый шигырьләргә халык җырлары дип әйтелә. Бу җыруның әүвәлеңдәге ике юлы, ягъни: Минем сөеп җиккән атым кара берлән тимеркүк, – дигән сүзләренең соңгы ике юлга бик ябышуы булмаса да, соңгы: Сагынганда айга карыйм – ай да ялгыз минем күк, – дигән мәгънәле вә хисле сүзләрнең астына нинди истигъдадлы (талантлы) шагыйрь дә кул куюдан тартынмас дип уйлыйм.

Аннан соң безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. Әүвәлге ике юл анчак скрипкә уйнаганда бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер.

Мәсәлән, гавамнан (гади халык) берәү җырлый:

Сандугачлар су ташый,
Кайда икән су башы?

Ул бу сүзләрен җыруга санамый, бәлки тыңлаучыга үзеннән бернәрсә көттерә.

Тыңлаучы: «Бу нәрсә әйтмәкче була икән?» – дип көтеп торган чагында гына, ул:

Безнең җанкәй ялгыз башы,
Хозыр булсын юлдашы, – дип куя.

Шулай көтмәгәндә генә килеп чыккан бу матур сүзләр тыңлаучының колакларына вә күңеленә, әлбәттә, хуш килә.

Бу тарыз (рәвешле) җырлау табигый рәвештә сайланган булса да, бик муаффәкыятьле (уңышлы) сайланган. Әүвәл юк кына сүзләр берлән

тыңлаучының колагын торгыз да аннан соң мәгънәле сүз әйт. Бик яхшы бит! Шулай көтеп алган кадерле була.

Бу сүзләр безнең җырларымызның күп тарафы шулай – әүвәлге ике юлы соңгы ике юлга ябышмаган булганлыктан гына сөйләнде.

Югыйсә безнең һәр дүрт мисрагы (җыр, шигырь юлы) да бер-беренә ябыша торган җырларымыз да бар.

Мәсәлән:

Җаныем, җаныем, җанашым, авыртмыймы җанбашың?

Авыртса ла, ай, җанбашың, үзем түшәк, җанашым.

Мин сөямен үзеңне, кашың берлән күзеңне;

Мин сөйгәнне син шуннан бел: һич тә алмыймын күземне.

Ләкин болар мөстәсналәр (аерым очрак, чыгарма) диергә ярый. Инде халык җырлары вә халык әдәбияты дип нәрсәгә әйтелгәне, шаять, азрак аңлангандыр дип уйлыйм.

Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу – кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур (төзек) Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.

Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфуз (сакланып) уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле.

Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһад итәргә кирәк.

Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан (якты) көзгеседер. Бу – бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр.

Менә шушы дәгъване, ягъни халык җырларының сихерле көзге икәнен күрсәтер өчен, хәзер берничә җырлар җырлап күрсәтәмез. Мәсәлән:

Байлар кияр каракүл, без киябез эшләпә;

Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә.

Менә бу җыру – халкымызның бу дөньядагы байлык вә фәкыйрьлек дигән ике нәрсәгә карашы. Аныңча, Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә.

Кимим – бүркем булса да, җыламыйм – күңлем тулса да;

Ходай кушкач, нихәл итим, чыдыйм – авыр булса да.

Менә бу – халыкның Ходай тәкъдиренә чын күңелдән тапшырылуын һәм, никадәр авыр булса да, үзен-үзе чыдарга көчләвен күрсәтә.

Ак келәтнең тәрәзәсе сиксән сигез өлгеле;

Начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле.

Менә халыкның ак келәтнең тәрәзәсе кеби юк кына нәрсә белән сүз башлап та, начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле кеби, чын хакыйкать сүзне шартлатып әйтеп тә бирә алуы. Монысын, мотлакан (шиксез), халыкның әдәби икътидары (көч-куәт) диергә ярый.

Җөрмә монда, кайт иленә, иленңдә иген игәрсең;

Стаканыңны ат итеп бутылкаңны җигәрсең.

Менә монысы халыкның үткен гакыллылыгын, русча әйткәндә, остроумиесен күрсәтә. Чынлап та, сукасын, сабанын, әвенен, хатынын, бала-чагасын онытып эчеп утырган бер сала мужигына, шулай итеп, каладан китәргә киңәш бирмичә, ни дип әйтергә кирәк?!

Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кеби, гаризый бер хәлдер. Фарсилар: Гаризра игътибар нист, ягъни вакытлы вә гаризи (читтән килгән) булган нәрсәгә игътибар юк, – диләр. Хуш. Тагын бер җыру:

Әй тал үсә, тал үсә – башын киссәң, тагы үсә;

Тутасычөн кайгырмыймыз: сеңелләре тагы үсә.

Менә бу җыру чын-чын халык халәте руханиясен күрсәтә. Бу җыруны чыгарган кеше, әлбәттә, апасы белән мөнәсәбәттә булган булырга кирәк: ул аның өчен бер дә кайгырмый. Сөаль: Ни өчен кайгырмый? Җавап: Сеңелләре тагы үсә. Күрәсез бит, бу җыруны җырлаучы гами (беркатлы кеше) : Тутасычөн кайгырмыймын, – дип кенә туктамый, бәлки үзен-үзе зурайтып: Тутасычөн кайгырмыймыз, – дип куя. Зур кеше, имеш!

Әгәр санасак, мондый мисалларны хисапсыз күп таба алырмыз.

Бая әйткәнчә, сихерле күзгедән каралса, ягъни халык җырларын дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын барчасын күреп буладыр.

Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык – шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил (яратучан) халык. Чү, аз гына бернәрсә шылт! иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга. Мәсәлән, Гайнетдин дигән кеше үземе яки кызымы бер гаеп эшләгән икән – бетте инде, урамда бәетен җырлыйлар. Фараз итик: җәй көне авылда Гайнетдин абзый үзенең гаиләсе белән чәй эчеп утыра. Тәрәзәләре ачык, кояш төшкән. Бу гаилә бернәрсәдән хәбәрсез, тыныч кына утырган чакта, менә берзаман боларның тәрәзәсе төбеннән әллә никадәр үсмер җегетләр Гайнетдинне мыскыллап җырлап үтәләр:

Тау башында тимер бүкән, типкәләмә, Гайнетдин;

Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин!

Гайнетдин бичара вә гаиләсе кызарыналар, күзгә-күз карашалар, вәссәлам! Нишлисең, тегеләрнең авызларына тастымал тыгар хәл юк!

Кыргыз халкында булган кеби, бер-берсенә каршы җырлашу безнең халыкта әле һаман да бар. Ләкин, кыргызлардагы кеби, шома вә яхшы чыкмый. Кара-каршы җырлашканда, безнең халык бер-берсенең исемнәрен җырга катыштырып һәм һич кирәкмәгән, мәгънәсез сүзләр катыштырганлыктан, җырлары ямьсез чыга.

Мәсәлән, кара-каршы җырлашканда болай җырлыйлар:

Аклы да гынай ситса, Закир абый,
Буй-буй ыштан, Җамалый кода;
Арага гына, Сәйфетдин абзый,
Төшкән дошман, Якуп агай-эне.
Ходай да гына кушкан, без кавышкан,
Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,
Нишләтер, ди, безне ул дошман!

Менә бу җыру булып чыкмый, бәлки шактый озын бер хат укып чыгу белән бер була. Ничек булса булган; әлхасыйль (кыскасы), халык, һичкемгә мохтаҗ булмыйча, үз хиссиятен үзе мәйданга чыгарган, җырның җыртыгы юк дигән дә, җырлый биргән, бәетләр дә чыгарган.

Халык җырлары, бөтен мөһмәляте (буш, мәгънәсез өлешләре) вә җитлексезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә. Чит милләтләр өчен безнең җыру мәгънәсез вә хәтта көлке дә булса булыр. Мәсәлән, шушы җыруны русчага тәрҗемә итеп карыйк:

Калфагым бар, шәлем юк,
Шәл алдырмый хәлем юк;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Сине алмый хәлем юк.

Русча:

У меня колпак есть, но нет шали,
Необходимо мне купить шаль.
По мне нет любимой, кроме тебя,
Необходимо мне жениться на тебе.

Шулай, һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә. Хәлне кире әйләндереп куйсак та, барыбер шулай булып чыга; мәсәлән, русларның сөеп җырлаганнары «В саду ли в огороде девица гуляла» җырлары безнең колакка да ул кадәр хуш килми бит. Керпе үз баласын «йомшагым» һәм аю үз баласын «аппагым» дип әйтә, ди. Бу гарәпләр мәкале; гарәпләр моны: «Көлле тайрин ястәлиззе бисаутиһи (Һәр кош үз тавышы белән ләззәтләнә)», – диләр.

Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр. Русларның Пушкин вә Кольцов кеби иң зур шагыйрьләре дә, халык җырларына тәкълид итеп, бертөрле искусственныя (күплекнең иске формасы) песни, ягъни сонгый җырлар яздылар. Болай халык җырларына тәкълид итеп язган шигырь, тәкълид итмичә язылган шигырьләрдән хис, мәгънә, тасвир ягыннан һич тә ким

булмавы өстенә халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга, халык күңеленә бигрәк гүзәл тәэсир итә вә урынлашадыр. Бу җөмләдән Кольцовның «Ник йоклыйсың, мужик?», «Сукачы җыруы», Пушкиннең «Кызлар җыруы» саналалар.

Ә бездә халык җырларына тәкълид итүчеләр билгомум (гомумән) булдымы? Әлбәттә, безнең Кольцовларымыз, Пушкиннәремез булмаганга, мин: «Халык җырларына тәкълид итүчеләр билгомум булдымы?» – дигән сөальне тәкрар итәм (кабатлау) дә: «Ник булмасын, булды», – дип, үз сөалемә үзем җавап бирәм. Менә иң элек мәдрәсә шәкертләре тәкълид иттеләр:

Каләш-шәйхе фишшифа дип
Укыганың мантыйкмы?
Ма вәҗәдте, валлаһ, җаный,
Синнән гайре артыкны.
(Шифа китабында шәех әйткән дип
Укыганың мантыйкмы (формаль логикамы)?
Табалмадым, валлаһи, җаный,
Синнән бүтән артыкны. )

Гыйльме хикмәт укыр өчен
Бару кирәк Бохарга;
Ярның исе алышынмас
Мисек-ганбәр, җофарга.
(Фәлсәфә укыр өчен
Бару кирәк Бохарага;
Ярның исе алышынмас
Һичбер төрле хуш искә.)

Каля рәсүллуллаһ дип
Укыганың Мишкатьме;
Имиең тотсам, кулым тими,
Әллә киемең биш катмы?
(Пәйгамбәр әйткән диеп
Укыганың Мишкатьме?)

Әл-хикмәтел-балига.
Мин тәэлиф әл-Мәрҗани;
Филмәшрикый вә филмәгъриби
Ля нәзыйрекә, җаный.
(Камилләшү серләре –
Мәрҗани төзеп чыгарган китап;
Көнчыгышта да, Көнбатышта да
Сиңа тиң юк, җаный. )

Менә боларны сонгый җырларымыздан санарга ярый. Үткән сәнәләр нәшер ителмәктә булган бер көлке журналда, Авыл җырлары сәрләүхәсе (исеме) астында, шундый сонгый җырлар күренгәли иде.

Исемдә калган кадәресен язам:

Җомры тояк тайларда,
Матур кызлар байларда;
Әхбар тәэмин иткән байлар
Җөри икән кайларда.

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен
Рәмиевләр алтыны.

Башындагы чабатаңның
Сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды
Бәдигъ мәзин күркәсе...

Вә гайреләр.

Менә бу сонгый җырлар да вакытында бик оригинальный вә нәүзоһур (яңалык, яңа килеп чыккан) нәрсәләр иде.

Чөнки көленергә тиеш бер нәрсәдән бер-ике юллык сүзләр белән тиз генә көленеп ташланыла иде. Бу озын-озын мәкаләләр хезмәтеннән артыграк эш күрә иде.

Башта әйткәнемезчә, халыкның бу тарыз җырлавы бик муаффәкыятьле сайланганлыктан, моның безнең һөҗүвиятемезгә-сатирамызга да файдасы тиде.

Халык җырларына билгомум тәкълид ителгәне (гомумән иярелгәне) язылды инде, ә шигырьләремездән халык җырларына тәкълид итүчеләр булдымы? Бу сөальгә дә: «Булды», – дип җавап бирергә тугъры килә. Безнең шагыйрьләремез дә мәйданга сонгый җыр дип әйткән шигырьләр китерделәр. Әмма муаффәкыятьле чыктымы-юкмы, ансы тәнкыйтьчеләр нәзарына (карамагына) калдырыла.

Мисал өчен мин монда Миргазиз әл-Укмаси җәнабләренең бер сонгый шигырен вә башкаларның да берәр шигырен укып күрсәтәм.

Татар тормышыннан.

**КИЛЕН**

Мәэюсь (өметсез) карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән (якты киләчәк) өмид кискән,
Ник тугъдым, – дип егълый, – анадан.

Кайнанасын күрә төшләрендә,
Җәллад булып килә каршына;
Башын кисә, имеш, – моның гаибе:
Тоз салмаган, имеш, ашына.

Иртә тора таңнар сызылганда,
Кош-корт яңа канат какканда;
Иңләп бу берьялгыз хезмәт итә,
Һәркем тан уйкусын тотканда.

Чү, сүз булмасын, – ди, – кайнанамнан,
Рәхмәт әйтсен, – ди-ди эшли эш;
Аргач, ял итәргә курка, мискин:
Тагын башланыр, –дип, –әр-каргыш.

Әгәр ялгыш булса бер хатасы,
Кайнанасы дөнья куптара;
Яшеннәр яшьни, күкләр күкри,
Дөньяларны җимрә, актара.

Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә,
Гыйфритләнә килен өстенә;
Бичара килен – япь-яшь кызга
Зәгьфырандай сары төс иңә.

Мәэюсь карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән өмид кискән,
Ник тугъдым, – дип егълый, – анадан.

Бу булды бер. Тагы да мәгъруф (танылган) шагыйрьләремездән Сәгыйть әфәнде Рәмиевнең Яшә, Зөбәйдә, яшим мин исемле китабыннан тәмам мәгънәсилә сонгый шигырь булган шушы җыруны күчерәм:

Без эчәбез дә җырлыйбыз,
Акча бетсә, урлыйбыз;
Ходай безгә шулай язган,
Ярамый дип тормыйбыз.

Сәгыйть әфәнденең пьесасында бу җыруны берничә исерек җегетләр урамнан җырлап китәләр. Аны алар җырламый, бәлки Сәгыйть әфәнде бу җыруны, аларның халәте рухиясенә карап, авызларына сала. Менә бу шунлыктан сонгый җырулар җөмләсенә керә.

Инде шушы сәтырларны (юл (китап юлы)) язучы кешенең дә шулай халык җырларына тәкълид уларак язганы бер шигырен дә нәкыль (күчерү) итәм:

## МИЛЛИ МОҢНАР

Ишеттем миң кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен,
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып, җырны тынлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: Кардәш, бу көй нинди көй?
Җавабында милләттәшем миңа:
Бу көй була, – диде, – Әллүки!

Шушы мисал итеп китергәнем шигырьләр – барчасы да сонгый җырулардыр. Бу сонгый җырлар халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене белән язылганнардыр. Шуңар күрә боларны «Зиләйлүк» вә яки «Әллүки» көйләренә туп-тугъры җырлап була.

Аңлашыла ки, бездә дә әдәбиятымызның нигезе булган шул халык җырларына, берничәшәр генә булса да, кирпеч салучылар булган һәм бар икән.

Халык җырларын, халык әдәбиятын колакка ишетелгәнчә генә хөкем итеп, бу мотлак шулай икән диеп булмый. Мәсәлән:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Безнең болай утырулар
Сагънып сөйләргә кала, –

җыруын шушы килеш отылып алынса, бу мотлак шушылай җырлана икән диер хәл юк, аны икенче кәррә (тапкыр) ишеткәндә, ихтимал:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Гакылың булса, уйлап кара:

Бу дөньяда кем кала? –дип тә ишетерсең.

Халык җырлары, халык әдәбияты кайчакта шулай аерым шәхесләрнең кәефенә карап төрлеләнә дә. Хикәя вә мисалларда да хәл шушылай ук. Мәсәлән, бер хикәя сөйләүче үзенең хикәясен: Бар иде урман буенда бер карт белән бер карчык, – дип башласа, шул ук хикәяне икенче кеше: Бар иде, ди, диңгез буенда бер карт, – дип башлый.

Халык җырларының вәзене вә җырлану рәвеше – һич үзгәрми торган бер генә вәзен вә бер генә рәвештер:

Сажидәнең камчат бүрке –
Күз өстендә күләгә;
Монда уйнаган монда калсын,
Анда кайтып сөйләмә, –

дигән җыру, әлбәттә, әллә кай заманнарда, әле безнең 17-18 яшьлек гүзәл Сажидәләремез башларына зур камчат бүрек киеп йөргән заманда җырланган. Инде хәзер, заманымыздагы кечкенә генә калфаклы туташларымыз тугърысында җырланганда да, барыбер шул ук вәзен, шул ук рәвеш белән җырланадыр.

Башка халыкта ничектер, бездә бер ел үтми ки, анда бер-бер төрле яңа көй чыкмасын. Бу хәл бабаларымызның мәҗүс заманнарыннан бирле үк дәвам итеп килми микән? (Бу урында бернәрсә хәтергә килә: безнең халык җырларында халкымызның мәҗүс заманнарында җырлаган җырлары дип хөкем итәрлек бер җыру да сизелми. Барча җырларымыз ислам кабул иткәннән соңгылар гына булырга охшыйлар. Мисал өчен: Иртә генә тордым, ай, таң берлән, битем юдым ап-ак кар берлән; ахирәт тә күрке иман берлән, дөнья күрке сөйгән җар берлән. Безнең хәзерге җырларымызның күбесендә ислам, тәкъдир, Ходай сүзләре күренә. Гаҗәбан (бик гаҗәп), мәҗүс (халыкларның табигать көчләренә табынуы белән бәйле заманнары (язычество) замандагы җырлар бөтенләй онытылып бетте микәнни?)

– Син бу ел чыккан яңа көйне ишеттеңме әле? Әнә фәлән абзый Мәкәрҗәдән яңа көй отып кайткан, – кеби сүзләр халык арасында һәрвакыт ишетелмәктәдер.

Бу ел яңа көй чыктымы, халык инде былтыргы иске көйне җырламый вә уйнамый башлый. Авыл урамнарында җегетләр, көз көне никрутлар яңа көйдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар.

Татар көйләре, шулай ел саен алмашынып торганлыктан, төрле исемнәр илә һич тә санап бетергесез дәрәҗәдә күптер. Казандагы иске әдәбиятны сөючеләр, төрле көйләрне язып, әллә ничәшәр китап вә рисаләләр язып тараттылар. Ләкин һаман да көй исемнәрен санап бетергәннәре юк әле. Бу китапчылар һәммә Русия мөселманнарына мәгълүм вә уртак булган «Тәфкилев», «Әллүки», «Салкын чишмә» вә «Ашказар» кеби көйләргә җырлар язып таратсалар да, өязләрнең вә аерым авылларның үзләренә махсус булган җыр вә бәетләренә тия алмадылар әле. Фәлән авылда

Себер киткән кызга, төгән авылда асылып үлгән яки баткан җегеткә үзенә махсус көйләр вә җырулар белән чыгарылган бәет вә моңнар һич тә җыеп бетермәслектер.

1905 ел җитеп, хөррият сәгате сукканчы, һәркемгә мәгълүм улдыгы үзрә (мәгълүм булганга), без Русия мөселманнарында әллә нинди бер гомуми онытылу бар иде. Шул онытылу арасында милли көйләремез, милли моңнарымыз да онытылып бара иде; әгәр бер кеше алдында «Сакмар суы», «Әллүки» кеби бер озын көйне җырлый башласаң: «Куйсана шул картлар җыруын! Яңа көйне җырла!» – дигән сүзне ишетә идең.

Әйе, хөррият булды, яшьләр чыкты. Алар халык арасына чумды. Алар шушы онытылып яки һичкем тарафыннан әһәмият бирелми башлаган милли моңнарымызны терелдерделәр. Китаплар яздылар. Әүвәлдә итальянский гармуннан башка уен коралы күрмәгән татарларга әллә нинди оркестрлар җыеп, әллә нинди чүмеч төсле мандолиннардан милли көйләр уйный башладылар. «Куйсана шул картлар җыруын! «Әпипә»не әйттер», – диюче кешенең, теге чүмечләр белән уйнаучы унлап җегетләрнең иске «Зиләйлүк»ләрне уйнаганын ишеткәч, колаклары торды. Аркасыннан каннар йөгерде. Әүвәлге фикеренең ялгышлыгын сизде. Бөтен көй вә моңнарымызга мәхәббәт итә башлады. Казандагы Шәрекъ клубына бу хезмәте өчен милләт исеменнән рәхмәт укымаска мөмкин түгелдер.

Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бер төрле хосусият бар кеби.

Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбүл вә мөстәхсән (тиеш һәм күркәм) күренә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бер нәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем. Әгәр дә шул чукрак хәлемдә бер руcның җырлап утырган хәленә карасам, мин аның авызының җыртылганчы ачылуыннан вә үзенә көчлек килүеннән, мотлакан, бу җырлый дип уйлар идем.

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән (яхшы карашын казанган) бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде. Аның шулай мыек астыннан гына җырлавы безнең хушымызга бигрәк китә иде.

Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела. Бу тугърыда күп мөсахәбәгә (сөйләшүгә) кителсә, эшнең музыка вә аны аңлау мәсьәләсенә җитәчәге сизелә.

Минем образованием бик бала рәвештә – малютка булып калган. Юк аның тоткан нәрсәсен куптарырлык кулы. Юк аның уйлаган вә сизгән нәрсәсен дәлилләр берлән сөйләрлек теле. Юк аның караган нәрсәсен аркылы тишәрлек күзе. Шул сәбәптән, җәһаләтемне билигътираф (наданлыгымны танып), ул хакта күп сөйләүдән туктыйм.

Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була.

Аннан башка кайдан табасың? Безнең матбугат исемендә йөртелгән иске китапларга вә басмаларга кайтып карыйкмы? Иске китапларымыздан «Фәзаилеш-шөһүр»гә, «Йосыф китабы»на мөрәҗәгать итикме? «Фәзаилеш-шөһүр» белән «Йосыф китабы» кем телендә? Алла белә, җен телендә. Бу китапларны кем дәрес китабы итеп тоткан? Татарлар.

Киләбез «Таһир-Зөһрә»гә.

Сазың күп моң кылады,
Ишеткән таң калады;
Гариб гашыйк, якын кил:
Исмеңез кем булады?

Бу кем телендә? Кыргыз телендә. Бу кем китабы? Татар китабы. Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер.

«Тәрҗеман» гәзитәсен алабызмы? Бармы анда бер генә татарча сүз! Көчләре беткәнче: Без Тәрҗеман бабай артыннан калмыйбыз, – дип маташкан иске өлфәтче вә башка да берничә мөхәррирләрнең тәхрирләрен (әсәр, язган нәрсә) алыңыз. Бармы аларда татар рухы вә татар сүзе?

Андый мөхәррирләребез татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар. Ләкин булдыра алмаслыкларына тәмам күзләре җиткәч кенә туктадылар.

«Тәрҗеман»ның гына ара-тирә җылаганлыгы ишетелә.

Борһане тәрәкъкый тагы, яңлыш-йоңлыш булса да, төрек җөмләләре тәртип итеп маташкан булып, нинди көлкеләр эшләмәде.

Үз араларында төрекчә сөйләшеп маймыллланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, госманлыез, әфәндем дип йөрүче хиффәтләребез (тиле, юләр) дә аз булмады.

Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте.

Гәзитәләр дә, бундан, буйлә кеби сүзләрне генә калдырып, татарча языла башладылар, китап вә рисаләләр дә татарча чыга; без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр – Истанбулда, без – монда.

Хәерле юлга!

### **ХАТИМӘ (**соңгы сүз**)**

Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм

мәхәббәт итәм. Шунлыктан, халык җырларына мәхәббәтемнең бер әсәре булсын дип, шушы мөляхәзәләремне язарга җөрьәт иттем.

Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем.

Мәдрәсәдә үк мине җырчы diләр иде.

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң сарт «Бәдәвам»нәре, сарт «Кисекбаш»лары, кызылбаш «Тасриф»ләре, гарәп «Нәхү»ләре (синтаксис) белән туган телемезне сөймәк кеби бер олугъ нигъмәткә малик (байлыкка ия) була алыр идеммени?

Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам.

Соң. 1910 ел.

***Материал түбәндәге чыганактан алынды:***

Тукай Г. Халык әдәбияты // Г.Тукай. Әсәрләр. Биш томда. Проза. Публицистика (1907-1913). – Казан: Татар.кит. нәшр., 1985. – 164-185 б.

**3. Фольклористикада Г.Ибраһимовның роле.**

1. Язучының «Халык мосаннәфаты» (1910) һәм «Әдәбият кануннары» (1916) хезмәтләрендә Г.Тукай күтәргән мәсьәләләрне үстерүе: халык иҗатындагы шәхси һәм коллектив иҗат мөнәсәбәтләрен аңлатуы. Фольклорның матур әдәбиятка йогынтысын күрсәтүе.
2. Г.Ибраһимовның фольклорда һәм әдәбиятта халыкчанлык мәсьәләсен күтәрүе.

**Г.ИБРАҺИМОВ**

## ХАЛЫК МОСАННӘФАТЫ

Халык арасында авыздан-авызга күчеп йөри торган, фәкать шул халыкның зиһенендә генә сакланып килгән вә чыгаручысы мәҗһүл *(билгесез)* булган, борынгы заманнан калма әсәрләрнең мәҗмугына «халык мосаннәфаты» дип исем биреләдер.

Гавамның җен, пәри, албасты, шүрәле вә су анасы кебек нәрсәләр хакындагы әкиятләре, хәзрәти Гали кыйссалары[1], үги ана, үги кыз вә таз малай хикәяләре, солдат вә сугыш бәетләре, мәкаль вә табышмаклар бармы?

Менә шуларның һәммәсе әдәбиятның «Халык мосаннәфаты» исемле кыйсьмен тәшкил кыйладыр. Болар башта, әлбәттә, шул халыкның үз эчендәге бер адәм тарафыннан чыгарылган була, ләкин соңыннан аның авызыннан алып ерак мөхиткә тарала башлагач, сахибенең *(иясенең, авторының)* исеме онытыла; ниһаять, халыкның гомуми малы кабиленнән *(төреннән)* булып каладыр. Яшәгән җиренә вә әхвале рухиясенә мөтәнасиб *(рухи хәленә бәйле)* рәвештә бу нәүгы җырлар вә әкиятләр һәр кавемдә була; байтак заманнар гавам *(гади халык массалары)* үз рухын шулар белән генә юатадыр. Гыйлем вә матбугат белән яктыртылмаган гавам өчен болар игътикад та *(ышанган, инанган нәрсә, идеал)* вә тәгълимат та буладыр.

Халык гыйлем белән зыялланганнан *(аң-белемгә ия булганнан)* соң, бундый әкиятләргә ышану бетсә дә, болар һаман игътибардан чыкмыйлар. Мәдәни милләтләр тарафыннан бу нәугы әдәбиятка зур әһәмият биреләдер. Аларда голяманың бер кыйсьме шуларны өйрәнү өчен гавам эченә керәләр; алар белән утырдаш булып, шул хакта мәгълүмат җыялар; вә таптыкларын матбугатта нәшер кыйлалар.

Бундый милләтләр матбугатында болар җыелган, эшләнелгән вә, төрле әкъсамә *(өлешләр)* бүленеп, нәтиҗәләр истихраҗ *(нәтиҗә ясау, хөкем чыгару)* өчен хәзерләнгән була. Болар өчен зур-зур мәҗмугаләр вөҗүденә китерелә; кыйраәт *(уку)* китапларында яхшы ук урын бирелеп, бөтен мәктәпләрдә тәгълим кыйлынадыр. Мисал өчен русларны алыйк.

Рус әдәбияты хакындагы тарихларга караганда, аларда халык мосаннәфаты гарбиләр *(Көнбатыш халкы, европалылар)* тарафыннан нәзаре хәйрәт *(гаҗәпләнүле караш)* белән каралырлык дәрәҗәдә күп вә гүзәлдер. Аларның христианлыкка керүләре вә рум халыкларына *(Рим (Европа) халыклары)* катышулары бундый мосаннәфатның табигый рәвешчә тәрәкъкыйсенә зур бер манигъ *(киртә, каршылык)* булган булса да, бөтенләй туктата алмамыштыр.

XVI һәм XVII гасырларда вә хосусән XVIII гасырның башларында рус халкына Гарби Европа тәэсире көчәеп, бу нәүгы әдәбият түбән ташланган; вә Бөек Петр заманыннан башлап яңа әдәбиятның зоһуры *(мәйданга чыгуы)* сәбәпле болар дәхи читкә ыргытылган исә дә,

озакламыйча бу хәл алышынып, алар халык мосаннәфатына әһәмият күзе белән карый башлаганнар.

XVIII гасырда ук рус голяма вә әдәбасы *(галимнәре һәм әдипләре)*, бер яктан, боларны җыярга вә, икенче яктан, шуңа тәкълид *(иярту)* вә назыйрәләр *(охшатулар)* язарга башлыйлар. Бу хезмәттә булган адәмнәрдән тарих исемнәрен забыт кыйлганнарының *(теркәп калдырганнарының)* бәгъзеләре шулардыр:

а) Сахаров. Бу кеше «Рус халкының сүзләре» исемле халык мосаннәфатына гаид бер әсәр вөҗүденә китермештер.

б) Терещенко. Бу кеше «Рус халкының торышы» исемле бер әсәр язды.

в) Снегиревтер. Бу адәм «Рус гавымының бәйрәмнәре» вә «Рус мәкальләре» исемендә ике мәҗмуга язып, халык мосаннәфаты өчен мөһим бер хезмәттә булынмыштыр.

Унтугызынчы гасырда руслар буңа дәхи артык әһәмият бирә башлыйлар. Бу вакыт аларда халык мосаннәфатын җыю өчен махсус комиссияләр тәэсис кыйлына *(оештырыла, нигезләнә)* вә башкача тәшәббесатта булалар *(эшкә тотыналар, эш башкаралар)*. Бу хезмәт шул көннән бирү дәвам итә; голяма вә әдәбаның буңа игътибары арта барадыр.

Заманыбызның голямасыннан бу хакта көч сарыф итүчеләр эченнән шул адәмнәрнең исемнәрен атау мөмкин.

Мәсәлән: Академия әгъзаларыннан Веселовский, Соболевский, Жданов, профессор Миллер, Дашкевич, Халанский, Архангельский кебиләр.

Болар гавам мосаннәфаты илә иштигаль итеп *(шөгыльләнеп)*, аңа төрлесе төрле яктан карый вә төрле нәрсә эзлиләр. Бер кыйсьме шул халыкның җыр вә әкиятләреннән рус халкының борынгы мәҗүсият заманындагы хәлләренә гаид хатирәләр табарга тырышалар. Вә шул иштигальдән рус халкы мосаннәфатының Мифологическая школа[2] исемле кыйсьме вөҗүдә килә. Бәгъзеләр мондый мосаннәфаттан рус милләтенең тарихы белән шул әкият вә җырлар арасында тәнасеб *(бәйләнеш, охшашлык)* чыгарырга тырышалар. Вә шуннан Историческая школа[3] вөҗүдә киләдер.

Өченче кыйсем бу мосаннәфат илә халыкның үзара мөгамәләләре хакында мәгълүмат эзлиләр, вә моннан Заимствование[4] кыйсьме *(үзара йогынты (керешү) төре)* туадыр.

Моңа хезмәт шундый махсус адәмнәрнең вазифасында исә дә, башкалар да моңа кирәксез дип карамыйлар.

Рус дөньсы буңа гомумән якын вә әһәмият күзе саладыр. Рус әдәбиятына гаид нинди бур тарихны кулга алмагыз, һәммәсендә диярлек иң башлап шул әкият вә җырлар хакында бәхәс вә шулардан нәмүнәләргә очрала; бөтен кыйраәт китапларында иң башка шулар куелып, шәкертләргә гомумән тәгълим кыйлынадыр *(укытыладыр)*.

Шагыйрь, әдип, рәссам вә музыкантлар да боларны ерак ташламый; араларында бик сөеп караганнары да күптер.

Пушкин шул җен, пәри, су анасы вә шүрәле кебек мәүһүмат *(хыялый, фантастик затлар)* хакындагы гавам әкиятләрен вә халыкның башка кыйссаларын *(хикәя, хикәят, сөйләкләрен)* үзенең матур вә шагыйранә җөмләләре белән тасвир иткән. Кольцов, Некрасов, Достоевский, Толстой вә Никитиннар дә боларга бик сөеп карыйлар; әсәрләрендә йә нәсер вә йә шигырь белән шуларны биззат *(турыдан-туры)* язалар; назыйрә вә тәкълидләр вөҗүдә китерәләр. Рәссамнарның шул халык әкиятендә булган баһадир вә гаҗаиб адәмнәре хакында гүзәл тәрсимнәре *(рәсемнәре)* дә очраштыргалый.

Хасил *(нәтиҗәдә, кыскасы)*, мәдәни рус дөньясының һәртөрле ягында моңа әһәмият биреләдер.

(Халык мосаннәфатына мәгънәсез бер әкияттән башка нәрсә түгел дип караучыларыбыз күп булганга, бу бәянатка *(аңлатуларга)* мәҗбүрият күрелде. Бу фәлсәфәне ник сата? дип мөәхәзәгә *(шелтәгә)* ашыгылмасын.)

Килик үз дөньямызга!

Безнең халык мосаннәфатын берничә төрлегә бүлү мөмкиндер:

1) әкиятләр;
2) җыр вә бәетләр;
3) мәкальләр;
4) табышмаклар.

Әкиятләрдә ике төрле әсәр күренә; бере – мәҗүсият вә фетишизм әсәре. Бу кыйсемгә су анасы, шүрәле, җен вә пәри кеби заман җәһаләтнең илаһешшәрләре хакындагы әкиятләр керә.

Икенчесе – ислам әсәредер. Бу кыйсемгә Хозыр хакында, хәзрәти Гали, Гомәр гайяр *(гайрәтле, батыр)* кеби әкябире ислам *(исламның зур кешеләре)* хакында булган әкиятләр керәдер. Мәсәлән, хәзрәти Галинең дию вә әждаһа белә мөхарәбә *(сугыш)* кыйссалары кеби. Әкиятләр эчендә бу ике тәэсирнең беренә дә тәхсис *(туры килүе)* мөмкин булмаган Үги ана, Үги бала вә Таз малай кыйссалары да бар. Болар, бик ерак юл белән булса да, мәзлүмнәргә муаффәкыять *(кимсетелгәннәргә уңышка ирешү)* вә бәхеткә ирешү кеби әхлакый бер нәрсә тәгълим кыйладыр.

Бездә гавамның әкиятләрен тыңлаган тәкъдирдә бер тәэссефле хәлгә очраладыр. Һәр милләт үзенең борын заманда гомум өчен берәр эш эшләгән адәмнәре хакында бик күп әкият ихтирагъ кыйлган *(иҗат иткән)*. Мәсәлән: руслар үзләренең Олег, Владимир кебек тарихта мәгълүмрәк кешеләре, хәтта бик соң килгән Бөек Петрлары хакында әллә никадәр әкиятләр сөйлиләр, аларны фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* бер адәм ясыйлар. Бездә исә бу нәүгы әкият һич юктыр. Борынгы татар дәүләтләре, Болгар ханлыклары хакында халыкта һичбер нәрсә сөйләнми, аларның дөньяда булганын бөтенләй белмидер.

[…] Безнең халык үз илләрен күп кайгыртмаган булырга охшый. Хыялы фәкать дин әкябире вә мәшаих *(ишаннар, дин галимнәре)* хакында әкиятләр генә вөҗүдә китергәндер.

Хасил: дин хисе миллият хисен тәмам җингән. Шунлыктан, милләтнең үткәне вә аның әкябире көллиян *(зур, абруйлы кешеләре бөтенләй)* онытылып, мәҗһүлият *(билгесезлек)* пәрдәсе эченә кергәндер.

Халык мосаннафәтыннан җыр, табышмак вә макальләр мәгълүм нәрсә булганга, ул хакта сөйлисе юктыр. Болар яңа матбугатка да беркадәр таныштыр. Фәкать шул кадәресен хәтергә алганда ярый: мосаннәфатның мәнзүм *(тезмә)* кыйсьме гавам кашында икегә бүленә: берсе, дүрт мисрагътан *(шигырь юлыннан)* гыйбарәт булып, гомуми мәүзугълар хакындагы җырлардан гыйбарәт булмый, бәлки озын-озын касыйдәләрдән тәшкил кыйлына; һәм мәүзугълары җырлардагы кеби гомуми нәрсә булмыйча, катль *(үтерү)*, иртидад *(диннән чыгу)*, сугыш, солдатлык, суга бату вә башкача бер адәмнең бер хәсрәте хакында яки берәүгә һөҗү *(көлү-сатира)* өчен чыгарылган була, галибән *(күп очракта)* мәүзугъның исеме дә зикер кыйлынадыр.

*

Безнең халык боларга ничек карады? Хәзер дә ничек карый? Йокыдан яңа уянган бер кавемнән болар хакында әллә никадәр хезмәт көтеп булмыйдыр. Шөйлә исә дә *(шулай булса да)*, яңа матбугат кыйсьмән бик начар күз белән карамаган кебек тоела.

Бу турында һәркемнән артык мәшһүр шагыйребез Тукаевка бурычлыбыз. Ул үзенең матур вә шагыйранә җөмләләре илә шул гавам әкиятләрен тасвир итеп, һәркем тарафыннан сөелеп укырлык бер хәлгә куйды.

Мәсәлән: аның күптән чыккан «Шүрәлесе», Мәктәп мөкяфәтендәге *(Мәктәп бүләге сериясендәге китаплар мәгънәсендә)* Су анасы буның иң гүзәл нәмүнәләреннәндер.

Тукаевның бу шигырьләре шулкадәр ачык вә табигый чыккан ки, чи гавамның авазыннан да шулкадәр генә чыгар иде.

Үрнәкчеләрнең «Шәп җырлары»[6] вә аңа подделка *(ясалма охшату)* уларак чыккан башка җырлар һәм Уфа комиссиясенең «Иске җырлары»[7] да шу халык мосаннәфатын җәмыгъда җөзьи *(җыюда өлешчә, кисәкчә)* бер хезмәт саналырга мөмкиндер.

Ләкин бу җыр нәширләре бераз тәрәкъкый пәрвәрлек сатып *(яңартып, эшкәртеп)* эшне бозалар.

Бундый нәрсәләр никадәр простой *(гади)* вә мәгънәсез исә дә, гавамның үз авызыннан чыкканча җыелу тиеш. Аның бер кәмале *(җитешкәнлеге, төгәллеге)* дә шунда гынадыр. Матурлыйм дип аз гына үзгәрттеңме, аның бөтен әһәмияте югалып ук бетәдер.

Матбугатыбыз мәйданында халык мосаннәфатының җыелу хакындагы бөтен хезмәт шулардан гыйбарәт булып, болар шу кадәр аз вә

накыс *(ким)* ки: аларны авызга алу да башка бер хәрәкәт тә күрелмәгәннән генәдер. Милли әдәбият мөхибләре *(сөючеләре)* буңа зур әһәмият бирүләре матлуб *(тиеш)* иде.

Боларның, бер яктан, җыелуы, икенче яктан, яңа әдәбият эченә катыша башлануы тиеш иде.

Безнең зыялыларның күбесе әле гавам эченнән бөтенләй ерак китеп бетмәгән, вә аңлы адәмнәрнең беркадәресе чи гавам эчендә дә яшиләр. Шундый адәмнәребез халык авызындагы әкият, бәет, җыр, табышмак вә мәкальләрне бер дә үзгәртми җыя барсалар, милли әдәбиятымыз өчен бер хезмәт итмеш булырлар.

Боларның ни файдасы булыр, дип уйларга ярамый. Һәм алай уйламасалар да, мәдәни кавемнәрнең буңа әһәмият бирүләре безә гыйбрәттер.

а) Дөрест, болар безгә Гареб мәдәниятен вә заман фәлсәфәсен өйрәтмәс. Ләкин аларның файдасы икенче яктандыр.

б) Болар милли тел вә милли лөгатьнең бердәнбер хәзинәләредер. Болар эченнән татарча бик тугъры тасвирлар вә җөмләләр табарбыз.

в) Болар гавамымызның психологиясен белүдә бердәнбер чарадыр.

Болар гавамның һәр тарихы, һәм хиссият вә әфкяредер *(фикерләредер)*. Гавамның рухының көзгеседер.

г) Болар зыялыларга гавамны таныштыра; аларны гавамга бәйлиләр. Гавам белән зыялы арасында хасил булачак зур ераклык өчен бер дәвадыр.

д) Боларны кыйраәт китапларында урнаштырып, балага укыту балаларда бик яшьтән үк үз халкына якынлык уята. Аларны ихтыярсыз татар гавамына тартадыр.

е) Әдәбиятымызның реальный булуы, аның гавами *(халыкчан)* һәм мәгыйши *(тормышчан)* бер хәлгә керүе өчен зарур нәрсәләрдәндер.

Шуларны мөляхәзә итеп *(фикер йөртеп)*, бер, бер яктан, халык мосаннәфатын бер дә үзгәртми җыя барырга вә, икенче яктан, әдип вә шагыйрьләремездән Тукаевның «Су анасы» вә «Шүрәле»се кебек шигырь вә хикәячекләрнең чыгуын теләргә тиешлемез.

Тәхрир *(язу)* соңында: бу мәкалә күптән язылган булса да, гәзитәгә бирелүе төрле мәсаһәләләр *(игътибарсызлыклар)* илә шу көнгәчә кичекмештер.

Буның язылуыннан соң бездә халык мосаннәфаты хакында ике нәүгы яңа эш булды: берсе Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләренең лекциясе[8]; икенчесе: Вакытның[9] гавам әдәбияты җыеп, бер мәҗмуга нәшер итәргә карары вә шул хакта укучыларына илтимас *(үтенеч)*.

---

[1] *...хәзрәти Гали кыйссалары...* – Сүз Гали ибн Талиб (Гали батыр) турындагы дини-фантастик риваятьләр турында бара.

[2] *Мифологическая школа (Мифологик мәктәп)* – XIX йөз урталарында Көнбатыш Европа һәм рус фольклористикасында киң

таралган фәнни юнәлеш. Бу теорияне яклаучылар фольклорның нигезе итеп борынгы миф һәм риваятьләрне санаганнар.

[3] *Историческая школа (Тарихи мәктәп)* – фольклористикада XIX йөзнең ахыры һәм XX йөзнең башында Россиядә барлыкка килгән фәнни юнәлеш. Бу юнәлеш тарафдарлары фольклор әсәрләрен халыкның милли тарихы һәм көнкүреше белән бәйләп өйрәнүне алга сөргәннәр.

[4] *Заимствование яки күчмә сюжетлар теориясе* – фольклористикада өченче бер фәнни теория. Бу теория тарафдарлары төрле илләрнең фольклорыннан уртак сюжетлар эзләү белән шөгыльләнгәннәр.

[5] *Гомәр гаяр...* – Сүз Гомәр пәйгамбәр турындагы дини-фантастик риваятьләр турында бара.

[6] *Үрнәкчеләрнең Шәп җырлары...* – 1908 еллардан алып Казанда Үрнәк көтепханәсе (китап бастыру һәм сәүдә итү ширкәте) Менә сиңа шәп җырлар, Менә кайда шәп җырлар һ.б. исемнәр астында күп санлы җыр җыентыклары бастырып чыгара. Үрнәктән күрмәк бүтән көтепханә яки матбагалар да (мәсәлән, Бертуган Кәримевләр) җырлар җыентыклары бастыра башлыйлар. Монда сүз шул хакта бара.

[7] *Уфа комиссиясенең Иске җырлары...* – Уфада Галия мәдрәсәсендә укучы әдәбият сөюче шәкертләр, үзара бер комиссия төзеп, татар халык авыз иҗатын җыя башлаулары, бу эштә халыкның ярдәмен үтенүләре турында 1908 елда татар газеталарында игъланнар бастыралар. Шул комиссиянең эш нәтиҗәсе буларак, Уфада бер җырлар китабы дөнья күрә.

[8] *...Тукаев җәнабләренең лекциясе...* – Г.Тукайның 1910 ел апрелендә Казанда Шәрыкъ клубында халык әдәбияты турында укыган лекциясе. Ул 1910 елның 20 июнендә аерым китап булып басылып чыкты (Казан, Сабах көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы).

[9] «*Вакыт»* – 1906-1918 елларда Оренбургта Фатих Кәрими редакторлыгында чыккан буржуаз газета.

***Материал түбәндәге чыганактан алынды:***

Ибраһимов Г. Халык мосаннәфаты. Әдәбият мәсьәләләре. Әсәрләр, сигез томда, Т.5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.- Б. 23-30.

## 4. Фазыл Туйкинның татар фольклористикасы тарихындагы урыны.

1. Ф.Туйкинның халык иҗатын җыю, бастырып чыгару өлкәсендәге эшчәнлеге.
2. «Халык әдәбиятын тикшерү юлында» мәкаләсе.
3. «Ил әдәбияты» җыентыгын төзүе.

**5. Хәмит Ярми – татар фольклористикасы буенча беренче фән кандидаты һәм докторы.**

1. Х.Ярми (Ярмөхәммәтов) – беренче профессиональ татар фольклорчысы.
2. Галимнең «Татар халкының поэтик иҗаты» монографиясе.
3. Татар халык иҗаты 13-томлыгын төзүне башлап җибәрүче һәм берничә җыентык авторы булуы.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1.Бакиров М. Фольклорның гомуми үзенчәлекләре. Фольклор фәне һәм татар фольклористикасы / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 5-15.

2. Урманче Ф. Милли фольклористиканың формалашуы (18-20 б.). XX гасыр башында татар фольклористикасы (20-21 б.). Совет чорында фольклор фәне (21- 23 б.) Фольклор фәнендә яңарыш чоры (23- 27 б.) // Ф. Урманче Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – 355 б.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Бакиров М. Татар халык иҗаты. Программа / М.Бакиров // Мирас. – 2002. –№ 6. – Б. 44-66 .
2. Гайнуллин М. Каюм Насыйри (1825-1902) / Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 1 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974. – Б. 5-26.
3. Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормыш һәм иҗат юлы) / Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 7-50.
4. Мәхмүтов Х. Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том. – Казан: Татр.кит.нәшр., 2005.- Б. 3-14.
5. Надиров И. Татар фольклор мирасының фәнни җыелмасы. Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы. – Казан, 1988. – 87- 95 б.
6. Надиров И. Татарская фольклористика // 50 лет поисков и открытий. – Казань, 1989. – С.96-112.
7. Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы. СССР Фәннәр академиясе, Казан филиалы, 1988.
8. Ханнанова-Галимҗанова Э. Фазыл Туйкин: язучы, телче һәм фольклорчы. – Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2006. –156 б.
9. Хәмит Ярми. Галим һәм Шәхес: Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар (Төзүчесе Х.Мәхмүтов). – Татар.кит.нәшр., 2004.
10. Хөснуллина И. Дәвалау имләүләрендә өч саны // Түгәрәк уен. – 2012.- № 1. – Б.49-54.

**«Татар фольклористикасы тарихы» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. К.Фуксның татар фольклорын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
2. К.Насыйриның татар фольклорын үстерүдәге роле.
3. В.В.Радлов һәм аның татар халык иҗатына бәйләнешле хезмәтләре.
4. Х.Бәдигыйның татар фольклорын үстерүгә керткән өлеше
5. Ф.Туйкинның фольклорга караган хезмәтләре
6. Г.Рәхимнең татар фольклорын үстерүдәге роле.
7. Г.Тукайның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге.
8. Г.Бәшировның татар фольклорын җыю һәм бастыру өлкәсендәге эшчәнлеге.
9. Н.Исәнбәтнең татар фольклорына караган хезмәтләре.
10. Хәмит Ярми –беренче профессиональ татар фольклорчысы.
11. М.Бакировның халык авыз иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
12. Ф.Урманчеевның татар фольклорын үстерү өлкәсендәге эшчәнлеге.
13. Х.Мәхмүтовның татар халкының афористик иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
14. И.Надировның татар халык җырларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
15. Л.Җамалетдиновның халык әкиятләрен җыю, бастыру һәм фәнни өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге.
16. А.Садыйкованың «Ислам һәм татар халык иҗаты» монографиясе.
17. К.Миңнуллинның төрки халыклар фольклорындагы уртаклыкларны өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
18. Р.Ягъфәровның балалар фольклорын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
19. Хәзерге татар фольклоры үсешендә Республика традицион мәдәниятне үстерү дәүләт үзәгенең роле.
20. Хәзерге фольклористиканың актуаль мәсьәләләре.

## ТЕМА № 2. МИФЛАР ҺӘМ ЫРЫМНАР

Борынгы халыкларның көндәлек тормышында гаять зур роль уйнаган Мифларга бигеләмә бирү – бүгенге гуманитар фәннәрнең иң катлаулы бурычларыннан берсе. Хәзерге вакытта мифның 500 дән артык билгеләмәсе бар.

**Миф** ул – җәмгыятьнең, кабиләнең, аерым кешенең – дөньяны күзаллау рәвеше. Миф грекча *сүз, хикәят* дигән мәгънәне белдерә.

Мифларга бирелгән бернче билгеләмәләрдә үк аның әдәби әсәр булуына басым ясала. Миф төшенчәсе хәрәкәт, йола, гореф-гадәт, ышану, җыр-бию, драматик күренешләрнең барысын да үз эченә алса да, күпчелек мифларга хас конкрет эчтәлек нигездә прозаик хикәяләү аша гәүдәләнә.

Мифлар кешелекнең бала чагында, борынгы ыруглык чорында барлыкка килгәннәр. Бу чорда кеше үзен табигатьтән аерып карый белмәгән. Шуңа күрә үзенә хас сыйфатларны табигатькә, андагы җанлы һәм җансыз нәрсәләргә күчереп караган. Кеше һәм табигать – мифларның төп хикәяләү предметы. Кагыйдә буларак, табигать мифларда һәрчак җанландырып сурәтләнә. Борынгы бабаларыбыз бөтен дөньяны "кешеләштергән": җир, кояш, үсемлек һәм хайваннарны җанлы итеп кенә түгел, ә кеше шикелле үк яшәүче, фикерли һәм хисләнә белүче тереклек ияләре итеп, үзенә кардәш затлар итеп күз алдына китергән һәм мифларны да шундый фикерләүгә нигезләнеп иҗат тикән. Җыеп кына әйткәндә, мифологик күзаллаулар нигезендә ***анимизм*** (һәр табигать күренешенең иясе, алласы бар дип уйлау), ***тотемизм*** (хайваннарны һәм кошларны аллалаштыру), ***антропоморфизм*** (хайваннарга, үсемлекләргә, җансыз табигать күренешләренә һәм объектларына кеше сыйфатларын күчерү), ***магизм*** (аерым сүз яки гыйбарәләрнең, эш-хәрәкәт яки йолаларның көченә, аларр ярдәмендә табигать көчләренә, тирәлеккә йогынты ясап була дип ышану), ***фетишизм*** (амулет, бөти, тылсым мәгънәсендә; төрле әйберләрне, предметларны, аерым объектларны изгеләштерү) тәгълиматлары ята.

Ыруглык җәмгыятенең карашлар системасын тәшкил итүче мифологиядә галәмне һәм тирәлекне танып белергә омтылу, кешенең һәм төрле нәрсәләрнең ничек килеп чыгуын яки асылын аңларга тырышу мөһим бер функция булган.

Борынгы бабаларыбыз мифлар аша чынбарлыкны аңлатып кына калмаганнар, ә алар ярдәмендә тирәлекә, табигатькә тәэсир итәргә тырышканнар. Мифларны календарь йола бәйрәмнәре, хуҗалык эшләре вакытында башкару һәм аларның күбесендә хаостан космос төзелү, беренче башлап ут табу яки төрле әйберләр иҗат итү, табигать көчләре (төрле ияләр) белән туганлашу яки көрәшү, ыруглык тәртипләрен һәм социаль нормаларны яклау турында сүз баруы әнә шул хакта сөйли. К.Маркс күрсәтүенчә, һәртөрле мифология табигать көчләрен хыялда һәм хыял ярдәмендә җиңә, буйсындыра һәм формалаштыра. Шул ук вакытта, аерым мифларда, фантастик сюжетка һәм образларга төренеп, борынгы кешенең табигатьне беренче җиңүләре дә гәүдәләнә.

***Мифология*** сүзе фәндә ике мәгънәдә йөри. Беренчедән ул, борынгыларның дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары һәм хыялда туган фантастик образлар, персонажлар турында билгеле бер халыкта таралган мифларның җыелмасы. Икенчедән, төрле халыкларның мифларын өйрәнә торган фәнне мифология дип атыйлар. Ф.Урмачеев:

«Татарларда мифология фән буларак формалашкан дип әйтү дөрес булмас иде. Димәк, сүзне, нигездә, татар мифларының, яисә безнең халыкка хас мифологик күзаллауларның җыелмасы хакында гына алып барыррга тиеш булабыз» дип саный. Һәм татар мифларын өйрәнүнең төп чыганаклары буларак түбәндәгеләрне күрсәтә:

1. Мифологик әсәрләр, нигездә хикәятләр.
2. Халык иҗатының кайбер жанрлары: мәкальләр, табышмаклар, дастаннар, әкиятләр.
3. Туган тел берәмлекләре.
4. Археологик материаллар.
5. Башка халыкларның, аеруча төрки-монгол халыкларының мифологиясенә караган мәгълүматлар.
6. Сәяхәтче галимнәрнең тарихи һәм тарихи-этнографик хезмәтләренә теркәлеп калган материаллар.

Мифларны классификацияләүдә фикерләр күп төрле. Ф.Урманчеев татар халкында сакланып калган мифларны берничә төркемгә бүлеп карарга тәкъдим итә:

1. Хайваннар белән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен сурәтләгән мифлар.
2. Галәм, җиһан төзелеше, Ай, Кояш, Йолдызлар белән бәйле мифологик күзаллаулар.
3. Алла, алиһәләр һәм мифологик персонажлар белән бәйле хикәятләр.
4. Түбән мифология персонажлары. [Урманче, 2003: 31].

Фольклор һәм әдәбият галиме Марсель Бакиров төрки болгар-татар мифологиясен түбәндәгечә төркемләргә тәкъдим итә:

«Галәмнең, табигатьтә һәм социаль тормыштагы төрле җансыз һәм җансыз объект-күренешләрнең ничек барлыкка килүен аңлатучы мифлар, киң планда алганда, ***этиологик*** (грекча *aitia*– сәбәп) мифлар булып исәпләнәләр. Борынгы мифларның зур күпчелеге шушы төркемгә керә һәм алар, үз чиратында, тагын да  ваграк төркемнәргә бүленә.

***Космогоник мифлар*** галәмнең һәм аның аерым өлешләренең ярытылуын һәм төзелешен аңлаталар.

Ай белән кояш һәм йолдызлар турындагы, ягъни, фәнни термин белән әйтсәк, ***соляр*** (латинча solarium – кояш) һәм ***астраль*** (латинча astralis– йолдызлы) мифлар. Боларда сүз әлеге күк җисемнәренең яратылуы яки аларның аерым сыйфатлары турында бара.

***Антропогоник*** һәм ***этногоник*** (грекча gone / gonos– яралу) мифлар кешенең һәм аерым ыруг-кабилә яки халыкларның барлыкка килүен аңлатуга корылганнар.

***Хайваннар, кош-кортлар, үсемлекләр*** дөньясына бәйләнешле этиологик мифлар флора һәм фауна дөньясына мөнәсәбәтле мифологик-фантастик хикәялардән тора(кеше җанының күбәләккә әйләнүе, абага

чәчәгенең җиде төн уртасында чәчәк атуы һәм аны ашасаң күренмәс кешегә әверелү мөмкинлеге һ.б.).

***Культура геройларына бәйләнешле мифлар*** (грекча *cultura*– эшкәртү, кайбер борынгы телләрдә – кул/ рука, димәк, кул белән эшкәртү) әлеге геройлар һәм шулар белән керешүче демиург (грекча *demiurges* төзүче-ясаучы, халык өчен иҗат итүче) дигән персонаж тарафыннан беренче башлап булдырылган һәм беренче итеп ясалган яки барлыкка китерелгән объект-күренешләр турында сөйләнелә. Һәм әлеге рәткә, өлешчә генә булса да, героик архаик эпос-дастан геройларының, хәтта идеаллаштырылган аерым тарихи шәхесләрнең мифик аң белән өретелгән эшчәнлеге дә килеп ялгана.

***Календарь мифларда*** ел фасылларына, табигать һәм борынгыларның хуҗалык циклларына бәйле рәвештә формалашкан магик-мифологик күзаллаулар бәян ителә. Аларның күбесе махсус йолаларны оештыруга хезмәт итә һәм шулар белән үрелеп гәүдәләнә. Бабаларыбызның мифологик карашларына нигезләнгән һәм төрле йолалар белән үрелгән 12 еллык хайван календаре; яз килүне тизләтү өчен карга боткасы пешерү һ.б.

***Дини мифлар*** ортодаксаль диннәр йогынтысында туган ышанулардан һәм әлеге диннәрдәдә, борынгыдан килүче мифологиядә дә урын алган шәхесләр турындагы хикәятләрдән гыйбарәт. [Бакиров, 2008: 29-31].

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

**Тема: Ырымнар**

1. Ырымнар. Аларның магик табигате. Жанрның үзенчәлекләре. Ырымнарны төркемләү. Ак һәм кара ырымнар. Дәвалау ырымнары яки им-томнар. Хуҗалык ырымнары. Иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлтелгән ырымнар.
2. Ырым текстларының төзелеше, поэтикасы һәм стиле. Ырымнарны җыю һәм өйрәнү тарихы. Ырымнарның мифология белән турыдан-туры бәйләнеше.
3. Фаллар. Магик йола белән ырым традицияләре очрашкан урында туган булырга тиеш дип фаразланган жанр булуы. Фал ачтыруның сәбәпләре. Татарлардагы фал ачу ысуллары. Фал ачу урыннары. Ырымнарның йола фольклорындагы урыны.
4. Сез яшәгән төбәктә им-том белән шөгыльләнүче кешеләр бармы? Ырым текстлары язып килегез.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1. Бакиров М. Мифларның тарихи нигезләре һәм үзенчәлекләре. Ырымнар / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б. – Б. 19-47.

2. Урманче Ф. Татар мифологиясе // Ф. Урманче. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – 355 б.- Б. 30-52.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Гыйләҗетдинов С. Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – Б. – 5-18.

2. Давлетшина Л.Х.Мифологизм в татарской прозе конца XX–начала XXI в. – Казань: Школа. –2006. – 140 с.

3. Закирова И. Космогоник миф һәм легендаларның телдә сакланган эзләре // Фолькор теле – шигърият теле. – Казан: Фикер, 2001. – Б. 67- 76.

4. Кариева Л. Татар мифологиясендә илаһи образлар (типологик яссылыкта) / Типология татарского фольклора.- Казань: Издательство Мастер-Лайн, 1999. – С.138-155.

5. Кариева Л.А. Татарская мифология (в историческо-сравнительном и типологическом аспекте): автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата филологических наук.2003.

6. Мифы народов мира. Энциклопедия в 2-х т. Т.I. Москва: Сов. энциклопедия - 1991, Т.2. – 1992.

7. Татар мифлары. 1 нче китап (төзүчесе Г.Гыйльманов). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1996.

8. Татар мифлары. 2 нче китап (төзүчесе Г.Гыйльманов). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1999.

9. Урманче Ф. Татар мифологиясе аңлатмалы сүзлеген төзүнең төп прининплары // Фолькор теле – шигърият теле. – Казан: Фикер, 2001. – Б. 3-22.

10. Урманчеев Ф. Татар мифологиясе // Фәнни эзләнүләр юлында.– Казан: Фикер, 2000.

11. Шәмси С. Татар мифологиясенең популяр образы // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. Казан, 1984. – Б. 142-153.

***Чыганаклар*:**

1. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А-Г) / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

2. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д-С) / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2009. – 343 б.


3. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1т. (С-Я) / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2011. – 199 б.


**Соңгы еллардагы фольклор практикасы вакытында тупланган ырым текстларыннан кайбер үрнәкләр:**

**Информант:**
*Шакирова Рафизия Нуригыйльман кызы*
*1928 елгы, 8 сыйныф белемле*
*ТР Балтач районы Арбор авылы*
**Язып алучы:** *Шакирова Зөһрә Камил кызы,*
*ФһсИ КФУ Татар филологиясе бүлеге студенты*

***<u>Сөялне имләү:</u>***

Сөялле кеше кояш баешына карап туп- туры утыра. Имләүче кеше сөялле кешенең баш түбәсенең чәч түгәрәгеннән үкчәсенә кадәр тип- тигез итеп, җеп өзеп ала.





Җепне үлчәп алганнан соң:

- Бу Фәлән Фәлән улы/ кызының буй озынлыгы, -ди.

Җепнең очыннан тотып, төйнәгәнен уң якка таба куеп, сул якка таба 41 төйнәргә.



Төеннәр сөялнең өстенә куеп төйнәлергә тиеш. Сөялне имләгәндә бер сүз дә әйтелми. Имләп бетергәннән соң, төйнәлгән җепне тиз черә торган урынга күмәсе. Авылда аны гадәттә мунча ләүкәсе астына күмәләр.Имләүче кеше күмсә дә, сөялле кеше үзе күмсә дә килешә. Шул җеп череп беткәндә сөял юкка чыга.

Сөял тизрәк бетсен өчен тиз черә торган һәм нечкә җеп сайларга кирәк. Әгәр төйнәгәндә өзелмәсә, ефәк җеп тә ярый.

Җебен үлчәп бирүче булса һәм сөял кулда булмаса, кеше үзен-үзе дә имли ала.

***Арпа имләү:***

Кирәкле әйберләр: 1 тиен, 3 тиен, 5 тиен (так тиен)

Имләүче кеше: «Фәлән Фәлән улы/ кызының сул/ уң күзенең асты/ өстенә арпа чыккан арпа имлим»,– ди.

Аннан соң акчаны алып, арпа өстенә ышкыйсы һәм түбәндәге сүзләрне әйтәсе:

•1дән 9га кадәр саныйсы һәм «туфракка китсен» дип, сул якка өч тапкыр төкерәсе

•1дән 7гә: «җиде юл чатына китсен»

•1дән 5кә: «бизеп китсен»

•1дән 3кә: «очып китсен»

•1: «берлексез булсын, бетсен– китсен»

Имләп беткәннән соң, имләнүче кеше, акчаны сул кулына тотып, сөйләшмичә, җиде юл чатына чыга. Чыгып җиткәч, өенә кайтыр якка борыла һәм сул кулы белән акчаны ыргытып китеп бара. Киткән чакта:

«Мине ашамагыз,
Мине эчмәгез.
Шушыны ашагыз,
Шушыны эчегез!
Сезгә азык – миңа саулык»,– дип әйтә.

Аягы белән үзе йөри алмаган кешене яки балаларны имләгәндә, имләүче акчаны үзе ташлый һәм ул кайтып, «шап!» итеп утырмыйча, имләнүче тик утырырга тиеш.

Акчаны имләнүче ташласа да, имләүче ташласа да барганда-кайтканда кеше белән сөйләшергә ярамый. Им-томны матча турына, кояш баешына карап имләү яхшы.

***Су тотуны имләү:***

Су өстенә әйтергә ярамый. Су өстенә әйтсәң, су тота, сызлавык чыга, чабырып кычыта һәм башка шундый авыртулар килә.

Әгәр дә су тотса, имләмичә торып, авырту бетми.

Су тотуны имләү өчен кирәкле әйберләр: чи җеп (җегерләмәгән сүс, ягъни пачас), колмак, көл, күмер, ватмыйча алган ат тизәге (булса, ат дагалаганда төшкән кадак бик яхшы), кәгазь.

Чи җепне җеп шикелле нечкә итеп сузып (өзелмәсен өчен төкрек белән сылап боргаласаң да ярый), авырту кешенең баш түгәрәк җиреннән алып үкчәсенә кадәр үлчисе. Бу вакытта: «Фәлән Фәлән улы/ кызының буй озынлыгын үлчим»,–дип әйтәсе. Сөйләшергә, җеп өзелсә төйнәргә ярамый. Гомумән, җеп өзелергә тиеш түгел.

Шуннан соң сүсне урталай яки өчкә бөкләп саласы, өстенә зур булмаган (0,5 дәфтәр бите кадәррәк) кәгазь куясы. Имләр өчен колмак, көл, күмер, ат тизәге, дага арасыннан өчесен аласы (кайсы бар). Өч предметны да аерым- аерым кәгазьгә төрәсе. Көлне алганда сул кулның өч бармагы белән аласы, әз дип өстисе, күп дип кире алып куясы түгел.

Әзерлек эше беткәч, имләү башлана. Һәр әйберне имләнүче кешенең башта биленнән, аннары тездән, аннан соң аяк очыннан уңнан сулга 3 тапкыр әйләндереп чыгарасы. Шул вакытта өчесендә дә болай дип кабатлыйсы: Моңа кем кагылды? Кагылмагыз!

Су анасы сылу бикә,
Җир анасы җирән бикә
Фәләнгә кагылмагыз
Фәләнгә тимәгез,
Шушыны ашагыз,
Шушыны эчегез!

Имләп бетергәч, өч әйберне дә сүс өстендәге кәгазьгә куеп төрәсе һәм сүс белән чорныйсы. Бу әйберләрне су кырындагы таллар арасына яки яр астына ташларга кирәк. СУГА ТАШЛАРГА ЯРАМЫЙ!!! Барганда кайтканда кешегә эндәшмәскә.

***<u>Зәхмәт кагылуны имләү:</u>***

Кеше чат башында, чүплекләрдә егылса, әшәке сүз әйтеп түгел, ә бисмилла әйтеп торырга тиеш. Әшәке сүз әйтә икән, шайтан килеп, зәхмәт ияртә.

Торып, егылган урынга өч тапкыр төкереп бисмилла әйтмичә «Пәригә авырлык, миңа җиңеллек»,– дияргә кирәк.

Егылганнан соң авыртып йөрсәң, сызлансаң, зәхмәт кагылган була.

Зәхмәт кагылганны имләр өчен кирәкле әйберләр: көл, су, савыт

Стакан кадәрлерәк бер савытка сул кулның өч бармагы белән көл саласы. Әз дип кабат өстәргә яисә күп дип кире алырга ярамый. Көл өстенә ярты савыт су саласы. Суны шулай ук чамалап алырга кирәк, чөнки кире алырга, калдырырга ярамый.

Имләү тәртибе: су белән көл салынган күлмәкнең алдагы изүеннән кертеп, аяк очына кадәр өч тапкыр үткәрәсе. Бу вакытта «Мине ашамагыз, мине эчмәгез.Шушыны ашагыз, шушыны эчегез»,– дип әйтәсе.

Кеше йөрүдән туктагач эшләнсә яхшы. Егылган урынга илтеп ыргытасы. Барган юлдан кайтасы, сөйләшергә ярамый.

Кеше үзен үзе имләсә бигрәк тә килешә. Булдырмаса, имли белгән башка кеше имләсә дә ярый. Барысы өч тапкыр эшләнергә тиеш.

***Куркулык кою:***

Яшь балалар курыкса (хәтта төштә), үсә алмыйлар, борчылалар. Зур кешеләр дә нәрсәдәндер бик каты куркырга мөмкин. Каты итеп егылганда да эчкә шайтан керә. Куркулыкны эчтән шайтанны чыгарыр өчен эшлиләр.

Кирәкле әйберләр: май эртү өчен чүмеч, салкын су салу өчен тирән зур аш тәлинкәсе кирәк, һәр чүмечкә зур әчтерхан чикләвеге кадәр эретеп кыздырылган сарык мае, чүмечкә май чәчрәп ут капканда утны сүндерү өчен капкач, куркылык коясы кешене каплау өчен ак җәймә (бите, башы, гәүдәсе май чәчрәмәсен өчен каплана), кургашын.




Кыздырылган сарык мае




Кургашын




Япма




Чүмеч




Аш тәлинкәләре


Куркулык койганда авыл өйләрендә өйнең морҗасы ачык булырга тиеш. Өй эчендә ике кеше генә булсын, әгәр дә булышырга кирәк булса, үзеңнең иң якын кешең булса ярый. Ләкин сөйләшмәскә кирәк.

Кургашын салып кыздырган майны ишектән 1-3 тапкыр тыгып: «Ишектән дә кер котым,

Тишектән дә кер котым,
Каян чыксан, шуннан кер,
Елан күк сузылып кер,
Тасма күк сузылып кер»,– дип кабатлыйсы. Бу эш бик кызу эшләнергә тиеш, чөнки кургашын белән май суынса, сурәт барлыкка килми.

Куркулык өч тапкыр коела. Бер койганда гәүдәнең 13 өлешенә (санына) эшләнә:

1. Баш
2. Уң җилкә
3. Сул җилкә
4. Уң терсәк
5. Сул терсәк
6. Уң кул очлыгы
7. Сул кул очлыгы
8. Уң янбашы
9. Сул янбашы
10. Уң тез башы
11. Сул тез башы
12. Уң аяк очлыгы
13. Сул аяк очлыгы



Һәрберсе саен «Фәлән кешенең фәлән төшенә куркулык коям»,- дип әйтәсе. Салкын сулы савытны куркулык коела торган урынга куясы, онытылып майны кеше өстенә кою куркынычы бик зур.

Салкын суда чираган туң майны аерым бер савытка җыеп барасы. Кургашынны койган саен яңа майда эретәсе. Кабат бер ереткән майны салсаң, чәчри, чыжлый. Кургашынны майга салу белән, өстен капларга кирәк, чөнки ут каба. Сурәт чыккан саен куркылык коелучы кешегә күрсәтеп барасы, ә иң соңгысын төреп аның йоклый торган урынына баш астына салырга.






Коеп бетергәч, маен калдырып, тәлинкәдән кырык бер тамчы суны алып, Әлхәм, Колһуаллах укып өшкерәсе һәм куркулык коелган кешегә эчертәсе. Маен да кырык бер кисәккә бүлеп, он белән әвәләп ашатырга кушалар, ләкин аны ашау бик авыр булу сәбәпле, кошларга бирәсе яки чиста урынга күмәсе.



***Авызсым авыртуын имләү:***

Авызсым – авызның ике чите даими рәвештә кабатланып чиләнеп тару. Аны имләмәсәң, гомер буе кабатланып тора. Әмма аны дәваларга мөмкин. Бу эш түбәндәгечә башкарыла:

Су чиләгенә чиста су саласы. Чиләк кырына ат авызлыгы (ат сбруясының бер өлеше – ат җиккәндә кулланыла) куясы. Шуннан соң, авызсым булган кеше, ат булып кешнәп җибәрә һәм авызлык аша үткәреп, чиләктән суны эчә.

Әлеге им-томны, авызсым бетмәгән очракта, 3 тапкыр кабатларга кирәк. Ул, һичшиксез, бетәчәк дип ышанганнар.


***Баш аву:***

Күбрәк түбән карап эшләгән кешеләрдә була торган авырту. Күңел болганган шикелле булып, чәнчеп, бик каты баш авыртса, баш ауган була. Күзләр дә чәнчә.

Аны имләр өчен юкә мунчаласы кулланыла. Шуны тип- тигез итеп, маңгайдан алып арт муен чокырына хәтле (тигез итеп, кыекламыйча) бәйләргә кирәк.



Шуннан колак яфрагындагы башланган җиргә, маңгайның нәкъ уртасына корым тиерәсе. Аннары кайсы якка ауганын шуннан үлчәп беләсең.




Башта ике колак турыныкын карыйсың: алга ауганмы, арткамы; аннары маңгай белән артныкын карыйсың: кайсы якка ауган – уң яккамы, сул яккамы? Шуннан мунчаланы, төенен чишмичә, баш турында өзгәлисең.




«Фәлән кешегә килмәгез, әйдә бар, каян килсәгез- шунда китегез»,– дип, ул мунчаланы учта бераз бөтергәлисең дә (баш миенең тамырлар шикелле була торгандыр инде, диләр) капкадан чыгасың да, сул кул якка ыргытасың, Әйдә бар, йөрмә, килгән җиреңә кит, дип әйтәсең.

Озынрак сөлге алып, башка арт яктан бер тапкыр бәйлисең дә, аннары чорнап- чорнап сөлгене бөтереп куясың.





Шул төен өстенә өч тапкыр сугасың .



Һәм башы ауган кешене 20 минутка чалкан яткырасың. Баш ауган булса, шушы им-томны башкарганнан соң баш авыртуы бетә.

***<u>Күз тию:</u>***

Күз тигән кеше хәлсезләнә, борчыла, тәне дә чуанларга мөмкин. Мондый очракта аны таң суы белән коендыралар яки өшкерәләр. Әмма күз тиюгә каршы дәвалау ырымы да кулланыла. Аны мондый тәртиптә башкаралар: ярты чокыр чамалы су аласы. Кулны шул су белән юешләп, урам якка караган өч тәрәзәне кул белән чылатып, ышкыйсы. Һәр ышкыган саен кулны яңадан чылатырга кирәк. Аннан соң морҗаның, морҗа булмаган очракта өстәлнең өч ягын, тәрәзәне чылаткан кебек үк чылатасы. Нәкъ шул рәвешле, ишекнең өй эчендәге тоткасын өч тапкыр, ишекнең

тышындагы тоткасын өч тапкыр чылатасың. Әлеге суны баланың баш очындагы бөтерчеккә сөртәсе, күкрәкләренә, кендегенә, уң һәм сул терсәгенә, кул очлыкларына, уң һәм сул тез башына, уң һәм сул тәпи очларына тидерәсең.

Бу эшне бала йоклап китә алмый елаганда эшләргә кирәк. Бу ырымны эшләгәч, бала тынычлап йоклап китә.

Әгәр дә өйдәге тәрәзә өч бүлемле булса, бер генә тәрәзәне дә сөртергә мөмкин. Шулай ук бер бүлемле тәрәзәнең өч почмагын сөртеп эшләргә дә ярый, диләр.

Имләгәч калган суны ишектән чыгып, сул якка ташлыйсы.

***<u>Чәнчү:</u>***

Чәнчү авыртуы – артыш ылысы чәнечкән кебек бөтен эчнең чәнчеп авыртуы дигән сүз. Аны имләү өчен уклау кулланыла.

Кешене аякларын кояш баешына таба каратып сузып яткырасы. Имләүче кеше авыруның уң ягына баса һәм имләнүченең корсагы буенча уклауны сулга таба ышкып,

- 1дән 9га кадәр саныйсы һәм «туфракка китсен» дип, сул якка өч тапкыр төкерәсе
- 1дән 7гә хәтле саныйсы һәм «җилгә китсен» дип, сул якка өч тапкыр төкерәсе
- 1дән 5кә кадәр саныйсы һәм «бизеп китсен» дип, сул якка өч тапкыр төкерәсе
- 1дән 3кә кадәр саныйсы һәм «очып китсен» дип, сул якка өч тапкыр төкерәсе
- 1 дип әйтәсе һәм «берлексез булсын, бетсен- китсен, җиде кат җир астындагы җир асты кондызларына китсен» дип, сулга өч тапкыр төкерәсе.

Имләп бетергәннән соң, авырган кеше 15-20 минут ятып торырга тиеш. Әгәр тәмам уңайланып җитмәсә, өч тапкыр имләргә кирәк.

***<u>Миңле булып туган баланың миңен бетерү:</u>***

Кайбер балаларның тәнендә туганда ук кызыл, яисә кара таплар, шулай ук борчак кадәр зурлыкта күз төбенә үскән итләр була. Бу таплар шактый зур була һәм ямьсез булып тора. Аны миң дип атыйлар. Муенда булган очракта, пычак кискән кебек чиләнеп, канап та торырга, күз янында булганда күзләре начар күреп, гел авыртып торырга мөмкин.

Әлеге миңнәрне бетерү өчен балага «миң» кергән исем кушарга кирәк.

Түбәннән пич авызыннан берәү кычкырып сорый: «Ни исемле кушасың?» − ди, чуар агач кашыкны мич башыннан (морҗада ачыла торган, ябыла торган юшкә тишеге) мич авызына төшерәсе һәм шул вакытта миң кергән исем – я үз исеменә миң өстисең, я икенче миң кушкан исем – әйтәсең. Шул чуар кашык белән берничә көн балага ризык ашатырга кирәк.

Ул, азан әйтеп, мулла кушкан исемгә туры килми, шуңа күрә исемне бозу диндә рөхсәт ителми. Ләкин чарасыздан эшлиләләр, ул төзәлеп китә. Соңгы юлга озаткан вакытта мулла азан әйтеп кушкан исем белән укып озаталар.

***Баланы мунча кертү:***

Баланы иң беренче тапкыр мунча керткәндә олылар – әбисе, я билгеләнгән аерым кеше юарга тиеш. Мунчага алып кергәч, исемен әйтергә ярамый, җен зәхмәте кагыла. «Бүре баласы. Бүректән аласы, бүреккә саласы» дип кенә әйтергә кирәк. Миллек белән чапканда: «Таш күк таза булсын, корыч кебек чыныксын» дип чөңгереп-чөңгереп ташка түкерәсе. Бала өчен бияләй зурлыгында гына аерым миллек бәйләргә кирәк. Шулай иткәндә бала сау-сәламәт, тыныч була диелә.

***Күз тию, җен кагылудан:***

Моннан тыш, артыш агачы җен китерми, зәхмәт ияртми, миләш агачы күз тиюгә каршы тора дип тә әйтәләр. Күз тиюгә каршы шулай ук уң җилкәдән алып, сул җилкәгә кадәр тагыла торган хәситә булыша дигән ышану да бар.

***Таң суы алу***

Таң суы алу тәртибе: кыш көне булса, агымга каршы 41 чүмеч (тулы итмичә) кар, җәй көне булса, су аласы.

Бисмилла әйтәсе, суны таң алдыннан аласы. Агымсу ерак булса, кичтән табак белән урамга су чыгарып куясы һәм шул суны алып керәсе. Су 3-5 литр җитә.

Чиста тәнгә, кешене табакка бастырып, өстенә коясы. Суны тапталмый торган урынга агач төбенә түгәсе. Ахырдан әлеге кешене өшкерәсе.

## ***Чүпрәле районында тупланган ырымнар***

### **Балага күз тигәндә**

**Информант:** Хәсәнә Гайсина Зиатдин кызы, 1928 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Татар Бизнәсе авылы, 2012 ел.

Балаларга күз тимәсендә баш очында Коръән сурәсе тора, петү дә язалар.

Күзеккән балага пасуда юган суларны берцәк битенә сибәләр инде. Ырым бу.

Күз тимәсеңгә корым да сөртәләр.

### Балага күз тигәндә

**Информант:** Мәхмүтова Бибинур Юныс кызы, 1931 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шланга авылы, 2012 ел.

Таң суын таң аткынча, истинҗа алып, ару, пакъ коедан алырга. Аннары аны укырга белгән догалар белән. Шул суга өрә барасың. Аннары шул суны күзеккәннең башыннан сөртәсең, коена торган суына саласың, и калганын авызына, битләренә, башларына сөртәсең инде.

Күз тидерүченең нинди дә булса чүпрәген алырга кирәк. Аны төтәштереп балага иснәтергә кирәк.

### Куркулык коюю.

Кургашын кайнатып салалар. Кеше нәрсәдән курыкса, шуның рәсеме килеп чыга.

### Эч авыртканда, кату чыкканда.

Карлыгач оясын аласың да, чүпрәккә чорнап җылытып, корсагына куясың. Анда төрле төштән җыелган балчык булганга, бик файдалы.

### Күз тигәндә

**Информант:** Ильязова Наилә Шиһап кызы, 1940 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шланга авылы, 2012 ел

Күз тимәсенгә, чәчен тугач та кыркып, петү ясап куялар тупыена (башлыгына). Шулай ук су алып, тәрәзәләрне, ишек бауларын юып, шул су белән бәбинең битен, корсакларын, башын сөртәләр. Күз тигәне бетә.

### Күз тигәндә

**Информант:** Миңнебаева Нәзирә Миркасыйм кызы, 1939 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шланга авылы, 2012 ел

Тәрәз рамнарын, ишек бауларын жуып, джүеш куллар белән сөртеп кендекләренә, битләренә сөртә идек.

### Бүсер

**Информант:** Миңнебаева Нәзирә Миркасыйм кызы, 1939 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шланга авылы, 2012 ел

Бүсер сыны ясап, шуны язуга язып та юып эчерәләр. Аның үз дәвасы бар. Андары соң буена да эләләр дияләр иде.

## Аяк авыртудан

**Информант:** Миңнебаева Нәзирә Миркасыйм кызы, 1939 елгы,
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шланга авылы, 2012 ел

Кем аягын каймыктыра, төньякка таба су бәрәләр иде. Аягыннан 3 мәртәбәме, 7 мәртәбәме әләндерәләр, аннары бил турысыннан, аннары баш турысыннан су белән әләндерәләр. Аны төньякка бәрергә. Илаһи, үзеңнең шифаңны бир дип әләндерәләр дә, шылай бәрәләр инде.

**Информант:**
Шиһабетдинова Рабига Насыйбулла кызы,
1933 елгы, *Иске Задур авылы*
,

## Күз тигәндә

**Информант:** Шиһабетдинова Рабига Насыйбулла кызы, 1933 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Иске Задур авылы, 2012

Бик яшь баланы кешегә күрсәтмә, каты күзле була, диләр. Күз тиюдән укыта идек. Күз тимәсенгә әбидән укытып, түмә тага идек круг итеп, корым буей идек.

## Балага күз тигәндә

**Информант**: Камалова Фәүзия Идиятулла кызы, 1951 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шәйморза авылы, 2012

Имән гөмбәсе, 40 төрле чүпрәк, 40 штук чыра. Шушы өч әйбернең берсен аласың да, ут төртеп бераз яндырасың. Шуннан чыккан төтен белән түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә баланы төтәштерәсең (төтәслисең):

Име-томы шул булсын,
Кемнең күзе тисә, шул чыксын.
Зәңгәр күз, яшел күз, кара күз,
Барыгыз да чыгыгыз.
Өф-өф-өф. (өреп җибәрәсең).

## Тимрәү (лишай) имләү:

**Информант**: Камалова Фәүзия Идиятулла кызы, 1951 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шәйморза авылы, 2012

Күмер, акча, ашык (сарыкныкы) алып, өч предметны өч көнне тимрәү тирәсендә түбәндәге сүзләре әйтеп, әйләндерәсең:

Әм-әм-әмрәмүнә,
Тим-тим-тимрәмүнә.

Ай кайта, көн кайта,
Тимрәү булсаң, син дә кайт.

### Күзгә арпа чыкса

**Информант**: Хисамова Гөлшат Сафи кызы 1940 елгы,
Халилова Гөлшат Шакирҗан кызы, 1949 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә
Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы**,** Шәйморза авылы, 2012

Арпа я балан белән өшкерәләр. Арпа тирәли догалар укып әйләндереп өшкерәләр.

### Бүсер

**Информант**: Хисамова Гөлшат Сафи кызы 1940 елгы,
Халилова Гөлшат Шакирҗан кызы, 1949 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә

Көмеш акча бәйләп, марля белән бәйләп куялар.

### Күз тигәндә

**Информант**: Хисамова Гөлшат Сафи кызы 1940 елгы,
Халилова Гөлшат Шакирҗан кызы, 1949 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә

Чашкага су аласың, тәрәзәләрне, ишек тоткаларын ышкыйсың. Шул су белән баланы туп-туры гына 3 мәртәбә сөртеп төшерәсең. Аннан соң:
Ияңне тап,
Каян килдең, шунда кит, диеп, тупсага бәрергә.

### Сөял имләү

**Информант**: Хисамова Гөлшат Сафи кызы 1940 елгы,
Халилова Гөлшат Шакирҗан кызы, 1949 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә

Җеп алып, сөял өстендә кырык тапкыр төен төйнәп, юешлеккә бәрергә. Җеп чергәч, сөял бетә.
Имләгәндә биштән бергә хәтле кирегә саныйсың.
5, 4, 3, 2, 1
4, 3, 2, 1
3, 2, 1
2, 1
1, 1, бердән кйта, сүәл булсаң син дә кайт, дип әйтәсе

### Куркулык кою

**Информант**: Хисамова Гөлшат Сафи кызы 1940 елгы,
Халилова Гөлшат Шакирҗан кызы, 1949 елгы
**Язып алучы:**ФҺСИ студенты Шакирова Зөһрә

Баланы матча турысына утырталар. Кургашынны эретеп, табакка суга салалар: баш очына куеп. Баланың исемен әйтәсе.

- Кемгә курку коясың?
- Шуңарга курку коям?

Шуларны 3 тапкыр кабатлап әйтәсе.

Аннары: Имең-томың шул булсын,

Каян килдең, шунда кит, дип, төньякка суны бәрәсе.

Әгәр төзәлмәсә, 3 мәртәбә эшлисе. Нәрсәдән курыкса, кургашында шул рәсем чыга.

Ай кайта, көн кайта,

Авыру булсаң, син дә кайт, дип, 3 тапкыр әйтәсе.

## Студентларның кыр фольклор практикасы вакытында тупланган мифологик хикәятләрдән кайбер үрнәкләр

### Елан белән карлыгач

**Информант:** Турушев Рашид Абдульмучин улы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты
Аллабердеева Нелли Йосыф кызы
Төмән өлкәсе Вагай районы Вершинские авылы, 2008 ел.

Безнең пәйгәмбәребез күлдә бара, бара торган көймәсенең бер ягы тишелеп чыга, көймәне су ала. Шул вакыт елан йөзеп бара. Еланга эндәшә пәйгәмбәребез Зинһар коткар мине, елан коткаруын коткарам, тик түгел. Шулай кырга чыккач, елан әйтә мин бөтен дөньяда кем бар, аларның каннарын тәмләп чыгасым килә. Шуннан соң пәйгәмбәребез карганы җибәрә, карга юлда, үтенечен үтәмәен, үлемтек күреп эеп, үлемтеккә ташлана, бурычын оныта. Озаксынып, чебенне җибәрәләр, чебен бөтен дөньяда исән-сауларның канын тәмләп чыга. Чебенне озаксынып карлыгачны очыралар, юлда карлыгач чебенне күреп ала, сорый чебеннән – карлыгач белеп алдыңмы кемнең каны тәмле, белеп алдым ди, чебен әйтә кешенең генә тәмле икән каны, калганнарның алай түгел. Карлыгач әйтә Әйтә телеңне чыгар, миндә тәмләп ийәен, чебен телен чыгарып иеүгә, карлыгач йотып та куя чебеннең телен, чебен телсез кала. Менә аннан соң чебен телсез калып м-м-мләп генә йөри башлый, ә карлыгач кайтып килеп еланга болай әйтә. Иң тәмлә дөнья йөзендә кан, бакаларның, ящерицаларның, хомякларның, тычканнарның, ә кешенең иң тәмсез икән каны. Елан карлыгачны аннан соң күрә алмый башлаган икән мин сине кабып йотармын, юлымда эләксәң дип әйтә елан. Юк диде карлыгач - мин кешенең тәрәзә төбендә оя ясармын, адәм кешесе мине яратыр, миңа карап сөенер диде. Шулай соң әле, карлыгачны яратабыз, ә еланны дошман, суык дип аңа ташланабыз, аны күрә алмыйбыз, Карганы да пәйгәмбәребез яратмаган шом калыр дип әйткән. Елан адәм баласын тәмләгән булса, безне кабып йотыр иде кызым, рәхмәт карлыгачка, ә чебен безнең канны имәте мәльгунь, ярайты теле юк, ичкемгә әйтә алмый.

## Нух пәйгамбәр

**Информант:** Ташбулатова Мәүликамал Сәфәр кызы, 1951елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Ташбулатов Валерьян
Төмән өлкәсе, Тобол районы, Күкрәнде авылы, 1993 ел.

Кырык көн, кырык төн төн яктан йел өргән. Пар пулган суны кырга ташлаган. Шаның өцен кыртагы саслык аратагы утраулар парысы та көнчыгыштан көнбатышкагаца су пулып сусылганнар. Кәп калык шал мәлне сыута цумып үлгән.

Нух пәйгампәр олло кимә салган, аннан суң әрбер хәйваннарны парлы-парлы итеп янына алган.

Шалай итеп кимә пелән йөсеп парганта Нух пәйгампәрнең пер паласы сай пулаган, кимәгә утырсыйца атлап киткән.

– Утыр, – тиеп әйткән Нух пәйгампәр. Ә паласы утырмаган. Шаңа ацуы килеп: «Утыр, залим»!– дигән Нух. Шал вакыт шәйтан шал сүсләрне эшетеп:

– Миннән тә залимрәк перәй кем пармы?– тип, кимәгә утырган.

Ә пасалы сыу пуенына өак йәткәө кимәгә утырган. Шал вакытны цыцкан пелән еланны кимәгә утысмаганнан. Шәйтан цыцканга кимәне тишеп кергәле әйткән. Ул тишеп кергәнсең кимәгә сыу керә пашлайты. Ә еланга шәйтан койрыгы пелән шал тишекне потәйткәле кушкан.

Пара-пара пыларның кимәләре Гималай тауларына парып йитәте.

Килеп йеткәнсең шәйтан церкәйгә кемнең каны тәмлерәк икәнен пелгәле йибәрәте. Церкәй парсыныкын та тәмләп, атәмнең каны иң тәмле икәнен пеләте әм шәйтанга шаны хәбәр итергә җыена. Карлыгач аның пы уйларын пелеп алып, атәмне якларга була. Карлыгач церкәйтән:

- Церкәй, кемнең каны тәмлерәк? – тип сурайты.
- Атәмнең,- тип әйтәте церкәй.
- Алай пулса, канын күрсәтце, – тип әйтүгә церкәй авысын аөып йибәргән.

Шал мәлне карлыгац церкәйнең телен өсеп алаты. Ә церкәй теле пулмау сәбәпле ицнимә әйтә алмайты. Моны елан күреп тора та:

– Пы синең өцен! – тип, тесмә паштагы карлыгачка ташланаты. Тик койрык оцын кына тешлщп алаты. Шаннан пирле карлыгачларның койрык оцларынта еланның теш эзләре ятып калган.

## Көзыр Ильйас

**Информант:** Азанова Айникамал Закир кызы 1930 елгы
**Язып алучы**: ТДСПА студенты
Хәбибуллина Наилә Наил кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы, Сөләйман авылы, 26.07. 2006 г.

Элэк пулган имеш Кысыр Ильйас тигән кеже. Ул ирттәгезен йөрөгән игән. Пер гөннө пер пицә итән севреп йөрөп йатканда, аның өйөнә пер начар кейемле кеже кергән игән. Ул кеже мыннан ажагалы икмәк сураган, пы пицә аның пылай суравына:

– Йук миндә икмәк, – тип, кулынтагы цүпне ул кеженең өстөнә цацкан игән.

– Йукка пөт, – тип, ул кеже цыгып киткән.

Аннан ул пицә йарлы пулып калыпты.

Игенцетә пер йегет сасха парып утырган игән, аның алтына пер кеже оцраган игән. Ул кеже ажанырга икмәк сурапты, йегет мыңа парып утырган йереннән туктап ажамлык пирепте. Ул кеже ажанып алгац:

–Мәңге ризыктан өзөлмә, – тип, йугалып китепте. Шаннан ул йегет симйазы паеп китепте.

## Астана турында

**Информант:** Хәбибуллина Мөсәвәрә Мәсгуть кызы, 1910 елгы
**Язып алучы:**ТДСПА студенты Рабикова Лилия Омск өлкәсе, Усть –Ишим районы,Зур Тибенде авылы 04.08.1994

Пэснэң аултан алыс түгэл йэртә йакшылар йаткан йэр пар. Аны пэстә астана тип йөртәтләр. Утысынцы йылларта астананың эцэнтә пэр урыс цыцып куйган итә. «Мин ышанмайым сэсснэң нимәгэскә» – тип. Шаннан сун ул урыс игэнцэ көннә үк тартышып үлтә.

Сугыштан сун астананыың эцэпэлән йул эшлэп киттэләр. Шуннан суң аның әүлиясэ пэрәүнэң төшэнә кэрэптэ «Пэс йәшэл йапраклы кайын йанына күцэп киттэк» –тип. Йул пуйтагы пөтөн йапраклары кайыннарның койолып пөтсә тә кышкы көннәргә цаклы пэр кайынның йапраклары йәм йәшэл пулып утыраты игән ул йәм-йәшэл йапраклы кайын йанынта пэр көцкөнә гэнә күлцэгәц пар кайпэр кэшэләр ул күлнэң суынта икэ аккошны күрәтләр игән. Картларның әйтүэнцә ул аккошлар ицкалай оцоп китмәсә тә кэшэләрнэң күсалтынта әллә калай йугалып китәтләр имэш. Мэнә шунтай кәлләр пулты пэснэң йакта.

## Бизәләй шәех белгән эшләр
## (Писәләй шык пэлгән эшләрэ)

**Информант:** Давлетбакиева Чинан Әхмәт кызы, 1922 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Рябиков Руслан Омск өлкәсе, Усть-Ишим районы, Кайнавыл авылы 2.10.1993 г.

Әүәлгэ уакытта пэснэң йакта әшгәрә тың укымышлы әүлиә сигырцы Писәләй шык тигән кэшэ йәшәгән пулган. Аның үсэ пэлән пэргә пиш кысы йәшәгән игән. Ул үсэ тэрэ пулганта ук пиш кысына йэтэ пийәнэң сөтөн саутырып аны палцык пэлән аралаштырып пэргә кирбэц суктырган. Аны күргәц, пашга кэшэләрнэң мыңа исэ гитэптэ. Шуннан пы шыктан алар сураптылар: «Пы нимә эшләйсэс сэс пылай тип?». Ул аларга шулай тип әйтэптэ: «Мин мэнә үлсәм, пы кирбэцләр кабэрэмнэ йапкалы. Шуңа карап торган калык тагын та ачәпкә калыпты. Шуннан кайпэрәүләрэ аларның сурапты тагын та мыннан: «Ә ник алай пийә сөтөннән кэнә тип?» Аларга та пы шык карт чауап табыпты: «Мин үлсәм әгәр тә, пәриләр

йаткысмаслар. Нэй өцөн тисәң, йэл пәриләрнэ мин эшләтәмэн. Әгәр тә интэ йэтэ пийәнэң сөтөннән пасып, пылай кирбэцләрнэ кылтырсам, ул уакытта интэ пәриләрнэң минэ кусгагалы урыннан кәлләрэннән килмәс.

Пэргөннәрнэ мэнә мынтай та кәлләр пулыпты. Пэр гөн алтан Писәләй шык ауылтагы кэшэләргә әйтәтэ игән иртә төннэ мин әйткән йэргә пармаң. Анта минэң кушуым пуйынца пәриләр эшләйтэләр. Ату пэрәйэгэсгә пэрәй нимә пулып куймасын тип. Ул кыйылтау тигән йэртә пәриләргә пэцән эшләткән игән. Пәриләр пэр төнтә пэцәннэ цавып куйатлар игән. Аннан ул ук төнтә аны коротоп кибәнгә өйөп куйатлар игән. Шулай пәриләрнэң пэцән цавып йөргәнэн кэшэләр тә күргән пулган, үсләрэ күрэнмәсә тә көцкөнә гэнә цалгылар чыш–чыш итэп цавып паратлар игән. Ул пуйта өсәрә пулган кэшэләр йанаш пармай гына караганнар игән, ә пэрәүэ күргәлэ тип, әшгәрә йуык килгәнтә, аның пэр айагын цавып усып китэптэләр кәттә. Эшләрэн пөтөрөп куйгац, пәриләр Писәләй шыктан тагын та эш сурап киләтләр игән. Ә интэ шулай итэп, Писәләй шык пәриләргә алар эшләй алмаслык эш эстәпакса та алар аны эшләй алганнар игән. Ә интэ көс көннәрэнтә кырта эшләр пөткәц ул аларга иләк пэлән су ташытып китсәтә ташый–ташый шал пэрницәк кыйланып мүцкәнэ тултыратылар игән.

Аннан суң интэ пәриләр аны та эшләй алгац, ул аларга комнан арган иштэрэптэ «Осон кыр» тигән йэртә. Шулай кыйлана–кыйлана, комта пәриләр арган та ишэп куйатлар игән. Ишэп куйганнан суң Писәләй шыкка килэп әйтәтләр: «Игән ишэп куйтык арганны. Әйтә: «Үсэң парып принимайт итэб ал арганны» тип. Шуңа гаршы пы аларга әйтәтэ игән: «Пылай йак мин пармайым, сэс үсэгэс алып килэң мынта. Аннан суң карапагырвыс нэтәй арган ишгәнэгэснэ. Шуннан йарайты тип, пәриләр комнан цыгып китәтләр дигән. Аннары алар парып комнан тигән арганны күтәрэвэйсәләр, ком койылып китәтэ игән. Шуннан пылар тагын ишэпагатлар игән комнан арган. Тагын та шулай пулыпты. Шулай итэп, пәриләр әллә ницәмә мәртәвә пылай ук кылып пакканнар. Суң Писәләй шыкның йанына алып килә алмагац, ком пауын ташлап кацатлар игән. Шулай итэп ул пәриләргә пайтак эшләрнэ эшләткән пулган.

Пэргөннө Писәләй шык Кайнаул аулыннан Иртэш йылгасы аша кимә пэлән кицэп Убаул аулына парган пулган. Ул аулта икэ кэшэнэ төсәткәннән суң үсэ тә кинәттән аурып китэптэ. Интэ әцәл кәстәсэнтә пулганта кэшэләргә пылай тип әйтэптэ: «Әгәр тә минэ Кайнаул йакка Иртэш аша кимә пэлән алып китсәгэс, пэр тактага ат койрыгыннан ишэлгән кыл тилвэгә пэлән пәйләп куйың» – тип. Мыңа йәшләр көлөп: «Үлэппак мэнә, кыймылтарсыңма игән», –тигәннәр. Шуннан суң, ул йәшләргә Писәләй шык пылай тип әйтэптэ: «Йак сэс миннән көлмәң, минэң әйткәнэмнэ кылың. Әгәр тә интэ алай кылмасагыс, сэснэ карап итүэм тә пар. Су пәриләр минэ патыргалы тайашырлар. Шуның өцөн кәсэр пылар пәрэсэ тә минэң күс агымта. Ат койрогыннан кыл тилвәгә ишэб

алың тип куйыпты». Кэшэләр ышанса, ышанмаса та аның үтэнэцэн кылыптылар. Шулай итэп кылтан тилвэгэ гэнэ ишэп алганнан суң: «Тагын та нимэ эшләйвэс?» тип сурап аның йакка караваксалар, ул интэ үлэп тэ куйыпты.

Иртэш йылгасы аша алып цыккалы тип кимэгэ салганта та, аның эйткэнэнцэ пэр тактага кылтан ишэлгэн тилвэгэ пэлэн пэйлэп куйыптылар. Ул көннэ тымык пулганга, Иртэшнэң суы та тыныц кына агып торган пулган. Шулай тыныц кына кимэ парып утыранта, интэ Иртэшнэң уртасына пылар йэткэнтэ, кимэ кинэттэн ул йакка та, пы йакка та аунаклай пашлаган игэн.  Әйтэрсэң су астытан пэр нимэлэр кимэнэ ул йактан та, пы йактан та кутэрэвэйтэлэр. Шулай пэр мэртэвэ эшгэрэ каты кимэ аунаклаганта үлгэн кэшэ төшэп китэ йасыпты. Шунта гына кэшэлэр аңлапты аның эйткэнэн. Тыныцланганнан суң кимэтэгэлэр йарайты ишшэ аның эйткэнэнцэ кылтык. Алай кылмасак пэлмэйвэс нимэ пулар итэ пэснэң пэлэн тип. Шуннан суң Кайнаул аулына аны алып кайтканнан суң кыслары пишэү тэ пылай тип эйтэптэ: «Атабыс тэрэ пулганта эйткэн пийэлэрнэң сөтө бэлэн палцык аралаштырылган кирбэц пэлэн кумгэлэ»– тип. Аның өцөн алай кылың тип кыслары эйтэптэ. Шуннан суң кына кэшэлэр аны ололап кумэптэлэр.

Кэсэр тэ Кайнаул аулыннан алыс түгэл йэртэ Исгэ үлэк тигэн йэр пар. Анта кирбэцтэн эшлэнгэн кабэртэ Писэлэй шык йататы. Ул пуйны йакшылар йаткан йэр тип йөртэтлэр. Ул кирбэцтэн эшлэнгэн кабэртэн уң йаккарак кырык кыс йататы. Ул алай ук аталаты кырык кыс. Игэнцэлэй кыслар үлэк тип йөртэтлэр мынта. Аның интэ тарих эм лэгэнталары үсэ пашга.

### Булган хәл

**Информант**:Габдрахманова Рауза Гаязетдин кызы,1943
**Язып алучы:** ФһСИ студенты Габдрахманова Зилә,
Балык Бистәсе районы, Югары Тегермәнлек авылы,
30 август 2011 ел.

- Ярулла хәзрәт бабай булган.Ишан булган.Ул бик изге җан булган.Ул бөтен әйберне белгән.Нәрсә буласын белгән.Зиратка ул суны аркылы чыга икән, аягы суга чыланмаган аның. Менә шундый изге җан булган. Аның шундый могҗизалары булган. Мәсәлән,аның хатыны авырга узганда, кыш көнендә агачта пешкән кура җиләге ашыйсы килгән. Бабай әйткән: «Бар түбәнигә төш», – дигән. Менә шунда Аллаһының рәхмәте белән ул агач үскән, кура җиләген туйганчы ашаган. «Кешегә әйтмә »– дигән. Ә хатыны кешегә әйткән, күршесенә: «Әйдә мин сиңа бер могҗиза күрсәтәм». Түбәнигә төшсә, бер әйбер дә жук. Менә шундый могҗизаларны әйткән. Аннан соң хатынының күзе сукрайган. Бабай үлгән. Бабай үлгәннән соң хатыны әйткән: «Минем күзем сукрайды карт, син булыш», – дигән. Аллаһ Тәгаләдән сорамаган. Аллаһ Тәгаләдән сорамагач, менә бабай әйткән:«Алай да аптраттың инде», – төшенә кергән. Шуннан

күзе ачылган.Ә кешеләр Коръән укыганда: «Абыстай синең күзең сукырайган ие бит.Нишләп күзең хәзер күрә?» - дигән.

- Менә бабагыз ачты бит, – дигән.

Бабагыз ачты дип әйтергә ярамый, Аллаһ Тәгалә рәхмәте булды дип әйтсә,күзе ачык каласы булган.Хәзер аштан кайтып кергәндә,капкадан кергәндә башына капчык кигергәннәр.Әби яңадан сукырайган. Менә шундый могҗизалары булган бабаңның.

**«Мифлар һәм ырымнар» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. Татар фольклорында космогоник мифлар.
2. Татар халык иҗатында Шүрәле персонажы.
3. Татар халык иҗатында «түбән мифология» каһарманнары.
4. Татар халкының дәвалау ырымнары.

## ТЕМА № 3. ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫ. КАЛЕНДАРЬ ЙОЛА ИҖАТЫ

Йола фольклоры – халык иҗатының иң борынгы төрләреннән берсе. Кешеләр, хезмәт процессында туган тәҗрибәләре нигезендә, табигать көчләрен буйсындыру турында бик күптәннән бирле хыялланганнар. Ләкин табигать серләрен, аның үзгәрешләрен һәм сәбәпләрен төшенерлек аң-белемнең булмавы аркасында, кешеләр табигатькә буйсынырга, табынырга мәҗбүр булганнар. Шул ук вакытта кешеләрнең аралашулары һәм билгеле бер дәрәҗәдә тормышка материалистик карый башлаулары аларда табигать көчләреннән ничек булса да файдалану теләген тудырган. Кеше үзенең тормышы өчен кирәк булган төрле нәрсәләрне табигатьттән сорау һәм үтенү аркасында табигать көчләренә багышланган магик йолалар килеп чыккан. Борынгы кешеләр сүзнең, арбауның, ырымнарның, җыр-сүз тезмәләренең магик көченә ышанганнар. Гомумән алганда, йола поэзиясенең барлык жанрлары, төрләре нигезендә беркатлы һәм шиксез ышану ята һәм барлык шигъри үзенчәлекләрне билгели.

Йола ул – аерым бер коллективның яисә кешенең иҗтимагый-хуҗалык һәм шәхси тормышындагы иң җитди моментларда башкарыла торган, борынгыдан килгән традицион хәрәкәт- гамәлләре.

Йола белән гадәт арасында аерма бармы? Гадәт ул киләчәк буыннарга мәдәниятны җиткерүнең үзенә бер традицион формасы. Ләкин аның йоладан аермасы шунда, ул максатка ярашлы хәрәкәтләрне киләчәк буыннарга җиткерә: хезмәт эшчәнлеге белән бәйле хәрәкәтләр, көнкүрештәге, гаиләдәге хәрәкәтләр. Мондый хәрәкәтләр нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү өчен хезмәт итә.

Йоланың гадәттән төп аермасы шунда, ул үз эченә турыдан-туры максатка ярашлы хәрәкәтләрне түгел, ә бәлки *символик хәрәкәтләрне* туплый.

Халык йолалары белән бәйле шигъри әсәрләрне икегә бүлеп карыйлар:

1. Ел фасыллары дәвамында башкарыла торган хуҗалык эшләренә бәйле календарь йолалар һәм

2. Гаилә йолалары.

Ф. Урманчеев календарь йолаларны түбәндәге төркемнәргә бүлеп өйрәнергә тәкъдим итә:

1. Яңа елны каршылау йолалары һәм җырлары.

2. Авыл хуҗалыгы эшләре белән бәйле йолалар.

3. Төрле өмәләр, аулак өйләр һ.б.

Ә Риф Мөхәммәтҗанов календарь йола поэзиясен ике циклга бүлеп карый:

1. Уңышны үстерүгә бәйле фольклор (кышкы һәм язгы-җәйге чорлар);

2. Көзге уңышны җыюга бәйле фольклор;

Уңышны үстерүгә бәйле йолалар җир эшләренең вакытына туры килә. Игенче фикеренчә, бу йолалар җирнең ундырышлылыгына, киләчәк уңышның мул булуына йогынты ясарга тиешләр. Идел-Урал төбәгендә әлеге төргә караган – нардуган, нәүрүз, сөрән, май чабу (керәшен татарларында), сабантуй, карга боткасы (каргатуй), яңгыр боткасы йолаларында сакланып калган. Икенче цикл йолалар уңышны җыеп алуга кагылалар. Болардан тыш төрле хуҗалык эшләренә бәйле өмәләр дә - чалгы, урак, сүс, туку, орчык, тула һәм каз өмәләре дә бар.

Тарихи яктан, хуҗалык итүнең характерына һәм борынгыларның табигатьне, үзләрен әйләндереп алган тирә-юньне танып-белергә омтылулары, күзәтүләре нигезендә, тикшеренүчеләр фикеренчә, беренче чиратта, халык сынамышлары барлыкка килә. Сынамышлар барыннан да элек табигатьтәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә туалар. Календарь йола поэзиясе составына сынамышлар рәвешендә мәкаль һәм әйтемнәр, ышанулар, арбаулар-теләкләр килеп керә.

Иҗтимагый-мәдәни тормышта билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләр тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык халыкларга да хас күренеш ул. Ул мәдәниятнең мөһим элементы булып исәпләнә һәм аның аермачык этник төстә булуы, халыкның бик борынгы үзенчәлекләренә бәйлелеге күзгә ташлана. Шуңа да, бер халыкны аерып күрсәтергә теләсәләр, шул халыкка гына хас булган аерым йола һәм бәйрәмнәрне аерып күрсәтәләр.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

**Тема: Гаилә-көнкүреш йолалары, аларны үткәрү рәвеше**

1. Бала туу белән бәйле, никах туе, кешене соңгы юлга озатуга мөнәсәбәтле йолалар комплексы, кузайтын (каршы алу), хәрби хезмәткә озату һ.б. бәйрәмнәр; аларны үткәрү максатлары, аларның вазифалары.
2. Дини йолаларның килеп чыгышы, үткәрү әһәмияте. Ислам дине йолаларының бүгенге көндә сакланышы. Гаилә йолаларына диннең йогынтысы.
3. Йола фольклорының милли тәрбия нигезе буларак роле, «Халык педагогикасы» дәресләрендә кулланылышы.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***


1. Бакиров М. Йола фольклоры / М.Бакиров // Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б. Б. – 47-89.
2. Урманче Ф. Йола фольклоры // Ф.Урманче.Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – 355 б.- Б.55-67.
3. Бакиров М.Х. Котлы булсын туегыз! – Казан: Сүз, 2007. –192 б.
4. Мөхәммәтҗанов Р. М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (туй поэзиясе). – Уфа.- 1990.-156 б.
5. Мөхәммәтҗанов Р. Татар туе. – Уфа, 1990. – 156 б.


***Өстәмә әдәбият:***


1. Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.
2. Арикеева З.М. Йорт күтәрү йоласы // Түгәрәк уен. – 2011. – № 1. – Б. 23-25.
3. Баязитова Ф.С. Нардуган // Түгәрәк уен. – 2012.- № 1. – Б. 74-75.
4. Брусько З.М. Фольклор семейно-бытовой обрядности татар. Автореф. канд. филол.наук, Казань, 2012.


***Чыганаклар*:**


1. Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. Татар халкының гаилә йолалары. –Казан: Тат.кит. нәшр., 1992. –295 б.
2. Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе, фольклор. – Казан: Фикер, 2002. – 298 б.
3. Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе, фольклор. Саранск: Татар газетасы, 2003. – 285 б.
4. Сайфулина Ф.С., Хасанова М.С. Язык тоболо-иртышских татар. Фонетический аспект (на материале фольклора сибирских татар). - Тобольск: ТГПИ им. Д.И. Менделеева, 2008. – 176 с.

Борынгы календарь йолаларның берсе – Сөрән, шактый үзгәртелгән хәлдә булса да, Татарстанның Кукмара районы Күкшел авылында һәр елны Сабан туена  берничә көн калгач уздырыла. Әлеге йола бәйрәме борыгыдан килгән өч йола кушылмасы буларак яши. Беренчесе – Сөрән– кышны озату бәйрәме. Сөрәндә бары тик егетләр генә катнашу һәм аларның аякларында җәй көне һәм һава торышының нинди булуына карамастан киез итек булу моны дәлилли. (Авыл кешеләре нигә киез итек кияргә кирәклекне белмиләр, «йоласы шул» дип җавап бирәләр). Икенчедән, егетләр армиягә алыну яшендә һәм рекрутлар йоласын үтиләр, авылдагы һәр йортка кереп, авылдашлары белән күрешеп чыгалар. Өченчесе – сабан туена әзерлек этабы, бәйрәмгә бүләк җыю. Бәйрәмнең хәзерге вакытта ничек уздырылуы турында Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлегенең читтән торып уку бүлеге студенты Галимуллина Нурисәнең мәкаләсе һәм фоторәсемнәрен тәкъдим итәбез.

## Язгы календарь йола – Сөрән /Клич

**Информант һәм язып алучы:**
Галимуллина Нурисә, 1991 елгы
Кукмара районы Күкшел авылы

«Язга бәйле рәвештә формалашкан йола бәйрәм «Сөрән» дип аталган йола Урта Идел –Кама – Урал төбәгендә яшәүче күп халыкларга таныш булган (чувашларда «серен», мариларда «сюрем», удмуртларда «сөрән»). Язны каршылау бәйрәме буларак, ул кар сулары аккан, ташу киткән чорда – апрельдә үткәрелгән һәм мал-туарны көтүгә чыгаруга, язгы чәчүгә әзерләнү эшләренә бәйләнгән. Сөрәннең мәгънәсе кышны җиңүче яз (бәйрәм) хөрмәтенә аваз салу, көр тавыш белән сөрән әйтүгә, муллык һәм уңыш теләп сөрәнчеләрне бүләкләүгә кайтып кала. Сөрән такмазаларын төркем-төркем булып атларга атланып йорттан йортка йөрүче яшүсмер егетләр әйткәннәр. Хуҗалар исә аларны төрлечә кунак иткәннәр, камыр ашлары яки сыра белән сыйлаганнар, күпчелек очракта йомыркалар биргәнннәр. Сөрән бәйрәмендә язны һәм язгы кар эшләрен сафланып – пакъләнеп каршылаганнар. Моның өчен кешеләр урамда яисә ындырда ягылган зур учактан сикереп чыгарга һәм шул рәвешле гөнаһларыннан, явыз рухлар тәэсиреннән арынырга тиеш булганнар. Җир – кардан, кеше кышкы киемнәреннән арынган кебек, гөнаһлардан арыну өчен дә иң кулай вакыт булып исәпләнгән.сөрән йоласының язгы кыр эшләре якынлашуга бәһлелеге аның акрынлап Сабантуй йола-бәйрәме белән керешеп китендә дә күренә булса кирәк»– дигән фаразлар әйткән хөрмәтле галим – Марсель Бакиров.

Сөрән йоласының безнең авылга кайчан килеп чыкканын төгәл белүче кеше юк. Чөнки олы яшьтәге әби-бабаларыбыз әйтүе буенча, инде аларның яшь вакытларында ук уздырылган бу бәйрәм. Шушы күркәм

традициянең безнең көнгә кадәр сакланып килүе гаҗәп түгелмени? Без моңа үзебез дә сокланабыз, горурланабыз. Чөнки бу йола шулай зурлап, матур итеп бары тик безнең Кукмара районының Күкшел авылында гына үтә. Безнең сөрән турында белмәгән кешеләр, беренче тапкыр ишеткәч, гаҗәпләнеп калалар, аптырыйлар. Чөнки моның сәбәпләре бик күп. Ә инде кайтып күргәч, сокланып та, шул ук вакытта ак көнләшү белән көнләшеп тә «нишләп бездә дә шундый бәйрәм юк икән?» дип уфтанып куялар.

Һәр ел саен карлар эреп, җирләр кибә башлагач, май бәйрәмнәреннән соң авылыбызның 9,10,11 сыйныф егетләре һәм 1 нче курс егетләре, ягъни армия яше туласы егетләр авыл башында Алмагач аланында мәҗлескә җыела башлыйлар .Егетләрне беркем мәҗбүр дә итми, чакырып та йөрми, үзләре белеп җыелышалар. Аларның анда җыелуларының төп сәбәбе һәм максатлары шунда: сөрәнгә әзерләнү һәм яшь егетләрдән, ягъни 9 нчы сыйныф егетләреннән «сөрәнчеләр» әзерләү. 9 нчы сыйныф егетләренең төп вазифалары: мәҗлес өстәле ясау, мәҗлес такмазаларын җырларга, татарча биергә һәм тигез итеп атларга өйрәнү. Ә калганнар исә, узган елда өйрәнгәннәрен искә төшереп, ныгытырга тиешләр. Әйтеп үтелгәчә, һәр ел саен яңа өстәл ясыйлар. Ул өстәлне Алмагачның бер читенәрәк, агачлар арасына буш урынга урнаштыралар. Алар мәҗлескә укулары беткәнче һәр атна шимбә, якшәмбе, ә укулары беткәч, көн саен җыелалар. Егетләр үзара дежурство билгелиләр. Һәр мәҗлес саен ашарга-эчәргә алып килә. Иң элек ашап-эчеп көч җыялар, ә аннары эшкә керешәләр. Араларында гармунчы егетләр сөрән көйләрен суза, ә калганнар җырлыйлар, аннан татар халык көенә бииләр, кырга чыгып, тезелешеп басып, тигез атларга өйрәнәләр. Ә инде җырларга да, атларга да өйрәнеп беткәч, гармун көенә җырлый-җырлый атларга өйрәнәләр. Сөрәнчеләребезнең Алмагач аланында барган әзерлекләре шушылардан гыйбарәт. Вакыт тиз үтә. Сөрән көне дә килеп җитә. Иртәгә Сабантуй диясе көннең кичендә егетләр йомгаклау мәҗлесенә җыелалар. Бу мәҗлес берәр егетнең әти-әниләренең рөхсәте белән, аларның ишегалларында уздырыла. Бер генә әти – әниләрнең, бер кайчан да каршы килгәне юк. Чөнки сөрән мәҗлесе туй мәҗлесе кебек үткәрелә. Өстәлләр төрледән төрле сый-нигъмәт белән тулы була. Монда мәҗлесне оештырган кешегә зур рәхмәт инде.

Егетләребез мәҗлескә үзләренең сөрән киемнәрен киеп киләләр: ап – ак күлмәк, кара чалбар, билдә чиккән сөлге, башларында татар халкының милли баш киеме – түбәтәй һәм иң кызыгы – аякларында киез итек була. Җәй башында һава торышының нинди булуына карамастан – кояш кыздырамы, яңгыр явамы, аякка итек кияләр.



Йомгаклау мәҗлесенең көндәлек узган мәҗлесләрдән төп аермасы шугнда: монда егетләр үзләре генә булмый. Алар үзләре белән сөйгән кызларын, дус – ишләрен, сыйныфташларын алып киләләр. Гомумән, мәҗлескә кем генә килсә дә, бер кешене дә кире борып җибәрмиләр, кунак итәләр. Бу эшне, билгеле хуҗа егет башкара. Мәҗлестә такмазаларын кабатлап, ашап – эчеп, шул әзерлек чорында чыккан мәзәкләр сөйләп, күңелле итеп утыралар. Бу мәҗлескә кичке 9ларда җыелалар һәм төнге12 ләргә кадәр утыралар.

Мәҗлесне дәвам иткәч, мәҗлестәге бар кеше авыл башына бәйрәмне башларга менеп китә. Ә авыл башында халык, төнге сәгать 1 булуга карамастан, яшьләрне зарыгып көтеп алалар. Сөрәнчеләр авыл башына менеп җиткәч, җыелышкан халык белән рәхәтләнеп биеп алалар һәм тиешенчә бер рәткә тезелешеп басып сөрәнне башлап җибәрәләр. Сөрәнчеләрне һәрбер өйдә ишегалдында өстәл тулы сый – нигъмәт белән каршы алалар. Алар хуҗалыкка дөрес итеп, йөгереп, «ура» кычкырып керергә тиешләр. Алдан бүләкләр эленгән озын колганы тотучы һәм гармунчы егет, ә алар артыннан калган сөрәнче егетләр керә.

Ә сөрәнчеләрне хуҗа кешеләр Сабантуйга әзерләгән бүләкләре белән каршы алалар. Хуҗа сабан туена әзерләгән бүләген сөрәнчеләргә тапшыра. Сөрәнчеләр бүләкне алгач, хуҗанын исемен атап рәхмәт әйтәләр: «Нургали абыйның Татарстан бәйрәменә биргән бүләге өчен рәхмәт. Ура!Ура!Ура!». Ә сөрәнчеләрнең вазифалары җыелган бүләкне авыл җитәкчелеге берләшмәсенә тапшыру. Чөнки ул бүләкләр сабан туенда җиңүчеләргә, батырларга дип җыела.

Әгәр өйдә яшь кызлар яки кунак кызлар булса, алар сөрәнчеләр килүенә чиккән куляулык әзерләп куялар. Кулъяулыкларны күп кызлар үзләре чигә, ә инде җитешмәгән яки кул эшенә оста булмаган кызларга әзерне сатып алу мөмкинлеге бар. Ничек кенә булмасын, бер кыз да

кульъяулыксыз булмый. Кызлар бүләкләрен үтүкләп, матурлап куялар. Ә кульъяулыкны алып чыктың да теләсә кемгә бирдең түгел бит әле ул. Сөрәнчеләр кергәндә кызлар өйдә, йөрәкләре чыгып китәрдәй булып, көтеп торалар. Сөрәнчеләр колгалары белән тышкы өй ишегенә шакый-шакый такмаклап кульъяулык сорыйлар: «Әйе шул,шулай шул, Гүзәлдән кульъяулык». Йөрәкне иң җилкендергәне дә шул вакытта бит аның. Кызлар өйдән чыгып, кемгә дә булса атап кульъяулыкны бирәләр. Кемдер сөйгән ярына, кемдер дус-ишенә, кемдер, сыйныфташына, күршесенә, ә кемдер туганына бирә. Биргәндә: «чиккән кульъяулыгым – Илшат дустыма бүләгем» дип әйтеп бирәләр. Әгәр дә кунак кыз булса, «Әйе шул, шулай шул, кунак кыздан кульъяулык» дип сорыйлар. Кунак кызлар исә, гадәттәгечә, гармунчыга бирәләр, чөнки ул авылның егетләрен белмәскә мөмкин, ә белгән очракта, исеме белән атап бирәләр. Гармунчы егетнең кульъяулыкларын сөрән беткәч, егетләрнең үзара бүлешүе каралган.

Авылыбызда ел саен яңа гаиләләр төзелеп тора. Һәм аларның да сөрәндә үз рольләре бар. Яшь килен сабантуй батырына дип сөлге чигеп куя һәм сөрәнчеләргә бүләген тапшыра, ә яшь кияүне ишегалдыннан урамга күтәреп алып чыгып «ура» кычкырып чөяләр.



Бу берьяктан аларны котлау кебек булса, икенче яктан безнең читән кайткан авылдашларыбызга, кунакларыбызга, ишемәгән, белмәгән булсалар, зур яңалык була. Әле яшь кияүне сөрәндә чөю белән генә чикләнмиләр. Безнең сөрәнчеләребез Сабантуйда да шушы милли киемнәреннән булалар, бары тик киез итекләрен генә салалар. Алар шулай күмәкләшеп, озын итеп, бер рәткә тезелеп сабан туена ямь өстәп йөриләр. Менә шунда юлларында яшь кияүне күреп алсалар, мәйданга алып кереп чөяләр. Хәтта яшь кияүләрнең кайберсе сөрәнчеләрдән качып та йөри әле.

Шулай итеп, хуҗадан бүләк алынгач, кызлар куляулыкларын бүләк иткәч, яшь килен чиккән сөлгесен тапшыргач, яшь кияүне алып чыгып

чөйгәч, сөрәнчеләрнең хуҗаларга кунак булганнары өчен рәхмәт әйтәселәре һәм Сабантуй бәйрәменә чакырасылары гына кала.

Уйсу җирдә су җыела,
Анда казлар коена.
Әйдә дуслар рәхмәт әйтик
Нургали абый сыена.
Яңа авыл үзәгеннән
Җыеп алдым балтырган.
Рәхмәт яусын Нургали абыйга,
Кунак итеп чакырган.
Биек икән тавыгыз
Каршы ява карыгыз.
Без килдек тә кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз.
Без килдек тә кунак булдык,
Сабантуйга барыгыз, – дигән такмазаларын әйтәләр дә, чыгып китәләр һәм чираттагы өйгә керәләр. Шул тәртиптә авылның һәрбер өенә кереп чыгалар.

Сөрәнчеләребез тимердән түгел, бик аралар, билгеле. Тавышлары бетә башлый. Аяклары атламас дәрәҗәгә җитә кайвакыт. Әмма егет кеше зарланмый шул, сөрәнчеләр бигрәк тә. Алар үзләренең елдагыча гадәтләнгән урыннарында беразга гына туктап ял итеп алалар. Көч җыйгач, тагын дәвам итәләр.

Безнең сөрәнчеләр артыннан йомырка җыючы йөри, авыл халкы, кунаклар бәйрәмне күзәтеп баралар. Күптән күрешмәгән дус-ишләр, туган-тумачалар күрешәләр. Сөрәнчеләребез халыкның күңелен күтәрү өчен һәр урамны йөреп бетергәч, чат саен рәхәтләнеп биеп алалар.

Мәдәният йортыбыз турысына җиткәч, сөрәнчеләребез зур тукталыш ясыйлар. Анда бөтен авыл халкы җыела. Татар халык бию көе яңгырый, шунда җыелган халык рәхәтләнеп татарча биеп ала.



Аннары сөрән дәвам итә. Ул вакытта йөрергә бер генә урам калган була. Шулай итеп бәйрәм ахырына якынлаша. Йөреп бетергәч, сөрәнчеләр тау битенә менеп кайсыдыр ятып, кайсыдыр утырып ял итәләр, иркен итеп сулап куялар. Алар шунда үзләренең кулъяулыкларын саныйлар һәм гармунчыныкын бүлешәләр. Аның кулъяулыклары бихисап күп була, билгеле. Менә шунда, егетләребез авылда күпме кунак кызы булуын белеп алалар. Сөрәнчеләр янына авылның яшьләре килә. Ә авыл халкы тәмле чәй эчәргә, кунакларын сыйларга өйләренә таралыша. Сөрәнчеләр дә бераз хәл алгач, әкренләп өйләренә кайтып китәләр. Шуның белән сөрән тәмам була. Күбесенчә, бәйрәм кичке өчләр тирәсендә бетә.

Тагын өстәп шунысын да әйтәсе килә: безнең сөрәнчеләр өчен “Сөрән” сүзе бик зур әһәмияткә ия. Әйтеп үтелгәнчә,сөрәнчеләрнең гомере бары тик 3 ел гына. Шуңа сөрән яше чыккач егетләр сөрәндә йөргән вакытларын бик сагынып искә алалар. Әле нинди егетләр генә, олы яшьтәге ир-атлар да яшьлек елларын искә төшереп, сөрәнчеләр артыннан, тезелешеп, гармун уйнатып җырлап утыралар, я булмаса сөрәнчеләр кебек үк урамнан йөриләр.

Әле соңгы 5 елда тагын шундый гадәт керттеләр: мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм мәктәп укучылары бергә җыелышып, мәктәп Сабантуе алдыннан, сөрән җыялар. Ләкин алар бөтен авылны йөрмиләр, ә һәр урамның балалары үз урамнарында гына йөриләр. Алар, билгеле, гармун уйната белмиләр, ләкин сөрән такмазаларын бик яхшы беләләр һәм нәкъ чын сөрәнчеләр кебек киенәләр. Шуңа күрә кайсыбер олы яшьтәге егетләр, абыйлар вакытларын кызганмыйча балалар белән дә йориләр. Бу беренчедән, бик файдалы һәм кирәкле, чөнки алар булачак сөрәнчеләр, икенчедән, бик күңелле. Балалар сөрәне бөтенләй башкача. Аларга да өстәлләр әзерлиләр, бүләкләр бирәләр. Хәтта татарча бию көе куеп биетәләр дә. Шундый яшьләре булганда авылыбыз да сөрәнебез дә югалмаячак, яшәячәк. Яшь буынның гореф – гадәтләрне белеп, аңлап, яратып үсүе хәзерге заманда бик мөһим.





Бүләк өчен рәхмәт әйтү күренеше.

**Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә хәзерге вакытта уздырыла торган туй йолалары турында мәгълүматлар**

**Татар халкының туй йолалары**
***(Мордовия Республикасы авылларында җыелган материаллар мисалында )***

Татар халкының туй йоласы иҗаты фольклорчылар, этнографлар тарафыннан шактый өйрәнелгән өлкә. Соңгы берничә дистә елда бу юнәлештә фольклор һәм әдәбият галимнәре Р.Мөхәммәтҗанов, М.Бакиров, Татар фольклоры дәүләт үзәге белгече З.Арикеева-Брусько һ.б. кызыклы хезмәтләре дөнья күрде.

Чыннан да, туй йоласы үзенең тирән эчтәлеге, матурлыгы белән тикшеренүчеләр игътибарын даими җәлеп итүче өлкә. Кайсы чорда һәм кайсы халыкта булуына карамастан, никах туе белән бәйле йолаларның төп мәгънәсе яңа гаиләне булдыру, аны рәсмиләштерү һәм тануга кайтып кала. Р.Мөхәммәтҗанов билгеләвенчә: «Туй йолаларының төп юнәлеше һәм составы бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Калган бөтен эшләр (башта, озатканда, соңыннан булган чаралар) һәммәсе дә әлеге үзәк акт – ярәшелгән кызны күчерү – тирәсенә тупланган [Мөхәммәтҗанов, 1977: 11]». Бу процесс күпчелек халыкларда һәм татарларда да шулай булган һәм берничә көнгә яки айга сузылган. Шул рәвешле ул катлаулы фольклор-этнографик комплексы барлыкка китергән.

Соңгы елларда Казан федераль университетының Татар филологиясе бүлеге студентлары тарафыннан җыелган фольклор материаллары арасында туй йолалары турында шактый кызыклы мәгълүматлар бар. Әмма аларда аермалар бик аз. Туй йоласының этаплары, детальләре күп очракта кабатлана. Хәзерге вакытта рус һәм башка милләтләрнең традицияләренә, заман үзенчәлекләренә иярү дә сизелә. Кызганыч, чит йогынтыга иярү милли йолаларның онытылуына, югалуына китерә.

Ә менә Россиядәге иң зур татар авылларының берсе булып саналган Мордовия республикасының Белозерье авылында туй йолаларын саклауга хәзер дә бик зур игътибар бирелә икән. Әлеге авылда уздырылучы туй йоласы түбәндәге ритуалларны берләштерә.

*Яучылау (кодалау).* Яучылау өчен биредә иң уңышлы көн дип ярәшәмбе һәм җомга көн санала. Яучы булып егетнең әти-әнисе яки берәр якын туганы килергә мөмкин. Кыз бу егеткә барырга риза булса, аның әти-әнисе чәй өстәле артында яучыларга хәбәрне әйтәләр һәм кул билгесе көнен билгелиләр.

*Ярәшү яки кул билгесе көне.* Бу көнне кыз йортына егетнең әти-әнисе зур бүләкләр белән килә. Алар булачак кодагыйлар белән калым хакын (хәзерге вакытта калым якынча утыз мең сум тирәсе), кызга нинди киемнәр алырга кирәклекне (елның дүрт фасылына да яраклы баш, өс, аяк киемнәре, туй, туй арты көне өчен киемнәр һ.б.) сөйләшәләр. Аларны тәмле ризыклар белән сыйлап, кызның ризалык билгесе буларак берәр бүләк, мәсәлән сөлге биреп озаталар. Кияүнең нинди вакытка килергә мөмкин икәнен әйтеп җибәрәләр. Билгеләнгән вакытка кияү үзенең бертуган абыйсы яки энесе, я берәр якын дусты белән килә. Кызга бүләк итеп алтын бизәнү әйбере һәм чәчәк алып килә.

*Сүз бетерү.* Бу көнне егетнең әти-әнисе һәм якын туганнары җыелышып кыз йортына баралар. Алар барысы да яшь киленгә һәм аның әнисенә бүләкләр алып киләләр. Кияүнең әнисе кәләшкә алтын бизәнү әйберсе бүләк итә. Кодагыйлар да бер-берсенә зур бүләкләр бирешәләр.

*Туй.* Сүз бетергән көнне кичен кыз өенә ике яктан да яшьләр җыела. Менә шул көнге табынны туй дип йөртәләр. Элегрәк кызлар һәм егетләр бер өстәлләр артына утырганнар. Шушында танышып өйләнешүчеләр дә шактый булган. Әмма хәзер, авылда Ислам дине йогынтысында кызлар һәм егетләр аерым өстәлләргә утыралар. Бу көнне кунакка килгән яшьләрнең барысына да кызның әнисе бүләк биреп җибәрә.

*Никах* –туйның иң әһәмиятле өлеше. Белозерьеда аны Фатия дип атыйлар. Монда инде ислам, шәригать кануннары өстенлек итә. Никах кыз өендә укыла. Никахка өлкәнрәк кешеләр килә. Кияү үзе белән мулла алып килә. Мулла никах укыр алдыннан кыздан өч тапкыр рөхсәт сорый. Кызның җавабыннан соң гына никах укыла. Кияүнең этисе мәһәрне кәләшнең кулына тапшыра. Фатия вакытында өстәлгә савыт белән су куела. Аны “фатия суы” (Ләбәжәдә) дип атыйлар. Никахтан соң бу су белән яшьләр кулларын, битләрен юалар, аннан агач төбенә түгәләр. Ә юынган сабын белән себеренгән (сөртенгән) сөлгене яшьләр үзләренә генә тоталар. Ә менә Тобеев районында никах суы белән яшь парлар мунчада юынырга тиеш икән.

*Фатия көнендә үк*, өлкәннәр таралгач, 30-35 егет белән кияү кызны алырга килә. Шау-гөр килеп, бик күңелле итеп киләләр. Мылтыктан аталар. Мылтыктан ату күренеше Казан арты авылларында сакланмаган. Белозерьедагы информантлар да «мылтыктан ату нигә кирәк?» дигән сорауга җавап бирә алмадылар. Әмма туй йоласына караган фәнни хезмәтләрдә бу сорауга бик кызыклы җавап бар. Р.Мөхәмәтҗанов кияү килгәндә мылтыктан атуны борынгыдан калган йола элементы дип күрсәтә һәм борынгы кеше карашынча, усал, явыз көчләргә каршы тору чарасы, ягъни апоторопик магиянең бүгенге көнгә килеп җиткән күрсәткече дип саный. [Мөхәмәтҗанов, 1977: 28].

Кияү егетләрен ишек төбендә кечкенә малайлар көтеп тора. Алар кияүне акча түләгәч кенә кертәләр. Кыз өендә ашап-эчкәч, кияү, эти-энисеннән рөхсәт сорап, кызны алып китә. Машиналарның сигналларын кычкыртып һәр урамны әйләнәләр һәм егет ягы әзерләгән табынга туй мәҗлесенә – кодага кайталар.

*Кода.* Кодада кеше бик күп була (250-300 ләп кеше). Зурлап уйнала. Кодада өч-дүрт сәгать дәвам итә. Ирләр һәм хатын-кызлар аерым өстәлләр артына утыра. Яшь парлар да иң якын туганнары белән аерым утыралар. Кунаклар бераз ашап-эчкәч, яшь кәләш белән кияүне хатын-кызлар ягына «тау итәргә» ягъни, күренергә чакыралар. Күренекле галим М.Бакиров «Туй табыны җырларының берише, мәҗлес ахырында җырлана торганнары, «тау итү җырлары» дип атала. Тау итү кыпчаклардан килгән борынгы гыйбарә, рәхмәт белдерү мәгънәсендә. Мондый җырлар мишәрләрдә һәм кершен татарлары арасында күбрәк сакланган» – дип яза. [Бакиров, 2008: 79]. Белозерьеда «тау итү» җырлары бүген дә сакланган. Ике як уздырышка кияү һәм кәләшне мактап җырлый. Алар чыгып киткәч

тә, ике як кодагый-кодачалар арасында кара-каршы җырлашу дәвам итә. Җыр текстлары шактый күп. Чөнки туй табыны җырларының тематикасы, эчтәлеге шактый киң. Иң характерлы һәм киң таралган җырларяшьләрне, ике якның да нәсел-нәсәбен һәм бер-берләрен макташуга корылган. Шуларның кайберләренә генә булса да игътибар итик. Җырларның кайберләрендә яшьләрне мактау, аларга бәхетле тормыш теләү күзәтелә:

Йе(ө)злереңә йе(ө)з карадым,
Йе(ө)з карап та туймадым.
Нурдан яралгансың диеп,
Син маемны уйладым.
***
Карагызчы киленемә,
Каршысында ае бар.
Җир шарында рәхәт яшә,
Йерәгемнең маеман (мае белән).
***
Э(ө)сләрегезгә килешә
Костюм күгелчемнәре
Пар килдегез, шат яшәгез,
Бохар күгәрченнәре.
***
Ке(ө)згегәме багыштыгыз,
Куллармы алыштыгыз?
Сахра былбыллары кебек
Сез каян табыштыгыз?

Кайбер текстларда кунакларны кыстап ашату, хөрмәтләү, аларның мөнәсәбәте өчен борчылу сизелә:

Магазиннан сатып алдым,
Ике тәңкәгә бер каз.
Ашамыйсыз да эчмисез,
Әллә хөрмәтебез аз?

Җырлар кода-кодагыйларга рәхмәт әйтеп, өйгә кайтыр вакыт җиткәнне белдерү белән тәмамлана:

Ары да ефәк эләбез,
Бире дә ефәк эләбез.
Кодагыйга рәхмәт әйтеп,
Давай өйгә китәбез.

Җырлашу бетү белән, кодалар мәҗлесе дә ахырына якынлаша. Кунаклар тарала, ә яшь киленнең туганнары кияү йортына «урны түшәргә» китәләр. Урынны кәләшнең иң якын җиңгәләре түши һәм кодагыйда кунак булгач, кайтып китәләр. [Салихова Ә.]

Икенче көнне тагын кунаклар җыела. Монысы инде «урны кыртлау», ягъни, «урынны котлау» дип атала. Бу көнне якын туганнар гына җыела. Монда кеше саны азрак (100-150) була.

Ә менә Мордовиядәге Торбеев районында туйның төп өлеше җиде көн үткәрелә:

1 көн- яраш туй (кыз ягында);

2 көн – алыр туй (егет ягында);

3 көн – еңәләр (җиңгиләр) Кызны кияү йортына төшерүче җиңгиләр белән кияү ягында була;

4 көн – кодачалар (ике якта да);

5 көн – кияүләр  (кыз ягында);

6 көн – кодагыйлар (ике якта да);

7 көн – ике якта да Коръән укытыла. [Агишева Ә.]

Замана туйларын оештыруны тамадаларга тапшырып, халык үзенең табигый күңел ачуын онытa барган вакытта, Мордовиядә яшәүче кардәшләребезнең гаилә йолаларының иң матуры – никах туе йоласын бүгенге көнгә кадәр шактый тулы формада саклап үткәрәләре һәм киләчәк буынга җиткерүләре бик матур күренеш.

**Әдәбият:**


1. Бакиров М. Гаилә-көнкүреш йолалары һәм аларның поэзиясе// М.Бакиров // Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан – Мәгариф, 2008. – Б. 65-88.
2. Мөхәмәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе) “Татар халык иҗаты” курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. – Уфа, 1977.
3. Брусько З. К вопросу комплексного изучения фольклора (на примере семейно-бытовых обрядов татар) // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 29 июня 2009 г. ) ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ.- Казань- Алма-Лит, 2009.- С. 88-89.


**Искәрмәләр:**

1. Агишева Әлфия, 1973 елгы, татар, Мордовия Республикасы, Торбеев районы Тат.Юнки авылында туган. Язып алучы– Җамалиева Л.Ф. 17сентябрь 2010.
2. Салихова Әкълимә, 1941 елгы, татар, Мордовия Республикасы, Ромадан районы Белозерье авылында туган. Язып алучы– Җамалиева Л.Ф. 18 декабрь, 2010
3. Янгличева Лилия, 1983 елгы, татар, Татарстан Республикасы, Нурлат районында туган, Ромадан районы, Ләбәжә авылында яши. Язып алучы– Җамалиева Л.Ф. 17сентябрь 2010.

## Шыгырдан туйлары

**Информант:** *Абейдуллова Айгөл,1994 елгы ФhСИ студенты*

Шыгырдан – Россиядә зурлыгы белән икенче урында торучы 39 урамлы, 1679 йортлы, 5570 кешеле авыл. Элек-электән һөнәрчелек киң таралган булган монда. Совет заманының иң коры елларында да сату-алу эшен туктатмаган авыл халкы: Мәскәүдән кием-салым, лимон ташыган, Казанга килеп, ит, йомырка саткан. Соңгы елларга кадәр Казанда ит сатып көн күрә.

Бүгенге көндә Шыгырдан зураеп тора: 3 ягыннан чуаш авылларына җитеп килә, 1 ягыннан район үзәгенә – Батырга барып тоташкан. Байлыгы, халкының усаллыгы, әрсезлеге белән дан тота Шыгырдан. Сату-алу гына түгел, дин, йолалар да көчле безнең авылда. Минем кеше гомерендәге иң матур бәйрәмнәренең берсе – туй йоласына тукталасым килә.

«Шыгырданга булса ризалыгым юк!»– дигән әни сүзләре күп кызлар йөрәгенә ут салгандыр, мөгаен. Кызлары янында Шыгырдан егете күренә башласа, күп эти-әниләрнең йокысы кача, тынычлыгы бетә, чөнки кыйбатка төшә торган туйлары белән дан тота шул бездә Шыгырдан авылы.

Бүгенге көндә Шыгырдан туе Ак туйга һәм Кызыл туйга бүленә, аларның арасы 1-2 атна була. Ак туй – кыз ягында, Кызыл туй – егет ягында. Тик туйга кадәр дә шактый юл үтәсе бар әле!

*Кияүгә китү яки өйләнү*. Шыгырданда кияүгә китү яки өйләнү кызның кияү өенә кайтуыннан башлана. Әгәр белеп, көтеп торган өйләнешү булса, каенана киленне бал һәм май каптырып каршы ала. Тик мондый өйләнүләр сирәк бездә. Күбрәк элек-электән килгәнчә «урлыйлар». Чын-чынлап урлаулар юк дисәң дә ярый инде хәзер (сирәк кенә булгалап тора – риза булмаган очракта да урлап китәләр), ләкин һаман да бөтен йоласына китереп, *чынлап урлаган кебегрәк итеп алып китәләр кызны. Егет булачак хатынын күп вакытта якын туганы йортына алып кайта (ризасызлык күрсәтеп* туганнары кызны эзләп йөрүдән курка, имеш). Төн кунганнан соң, яшьләр егет йортына кайталар. Анда инде аларны яккан мунча, сый-хөрмәт белән каршы алалар. Мунча кергәннән соң мулла чакырыла, яшьләргә изәт-кабул (иҗәб-кабул) кылдырыла.

*Килен күрергә килү.* Килен төшкән көннән үк туган-тумачалар, күршеләр, дуслар килен күрергә килә башлый. Буш кул белән беркем дә килми, яулык, халат, сөлге һ.б. алып киләләр. Аларны яшь кәләш чәй, белен белән сыйлый.

*Барып әйтү.* Иртәнге сәгать тугызлар тирәсендә кыз ягына, кызыгыз бездә дип, барып әйтүчеләр китә. Бу егетнең якын кешеләре була (йорттагы абый белән килен яки якын туганы), соңгы вакытта парлап баралар. Машина белән киләләр. «Кызыгыз бездә»,- дип керәләр. Аларны

инде көтеп торалар, туганнар җыелган була. Хәбәр китерүчене коймак-белен белән сыйлыйлар, сый-хөрмәт күрсәтәләр. Бу кунаклар һичшиксез икешәр чынаяк чәй эчәргә тиеш (яшьләр гомер буе парлы яшәсен өчен). Аларга бүләкләр бирелә - хатын-кызга - зур яулык яки халат, ир кешегә - зур сөлге.

*Кызга әйберләр илтү.* Ике як та риза булгач, кыз йортыннан яшь киленгә әйбер илтәсе бар. Зур ак эскәтергә 2 метр өстәл җәймәсе, 2 мунча сөлгесе, 2 зур сөлге, 2 тастымал, 1 урын җәймәсе, кызга кирәк бөтен киемнәр куела. Бу төенне йорттагы кыз яки килен кеше илтә, соңгы вакытта парлап машина белән бару күбәйде. Егет йортында аларны кунак итәләр, бүләкләр бирәләр (хатын-кызга зур яулык, ир кешегә зур сөлге). Эскәтерне калдыралар, аны кире алып кайтырга ярамый. Кода белән кодагыйны танышу мәҗлесенә чакырып калдыралар.

*Танышу.* Бу көнне бик зур булмаган танышу кичәсе була. Кыз йортына үз ягындагы якын туганнар чакырыла, егет ягыннан кода-кодагый, иң якын туганнар килә. Ата-ана беренче күрешүне матур мул өстәлләр төзеп көтеп тора, беренче күрешү яхшы тәэсир калдырсын дип кайгыра. Әгәр әби-бабайлы йорт булса, көндез ике яктан да иң якын әби-бабайларны чакырып, кунак үткәрелә. Кода-кодагый 3 төрле күчтәнәч алып килә: каз, торт, зур, матур итеп пешерелгән ипи. Барлык туганнарга да бүләкләр тапшыралар: хатын-кызга - сөлге, ир кешегә - күлмәк. 1-2 сәгать утырганнан соң кунаклар китә, аларга алып килгән ашларыннан күчтәнәч җибәрелә (берәр кисәк торт, ипи, каз). Кич белән яшь кияү белән яшь килен килә, алар белән егетнең 1-2 иң якын парлы туганнары да килә. Кыз ягыннан да берничә яшь пары чакырылган була. Кияү белән кәләш әти кешегә күлмәк, әнигә зур яулык, күчтәнәчләр алып киләләр. Шул вакытта гына ата-ана балаларын күреп сөйләшә ала. Бу көнгә кадәр ана белән балага очрашырга ярамый дип саныйлар бездә. Берничә көннән шундый ук кичә егет ягында була

*Туй сөйләшү.* Бер атнадан кода белән кодагый икәү генә кыз йортына туй сөйләшергә баралар. Кунак өстәле әзерләнә, тик бик аз кеше белән генә үтә. Бу көнне кайчан Ак туй, кайчан Кызыл туй, ничә көн һәм нинди тәртиптә буласы сөйләшелә, задатка көне, сандык алу көне билгеләнә.

*Задатка.* Билгеләнгән көнне көндез кыз йортына егет ягыннан 3 хатын-кыз килә (кодагый, якын туганнары), кыз ягыннан туй алдыручы йортлардан хатын-кызлар чакырыла. Егет ягыннан килгән кунаклар савым белән киләләр: ипи, торт, конфет яки чәк-чәк. Кодагый 7 төрле төрле аш алып килергә тиеш: 1 кәстрүл бал, 5 тартма шикәр, 5 зур тартма чәй, 1 пешкән, матур итеп бизәлгән каз, 1 матур итеп бизәп пешерелгән ипи, торт, кыз мәһәре – 1 олауга 500 сум акча (олау – Ак туйга баручы 1 пар). Савым зур ак эскәтергә чорнала, хәерләр баш яулыгында була. Табын бик мул итеп әзерләнгән була. Ясин укыла. Савымнар, кунакларга күрсәтелеп,

кемнеке икәнен әйткәннән соң, туралып өстәлгә чыгарыла. Чәй янына гөбәдия чыга. Икенче булып токмач, ит чыга.

*Сандык алу.* Гадәттә задатка көнне кичкә таба сандык алу була. Кызның бирелә торган барлык әйберләре – 60 тастымал, 1 табын кунак өстәленә җитәрлек эскәтер, 2 мендәр, 1 матрас, 1 юрган, челтәр, урын-җир кирәк-яраклары сандыкка куела (һәр кыз балага бик матур итеп эшләнгән сандык алына). Соңгы елларда кызга бирнә итеп йокы бүлмәсе җиһазлары бирелә - кемнеңдер бәярәк, кемнеңдер арзанрак(кыз бирнәсе хәзерге вакытта 50-60 меңгә якын төшә). Билгеләнгән вакытка машина белән егет ягыннан егетләр-кызлар килеп төшә, кыз ягы аларны каршы ала. Капка янында ук кияүне сынар өчен төрледән-төрле кызык уеннар оештырыла. Шактый акча туздыртырга да булдыралар аңардан: акылын, юмартлыгын, холкын белер өчен сынаулар бик күп була. Уен-көлке, шаяртулардан соң кунаклар табынга чакырыла. Сандыкны өйгә кияү белән кәләш күтәреп керергә тиеш. Кертеп куйгач, килен сандыктан алып каенатасына түбәтәй кигезә, каенанасына яулык бәйләтә.

*Ак туй.* Билгеләнгән көнне иртәнге сәгать тугызга кыз йортында мунча ягып куела. Егет ягыннан иң якын 10-13 пар кунакка килә. Барысы да парлы (элек атка утырып килгәнгә әле дә аларны «олау» дип атыйлар), һәрберсен машина китереп китә. Машиналар кояш чыгышына каршы килә. Беренче олау булып кода белән кодагый китерелә. Аларны кода-кодагый каршы ала, машинадан төшергә булыша, савымнарны алыша. Кияү белән кәләш шоферга бүләк бирә. Шулай бөтен олаулар каршы алына, өйгә озатыла. Машиналар кунакларны китерәләр дә китәләр, яңа машинага урын бирәләр. Олауларны каршы алуга авылда бик зур әһәмият бирелә, чөнки кызыклы элементлар кертеп бик күңелле ясап була аны. Кемдер һәр кунакны үлчәп кертә (авырлыгынмы, буенмы), кемдер машинадан төшерү белән зур тазга утыртып ишегалдына кадәр тартып бара, кемдер носилкага утыртып күтәреп бара, кемдер биетә яисә җырлата. Бу күренешкә беркем дә ачуланмый, нинди генә шаяртулар ишетсә дә кушылып көлә генә. Бөтен кеше килеп беткәннән соң хатыннар башка йортка кунакка китә, ирләр өйгә керә. Алар янына муллалар, тирә-күршедән ирләр дә чакырыла. Никах укыла. Ирләр чыгып башка җиргә китә, хатыннар кайта. Муллалар, күршеләр бармый. Ике туй көне эчендә 10 урынга (туй алдыручы йортка) да барып өлгерә алалар кунаклар. Бу күренеш *туй алдыру* дип атала. Кыз ягыннан якын туганнар яки күршеләр Ак туй кунакларын үзләрендә кунак итәләр. Ирләр хатыннардан аерым йөри, алар беренче көнне иртә белән үк аерыла (ирләр өйгә кереп кунак булдылар, хатын-кызлар башка җиргә киттеләр). Әгәр алдыручылар күп булса, бер көн эчендә 3-5 урынга бара алалар. Йорттан-йортка җәяү йөриләр. Һәрбер хуҗа берсеннән-берсе уздырырга тели: төрледән-төрле ризык әзерли, кунакларны кыстый, сыйларга тырыша. Табыннар бик мул итеп әзерләнә, кеше өстәленнән арттырырга тырышып бизәлә, тутырыла. Бу көнгә кадәр кешедә

күренмәгән азыгы булса, йорт-җире белән шаккаттырса, хуҗа бик горурлана. Шул көннең бизәге - савым чыгару, бүләкләр бирешү (бу хуҗалар өчен чын-чынлап четерекле, авыр өлеше, чөнки беркемнең дә савымын онытмаска, кемнеке икәнен бутамаска, чиратын белергә, бүләкләрең бәяле булырга кирәк). Бу хатын-кызлар кергәч була, ирләр боларны күрми, катнашмый. Һәр пар савым белән килә, алар барысы да әйтеп-күрсәтеп табынга чыгарыла: 1 бизәлгән пешкән каз, матур итеп пешерелгән ипи, торт яки чәк-чәк (барысы бергә 3 төрле). Кодагый исә 5 төрле алып килә - нинди дә булса пирог (эчлек кыстырып пешергән камыр азыгы бездә кукыль), торт өстәлә. Ясин укыла. Табынга һәрвакыттагыча самавыр чәе, чәй янына гөбәдия, савымнар, токмач, ит чыга. Мәҗлес ахырында хуҗабикә һәр парга бүләкләр бирә. Иң башлап кода-кодагыйга (табында кодагый гына була), аннан барлык килүче туганнарга. Бүләкләр бай булырга тиеш, чөнки халык теленә калуың бар. Мәсьәлән, кодагыйга мамык шәл яки модалы кием, 1-2 меңнән дә ким булмый инде ул. Ике як та бүләкләрне бер чамадарак алырга тырыша.

Икенче көнне иртән кунаклар тагын төп йортта җыелалар, ирләр-хатыннарга аерылып кунакка таралышалар. Икенче көнне дә мунча ягыла, тик керүчеләре булмый инде. Кич белән төп йортта очрашалар, таңга кадәр кунак булалар. Бу туй озату дип атала, күршеләрдән дә парлы кунаклар чакырыла. Туйны алып барырга артистлар яки шуның белән шөгыльләнүче авыл кешеләре чакырыла (артистлар бәярәккә төшәчәк), видеога төшерелә, теләкләр теләнә.

Туйның бу өлеше матурлыгы белән генә түгел, чыгымнары белән дә истә кала. Чын туй уздырыла, тагын хуҗалар-кыз ягы (егет ягы кунак кына булып йөри) һәр туй алдыручы кешегә бурычлы да булып кала (үзенә дә туй алдырасы була).

*Ступай.* Ак туй беткәннең икенче көнендә кыз йортында хатын-кызлар гына катнашында шундый кызык исем бирелгән мәҗлес уза. Бөтен тиешле ризыкка өстәп белен пешерелә. Егет ягыннан Ак туйга килгән хатын-кызлар, бөтен туй алдыручы йортлардан хуҗабикәләр чакырыла. Шуның белән Ак туй тәмам була.

*Кызыл туй*. Бу туй инде егет ягында 3 көн уза. Кичке тугыз-уннарда башланып иртәнге дүртләргә кадәр бара (Шыгырданда кичке кунак бик соң башлана). Беренче көнне картрак, икенче көнне – яшьрәк парлылар, өченче көнне – егет-кызлар чакырыла. Бүгенгесе көнне Шыгырданда бөтен Кызыл туйлар диярлек аерым пешекче, алып баручылар, видеога төшерүчеләр яллап үткәрелә.

*Сый.* Кызыл туй көндез үтә торган сый белән башланып китә. Иртәнге сәгать унга кыз ягындагы өлкән яшьтәге хатыннар чакырыла. Алар Ак туйга килгән кебек савымнар белән килә - төп кодагый - 5 төрле, калганнары - 3 төрле. Бүләкләр дә Ак туйдагы кебек бирелә (кара-каршы бирешү була). Ясин укыла. Савымнар табынга чыгарыла, тиешле

вакытында чәй, токмач, ит чыгарыла. Туйның иң матур көне – законлы никахлашу көне (регистрация). Башка көннәрдә кияү белән кәләш өстәл артына утырмый, кунакларны сыйларга булыша. Туй күлмәге язылышкан көнне генә киелә, кияү белән кәләш табынга утыра.

Язылышып кайтканны бөтен күрше-күлән көтеп тора, ләкин ул тиз генә булмый әле. Яшьләр ЗАГСтан соң, мәчеткә туктап, муллага сәдака биреп, дога кылдырып чыгалар. Аннан Бөек Ватан сугышына куелган һәйкәлгә чәчәкләр куялар да урманга яки нинди дә булса кафега (кыш көне булса) китәләр. Кияү белән килен утыра торган машина аерым бәяле була, шуңа күрә бәяле чит ил машинасы яллыйлар. Урманнан кайтканда бөтен яшьләр машиналар белән кыз йортына юл алалар. Өй алдында өстәл тезелгән була, самавырлар кайнатыла, белен пешерелә. Килгән туй кунаклары татарча бииләр, җыелган күрше-күләнне биетәләр, өстәл янына барып тамак ялгап алалар, ләкин өйгә кермиләр (бу ярамаган эш булып санала).

Капкаларны ачып куеп каенана яшьләрнең өйгә кайтуын көтеп ала. Кайту белән киленне ак мендәргә бастыра, икесенә дә бал һәм май, ипи каптыра. Кияү белән кәләш бөтен кешене дә биетеп чыгалар. Кияү кәләшен күтәреп өйгә алып керә. Туйда йөргән бөтен кеше өйгә уза, кунак була. Кичке мәҗлескә табыннар әзерләнә.

Шыгырдан Кызыл туеның тагын бер үзенчәлеге бар – туйга килүче кунаклар бүләкләрен өстәлгә узганчы ук биреп, яздырып калдыра. Алгы бүлмәдә билгеләнгән бер кеше шул вазифаны үти: килүче кешенең кем икәнен һәм нинди бүләк салганын язып тора. 10 ел чамасы элек тә әлеге бу исемлекне табынга чыгып укып биргәннәр (кечкенә бүләк алып барудан курыкканнар, чөнки оятка калуың бар). Соңгы елларда инде исемлек укылмый, ә язып бару йоласы яшәп килә.

Бүгенге көндә Шыгырдандагы күп йолалар ясалмарак та үткәрелә, әмма нигездә шыгырданлылар туй йолаларын саклап баралар. Тормыш үзгәрә, үсә, йортлар ике катлы, өйләрдә интернет, компьютер, «олаулар» урынына машиналар йөри, ә йолалар шул ук. Шыгырданлылар моңа изге гадәт итеп карыйлар. Йолаларга шундый мөнәсәбәт аларны саклауда зур роль уйный.

Авылдагы туйларның төрле елларда ничек узуын күзәтү шуны да раслый: дәверләр алышына, әмма гореф-гадәт асыл нигезләрен саклап, чит элементларны үзенә алып, үзенеке итә. Югарыда тарихи дәверләгә якынча гына бүлеп караган йолаларны да, бүген Шыгырдан татары һичкайчан да чуашныкы, коммунистларныкы, борынгы төрки чор дип карамый. Ул Шыгырданныкы гына. Бу йолалар чынлыкта да борынгыдан киләчәккә сукмак булып тора. Һәрхәлдә, шыгырданлылар үзләренчә шундый сукмак салып баралар.

## «Йола фольклоры» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары

1. Язгы циклга керүче календарь йолалар.
2. Яңа елны каршылау белән бәйле йолалар.
3. Татар фольклорында өмәләр һәм аларның поэзиясе.
4. Сабан туе һәм җыен йолалары.
5. Йола иҗатында сынамышлар.
6. Бала туу белән бәйле йолаларны комплекслы өйрәнү.
7. Никах туе йоласы: элек һәм хәзер.
8. Күмү һәм искә алу йолалары.
9. Хәрби хезмәткә озату белән бәйле йолалар.
10. Себер татарлары көнкүрешендә кузайтын йоласы.

## ТЕМА № 4. ЭПОС- ДАСТАННАР

Дастан – данлау, кемнәрнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны, язмышларны халык күңеленә язып куеп, киләчәк буыннар хәтеренә җиткерү, тарихта калдыру дигән сүз.

Дастан – төрки һәм фарсы фольклорында һәм әдәбиятларындагы эпик характердагы әсәр. Икенче төрле аларны эпос дип тә атыйлар. Эпос (грекчадан, сүз, сөйләм, хикәяләү мәгънәсендә) төшенчәсенең фольклористикада һәм әдәбият белемендә киң һәм тар мәгънәләре бар. Беренчедән ул вакыйгалылыкка, хикәяләүгә нигезләнгән әдәби төрне белдерә һәм шушы сыйфатларга ия булган төрле әдәби һәм фольклор жанрларын үз эченә ала. Тар мәгънәдә кулланылганда исә әкияти-мифологик һәм героик яки романтик планда хикәяләүче фольклор жанрына, шулай ук халык эпосы йогынтысында формалашкан әдәби әсәрләргә карата кулланыла.

Дастан – гадәттә, әкият сюжетларын, риваять-легендаларны эшкәртеп язган әсәр. Шуңа күрә аңа әлеге жанрлардагы маҗаралылык, сихри тылсым, бәет һәм җырлардагы шигъри бизәкләр, мәкаль һәм әйтемнәрдәге хикмәтле фикерләр хас. Дастанга гына хас булган, аның кыйммәтен, шигъри яңгырашын билгели торган сыйфатлар бар. Беренчесе – дастанда сурәтләнгән вакыйгаларның реаль, тарихи җирлеге булу. Әлеге вакыйгалар барган урыннар төгәл билгеләнә, вакыт та конкрет тарихи чорга тәңгәл килә. Икенчедән, әсәрдә халык хыялындагы иң матур сыйфатларны үзенә туплаган герой тасвирлана. Тарихи дастаннарда (икенче төрле тарихи-героик эпос дип атала) ул – тарихта билгеле булган реаль шәхес. Өченчедән, дастаннар искиткеч гүзәл, халыкчан тел белән иҗат ителгәннәр. Алардагы сурәтле сүз хәзинәсе халкыбызның меңләгән тел бизәкләрен, хикмәтле гыйбарәләрен, мәкаль-әйтемнәрен, канатлы тәгъбирләрен үзенә җыйган. Дастаннар бик зур күләмле, еш кына шигырь белән иҗат ителгән. Шуңа күрә аларны теләсә кем ятлый һәм сөйли

алмаган. Аларны иҗат иткән һәм башкарган кеше бик сәләтле, искиткеч хәтерле һәм фикерле кеше булган. Дастаннарны бик борынгы чорлардан безнең көннәргә китереп җиткергән мондый кешеләрне чичән, җырау яки дастанчы дип атаганнар.

Ф.Урманчеев дастаннарны түбәндәге төркемчәләргә бүләргә тәкъдим итә: 1) борынгы батырлык яки әкияти-мифологик эпос: «Алпамша»; «Түләк һәм Сусылу», «Йир Төшлек», «Алтаин Саин Сөмә»;

2) батырлык дастаннары: «Ак Күбек», «Идегәй»;

3) мәхәббәт дастаннары:«Кузы Күрпәч белән Баян-Сылу»;

4) китаби дастан «Таһирбелән Зөһрә» һ.б.

Ә М.Бакиров дәреслегендә эпос дастаннарның фольклористикада һәм тюркологиядә кабул ителгән бүленеше тәкъдим ителә:»

1) архаик-героик яки, төгәлрәк термин белән әйткәндә, әкияти мифологик эпос;

2) классик героик эпос;

3) тарихи-героик эпос.

Архаик-героик эпос борынгы ыруглык чорына барып тоташучы конфликтны –табигать белән кеше арасындагы бәрелешне гәүдәләндерә һәм борынгы кешенең бу көрәштә яулаган беренче җиңүләрен, чит кабиләләр арасындагы бәрелешләрне, батырлык кылып өйләнү, ягъни героик никахлашу вакыйгаларын чагылдыра. Бу төргә «Түләк һәм Сусылу», «Йир Төшлек» дастаннары керә.

Классик-героик дастаннар иҗтимагый үсешнең соңгырак чорында , ыру-кабиләләр җирлегендә халыклар формалашканда һәм борынгы дәүләтләр барлыкка килгән чорда туган дип санала. Бу төр дастаннарда тарихилык конкретрак була, реаль тормышка якыная. Бу төр әсәрләрнең үзәгендә туган җирне һәм халкыңны тышкы дошманнардан саклау идеясе үткәрелә. Классик героик төр дастаннар әкияти-мифологик эпос-дастаннан үсеп чыкканга, аларда да аерым архаик катламнар саклана. Бу төргә «Алпамша», «Ак Көбәк» дастаннары керә.

Тарихи-героик дастаннар жанр үсешенең соңгы баскычында туган дип фаразлана. Бу төр дастаннарның үзенчәлеге –эпик әсәрдә тарихи шәхесләргә яки реаль вакыйгаларга бәйләнешле материалның урын алуында. Әмма бу дастаннар тарихи вакыйга һәм даталарның әдәби елъязмасы түгел. Монда сәнгати уйланма һәм иҗади фантазия дә җитәрлек. Бу төрнең классик үрнәкләре булып «Гайсә улы Әмәт», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннары санала.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

1. «Ак Күбәк» дастанының эчтәлеге, сюжетның борынгылыгы, әсәрдәге төп мотивлар. Әсәрнең вариант һәм версияләре. Дастанның төп идеясе.

2. «Алпамша» дастаны. Эпос батырына хас сыйфатлар. Дастанның башка төрки версияләре булу. Татар халык Алпамша дастанының эчтәлеге. Алпамша архаик дастанының болгар чоры фольклорындагы урыны.

3. «Җик Мәргән» дастаны. Әсәрдә ил батырының хан хакимиятенә каршы көрәше сурәтләнү. Эчтәлекнең катлаулы һәм каршылыклы булуы. Эпик традицияләр сакланышы. Әсәрнең версия һәм вариантлары, төп идеясе.

4. «Чура батыр» дастаны. Дастанда чагылыш тапкан төп вакыйга буларак Казанның руслар тарафыннан яулануы. Дастанда төп каһарман, аңа хас сыйфатлар. Тарихи дөреслек һәм дастани образ, әсәрнең чынбарлык вакыйгаларына бәйләнеше. Чура батыр образы. Аның кырым татарлары, нугай, казакъ халыкларындагы популярлыгы. Дастанның әһәмияте.

5. Мәхәббәт дастаннары («Кузы Күрпәч белән Баян-сылу», «Камбәр», «Ләйлә»). Аларга хас гомуми үзенчәлекләр. «Кузы Күрпәч белән Баян-сылу» дастанының версия һәм вариантлары. Дастанда традицион сюжет, төп мотивлар, шигъри үзенчәлек.

6. Китаби дастаннар («Кыйссаи Йосыф», «Таһир-Зөһр», «Бүз егет»). Аларга билгеләмә. «Таһир белән Зөһрә» дастанының версия һәм вариантлары. Традицион сюжет, төп мотивлар, әсәрнең шигърияте. Дастанда традицион образларның бирелеше. Алтын Урда чорында дастан булып оешуы, XX йөз башынача кульязма һәм китап буларак таралышы. Дастанның әдәбиятка тәэсире.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен «Идегәй»дастанының кыскартылган варианты***

## ИДЕГӘЙ

### Туктамыш хан белән Аксак Тимер низагы һәм Котлыкыя би белән углы Идегәйнең үлемгә хөкем ителгәне

Борын үткән заманда
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда –
Данлы кыпчак җирендә,
Татардан туган Нугай илендә
Туктамыш дигән хан булды;
Ил булганга – ил булды,
Әйдәгәне мал булды.
Сарай дигән каласы,
Сиксән күчә[1] арасы,
Сары мәрмәр Алтын таш
Сигез йортка дан булды,
Аларда дан булмады.
Суна[2] тибеп каз алган
Кара лачын Төкле Аяк –

[1] *Күчә* –урам.

[2] *Суна* — кыр үрдәгенең сирәк очрый торган төре.

Яу булганга – яу булды.
Биләгәне кол булды,

Лачыны ияр кашында,
Чирүле күлдә кош чөеп
Дәүран[3] сөргән хан булды.
Ул дәрья да бу дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья,
Сыр-Дәрьядан – Сәмәрканд;
Сәмәркандта утырган
Әмир Бырлас Шаһ Тимер
Туктамышка хат бирде.
Ул хатында бу диде:
«Җаектан ашу Ак Түбә[4],
Иделдән ашу Күк Түбә,
Күк Түбәдә ак сарай;
Анда утырган Туктамыш,
Ул Туктамыш син булсаң,
Курымны[5] эчкән син булсаң,
Сине баккан мин булсам,
Тугрына[6] кунган Төкле аяк
Тугыз йортка дан булса,
Аны миңа тапшыргыл».
Туктамыштай олы хан,
Укыган соң бу хатны,
Уңына торып бер бакты,
Сулына торып бер бакты,
Эченә суык боз төште –
Туң тимердәй күк булды,
Эченә кызу ут төште –
Сум [7] тимердәй кызарды.
Кызарган соң ут булды.
Анда җавап хат бирде,
Ел артыннан яз килде,
Чирүле күлгә кош килде,
Ау лачыны бар иде,
Тугыз йортка дан булды.

Ул хатында бу диде:
«Ул дәрья да бу дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья,
Сыр-Дәрьядан – Сәмәрканд;
Сәмәркандта утырган
Аягы чонтык[9] Шаһ Тимер
Әмир Бырлас син булсаң;
Аргы атасы[10] – Чыңгыз хан,
Бирге атасы[11] – Туйгуҗа,
Аннан туган Туктамыш,
Ул Туктамыш мин булсам;
Күк Түбәдә ак сарай,
Анда утырган хан булсам,
Ил булганга – ил булсам,
Яу булганга – яу булсам.
Кара лачын Төкле Аяк
Сиңа булмас, Шаһ Тимер!
Аннан кала Бүз Тойгын[12]–
Ул да булмас, Шаһ Тимер!
И Шаһ Тимер, Шаһ Тимер!
Тешең җитсә, таш кимер!
Сигез йортка сыймадың,
Тугыз йортны куймадың,
Сычкан типкән бидаяк[13]
Сиңа булсын, Шаһ Тимер!»
Хат бөтелде[14], сүз бетте,
Ай бетте дә көн бетте;
Аннан да үтеп ак булды.
Азамат ир Туктамыш
Оя баскан Төкле Аяк –
Ул да бала чыгарды.
Кош чөюгә мәл[15] килде.

---

[3] *Дәүран* – гомер, вакыт.
[4] *Ак Түбә, Күк түбә* – Алтын Урда заманында Идел белән Сырдәрья арасындагы җирләр
[5] *Курымны*—кымыз
[6] *Тугыр*– ирдә ау кошы кундыру урыны.
[7] *Сум* - саф.
[9] *Чонтык* – бер аягы кыска, аксак.
[10] *Аргы атасы*– бабасы.
[11] *Бирге атасы*– үз атасы.

Күгәл[8] белән каз килде.
Ау кошларын караган
Котлыкыя би иде.
Азамат ир Туктамыш
Аны үзенә чакыртты.

(Туктамыш хан кушуы буенча Котлыкыя би Төкле Аяк чыгарган ике лачынны алып килә. Аларны очыртып карыйлар, әмма кошлар очмый. Туктамыш хан Котлыкыяны ау лачыны балаларын Шаһ Тимергә саткансың дип, хыянәттә гаепли. Котлыкыя би аңа каршы кыю рәвештә җавап бирә, ханның үзен ил белән идарә итә белмәүдә гаепли).

–Били белсәң, ханиям,
Икселмәс[16] дәүләт бу иде.
Алтын Урда, Ак Урда
Алтмыш йортка юл иде,
Индегенең[17] көнендә
Кәрван, дөя килалмый,
Дәрвазаңнан[18] иңалмый,
Дәрвазаңнан иңгәндә,
Сиңа бүлеп биралмый.
Синнән дәүләт тайганы
Шул түгелме, ханиям?
Янә торып, янә әйтсәм,
Идел сырты Сары тау
Илем кунган йорт иде,
Илем йортта куймадың,
Иделне ике кичердең,
Анда да аны куймадың,
Кырлы курай шур[19] татыр
Кола чүлгә китердең,
Комкәнт дигән каламны
Комга түгеп бетердең!
Бер башымны ике итеп,
Ике ханга баш орсам,
Ул да булса, ханиям,
Йорттан йортым күчкәне –
Бездән ырыс киткәне,
Куштан кошның күчкәне –
Сездән дәүләт киткәне,
Чабучы булсаң, баш – менә!
Түгүче булсаң, кан – менә!
Азамат ир Туктамыш
Ике биен чакырды:
Чакмагыш би, Дөрмән би
Анда килеп баш орды.
Туктамыш хан анда әйтте:
–Әй, Дөрмән би, Дөрмән би,

Айбалтаңны тот, – диде. –
Айпычагың так, – диде. –
Котлыкыя ялган бине
Муйнын ора чап! – диде. –
Пәридән алган хатыны,
Буында типкән кан калыр.
Буыннан буын чабылса,
Ул чагында ни калыр?
Йорт урынында яу калыр.
Яу чапканда ни калыр?

---

[12] *Бүз тойгын* – ак карчыга
[13] *Бидаяк* – карчыга
[14] *Бөтелде* – язылды
[15] *Мәл* – вакыт
[8] *Күгәл* – кыр үрдәге
[16] *Икселмәс* – кимемәс.
[17] *Индеге* – хәзерге.
[18] *Дәрваза* – шәһәр капкасы.
[19] *Шур* – тозлы җир, су.

Бишектә ятыр баласы;
Аны да ташлап калдырган
Пәридән булган анасы –
Ул баланы тап! – диде. –
Бишеген ора чап! – диде. –
Шунда торган Җантимер –
Киң кунычлы Җантимер –
Алты угыллы ир иде;
Атагы– өлкән аталык,
Йортта өлкән пир[20] иде;
Туктамышның кашында
Киңәше киң килбәтле,
Сүзе үткән би иде;
Котлыкыя би белән,
Кан тамызып ак сөткә,
Ант эчешкән ир иде.
Торып килеп Җантимер,
Хан алдында йөгенде[21]:
Җир китәр дә, ни калыр?
Җиреннән тайган ил калыр.
Ил китәр дә, ни калыр?
Ил киткәндә йорт калыр,
Йорт китәр дә, сөт калыр;
Ак күкрәктән сөт имгән
Сүзе татлы тел калыр.
Тел китәр дә, ни калыр?
Язганнан язган хат калыр.
Баш китәр дә, ни калыр?
Ул да карап калмады.
Ни кыласын аңлады,
Өенә карый юл алды.
Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл – Кобогыл.
Алып килеп ул аны,
Котлыкыя өенә,
Салып куеп бишеккә,
Котлыкыя баласын
Ялгыз башы каңгырап,
Куйдай булып маңгырап,
Чүл-далада тинтерәп,
Дуадактай[22] хан калыр.
Аталыгым хакына
Хаталыгын кич[23], – диде,
Хаталыгын кичмәсәң,
Бишектә яткан баласы –
Кашык канын кич, – диде. –
Буында типкән кан калсын,
Баладан кулың тарт[24], – диде. –
Каныннан аның кайт! – диде.
Җантимер би әйткәндә,
Туктамыштай олы хан
Аның телен алмады,
Сүзенә колак салмады.
Ачуы аннан каты иде,
Кичүе аннан кайт[25] иде.
Котлыкайны тоттырды,
Кулына кыл-җеп тактырды.
Чапкылыкка мендереп,
Чүң[26] бүкәнгә чүктереп,
Айбалталы Дөрмән бидән
Анда башын чаптырды.
Җантимердәй атага
Хан колагын салмады.
Хан колагын салмаса,

Киң кунычлы Җантимер,
Кунычына яшереп,
Үз өенә китерде.
Ул баланы Җантимер,
Итегемнән алдым, дип,
Итегемнән алганда,
Илсез-көнсез калдың, дип,
Атын куйды Идегәй.

[20] *Пир* – изге кеше.
[21] *Йөгенде* – тезләнде.
[22] *Дуадак* – ялгыз, нәселсез.
[23] *Кич* – кичер, гафу ит.
[24] *Тарт* – кире ал.
[25] *Кайт* – кайтыш, ким.
[26] *Чүң* – зур.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар кайсы чорда бара?
2. Текстта аталган шәһәр исемнәре һәм башка географик атамалар сезгә танышмы, алар бүген дә сакланып калганмы? Сез алар хакында ниләр беләсез?
3. Туктамыш һәм Аксак Тимернең кемнәр булуын билгеләгез. Алар арасында килеп чыккан низагның сәбәпләрен ачыклагыз.
4. Ни өчен Туктамыш Котлыкыяны үлемгә хөкем итә?
5. Җантимер үз баласын үлем куркынычы астына куеп дөрес эшлиме?
6. Идегәй дигән исемнең ничек килеп чыкканын аңлатыгыз.
7. Аңлашылмаган сүзләрне ачыклап бетерегез, бүлекне тагын бер кат игътибар белән укып чыгыгыз.

**Идегәйнең Кобогыл исемендә үсеп, Туктамыш хан сараенда түрә булганы.**

Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл – Кобогыл,
Кобогыл дип беленеп,
Үсә куйды Идегәй.
Бер яшендә бер икән,
Баскан җире шил[27] икән,
Ике яшьтә ил булды,
Әйткән сүзе им булды.
Өч яшендә аталык
Остаздан китап башлатты.
Дүрт яшендә дан булды,
Фирасәте[28] фаш булды;
Биш яшенә килгәндә,
Җантимернең биш угыл –
Бишенә дә баш булды.
Алтысында ат менде,
Җидесендә, җай[29] тартып,
Җиде тотам ук атты.
Сигез-тугыз булганда,
Сигез тукмак сындырып,

Туң тимергә кул орды.
Унга җитте – ул булды,
Ул ни дисә, шул булды;
Чүлгә чыгып басканда,
Чүл ярылып юл булды,
Тауга чыгып басканда,
Тау сыгылып уй булды.
Унберендә бер булды,
Уйпыксыз чичән[30] ул булды;
Уникегә җиткәндә,
Түрәсен биргән ул булды.
Унбишенә килгәндә,
Туксан башлы Урданың
Туксан углы бер булып,
Айдалага[35] килгәндә,
Алар белән ант тотты.
«Көрәшеп барын мин ексам,
Мин барыңа баш, – диде. –
Көрәшеп берең мине екса,
Улыгыз миңа баш», – диде.

---

[27] *Шил* – чокыр, иңкү җир.
[28] *Фирасәте* – зиһенлелек, сизгерлек.
[29] *Җай* – җәя
[30] *Уйпыксыз чичән* – тел остасы.
[35] *Айдалага* – ачык, такыр дала.

Алпамыштай ир булды.
«Ир булган  соң җир булыйм,
Иңсәм җиргә тисен, дип,
Ил игелегем күрсен, дип,
Асыраган чал бабам –
Ул игелегем күрсен», – дип,
Тауда ятты, тай бакты,
Кырда ятты, куй бакты,
Елкы бакты, кол булды,
Өстендә ямар тун булды;
Башы белән баш булды,
Атагы[31] белән дан булды,
Түрәсе [32]белән фаш булды,
Ятимнәргә яр булды.
Идегәй андый ир булды:
Аты юкка – ат булды,
Чүлләгәнгә[33] – су булды,
Адашканга юл булды;
Ялгызга – ясак[34]
Җәяүгә – таяк ул булды.
Ундүртенә килгәндә,
Ундүрт дауны бетереп
Анда торып моны әйтте:
– Туксан бала айдалада,
Туксаны булып бүз[38] бала,
Бүз балалык итә белмәдең –
Башлап сәлам бирмәдең.
Ханыгыз булган минме өлкән,
Әллә юкса сезме өлкән?!
Анда әйтте Идегәй:
– Башта булсаң син өлкән,
Аякта[39] чыгар без өлкән.
Әйтеп бирсәм ник өлкән –
Туксан башлы Урданың
Янымда туксан баласы,
Кушагын алып ту[36] итеп,
Анда мәйдан күтәрде.
Туксан башлы Урданың
Туксан углы җыелып,
Идегәй белән көрәш тотканда,
Екса ега белмәде –
Чалса чала белмәде –
Барын екты Идегәй;
Еккан береннән тун алып,
Айдалага өйдерде.
Өеп салып Идегәй,
Өстенә менеп тайчынды.
– Туктамыш хан тәхетенә
Мин мендем! – дип яр[37] салды
Аннан әйтте Идегәй:
– Анау килгән ак атлы –
Ул Туктамыш хан булса,
Алдында баш имәгез,
Үзе сәлам бирмәсә,
Башлап сәлам бирмәгез...
Туктамыштай олы хан

Шушы туксан баланың
Яшен санап салсам мин,
Анда чыгар без өлкән...
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән улы Урман би –
Туксан бала эчендә
Каракчылык кылган би:
Балалар менгән таяк ат –
Аны урлап тотылды...
Өч урлады – котылды,
Дүртенчедә тотылды.

---

[31] *Атак, ат* – исем..
[32] *Түрәсе* – хөкем, гаделлек.
[33] *Чүлләгәнгә* – сусаганга.
[34] *Ясак* – монда: ярдәм, таяныч, корал.
[36] *Ту*– байрак.
[37] *Яр* – аваз, хәбәр.
[38] *Бүз* – асыл, затлы
[39] *Аякта* – азакта, соңында.

*(Идегәй Урман бинең башын чабарга дип хөкем чыгара. Моны ишетеп, Туктамыш хан Идегәйне сараена чакырып ала.)*

Туктамыштай олы хан
Идегәйне алдырды:
–Әй Кобогыл, Кобыгыл,
Яхшы атаның баласы–
Җантимернең углы идең;
Елкы бактың, куй бактың,
Айдалага ут яктың:
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән углы Урман би,
Аның башын ник чаптың?
Анда әйтте Идегәй:
–Илеңдә йөргән каракчы
Өч ат урлап тотылса,
Дүртенчедә тотылса,
Синең түрәң[40] буенча
Дүртенчедә чабылса,
Дөрмән улы Урман би –
Ул да шулай тотылды,
Синең хөкемең буенча
Ул да шулай чабылды,
Аның аргысын мин белмәм...

*(Туктамыш хан Кобогылны бу гамәле өчен гаепли алмый, аны дөрес эшләгән дип саный. )*

Кобогылга аны әйтте:
–Әй Кобогыл, Кобогыл,
Сараемда кал, – диде. –
Өстеңдәге иске тун –

Ул туныңны сал, – диде...
Анда әйтте Идегәй:
–Атың булса, багамын,
Утың булса, ягамын,
Мин яхшыга яхшымын,
Мин яманга яманмын,
Кул биргәннең колымын –
Хезмәтеңдә каламын.
Торып килеп Идегәй,
Хан ни бирсә, аны алды:
Ал кара[41] кеш тун[42] икән –
Кияренә аны алды;
Тимгел чуар ат икән –
Менәренә аны алды;
Күн давылбаз[43] бар икән –
Төяренә аны алды;
Асыл шонкар кош икән –
Чөяренә аны алды;
Бер бите айдай балкыган,
Кырымнан калын яу килсә,
Яуны кырды Идегәй.
Туктамыштай олы хан
Идегәйнең көнендә
Яу белән даудан котылды.
Сарай дигән калада
Дүрт дәрвaза бар икән:
Икәве бикле булганда,
Икәвен ачык куйдырды,
Береннән килгән кәрваны
Береннән чыгып бетә алмый.
Божрасы бөтен алкадай
Боралып килгән мал булды.
Туктамыштай олы хан,
Идегәйдәй ирнең көнендә
Ил казнасы бай булды,
Биләгәне кол булды,
Әйләгәне мал булды;
Җәеп салсаң көмешен –

---

[40]*Түрә* – хөкем, закон.
[41] *Ал кара* – чем-кара.
[42] *Кеш тун* – кыйммәтле, затлы мех бирә торган җәнлек тиресеннән тегелгән тун.
[43] *Давылбаз*– күннән ясалган барабан.

Бер бите көндәй салкыган,
Болгардаен болкыган,
Җофардаен аңкыган
Айтулы атлы ару кыз икән –
Туеннан туен кылдырып,
Сөяренә аны алды.
Кырымнан кыен дау килсә,
Дауны кырды Идегәй;
Җәйрәп яткан күл булды;
Өеп салсаң алтынын –
Әлдермештәй тау булды.
Ашаган казы ял булды,
Эчкәне сары бал булды.
Әмма Идегәй үзе кем?
Анысын белмәс хан булды.

*(Туктамыш ханның хатыны Йәникә игезәк кызлар таба. Аларның олысына Ханәкә, кечесенә Көнәкә дип исем кушалар. Бу шатлыктан хан утыз көн уен, кырык көн туен үткәрә. Идегәйнең улы туа. Аңа Норадын дип исем куша, бәби туен бик зурлап, ханнар дәрәҗәсендә үткәрә. Йәникәнең моңа һәм, гомумән, Кобогылның халык арасында абруе үсүгә бик ачуы килә. Ул Туктамышны, чичән-җырчыларны чакыртып, Кобогылның кем икәнен сорарга кирәк дип котырта. Туктамыш хан кол булган Кобогылның үзен хан белән тиң итеп тотуын күреп, моның серен беләсе килә. Зур туй ясатып, тугыз җырчыны чакыртып сорыйлар, берсе дә Кобогылның кем икәнен әйтә алмый. Җавап таба алмагач, йөз туксан биш яшьлек Субра картны алып киләләр. )*

Күп батырны мин күрдем,
Күп батырны мин белдем,
Яшем йөз туксанга килгәндә,
Чыкмаган җан йөргәндә,
Миннән дәүран [44] үткәндә,
Сезгә дәүран җиткәндә,
Утыз тешем беткәндә,
Шунча ирләр күргәндә
Утыз ханның гомерен үткәндә,
Кобогылдай ирне мин
Бер күрмәгән картыңмын!
Кашларына карасам,
Каләмнән пәйда булгандай;
Күзләренә карасам,
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай;
Буйларына карасам.
Нурдан пәйда булгандай!
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул – Кобогыл!

*(Субра чичән Идегәйнең, Ак урданы алып, Туктамышны тәхеттән куачагын да әйтә. Моны ишеткән Йәникә, Идегәйгә агулы бал бирергә куша. Әмма Идегәйнең сарайдагы дуслары Аңгысын белән Тынгысын, моны Идегәйгә сиздерәләр. Бөтен атларның өзәңге бауларын кисеп чыгалар. Идегәй Тим Чуар исемле атына атланып хан сараеннан качып*

[44] *Дәүран* – гомер, вакыт.

*китә; туган җирен ташлап, Туктамышның дошманы Аксак Тимергә юнәлә).*

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Идегәйнең бала чагы тасвирланган урыннарны укыгыз. Гадәти җир кешесе мондый сыйфатларга ия була аламы?
2. Идегәйнең лидерлык сыйфатлары нинди вакыйгада күренә? Ул яшьтәшләре белән гадел идарә итәме?
3. Идегәй ханга хезмәт итә башлагач, Туктамыш һәм дәүләт тормышында нәрсәләр үзгәрә?
4. Туктамышның Идегәйгә карата мөнәсәбәте үзгәрүгә нәрсә сәбәп була?
5. Идегәйне халык ни өчен ярата?
6. Субра чичән образы турында нәрсә әйтә аласыз? Тормышта шушы яшькә җиткән кешеләр бармы?
7. Идегәй ни өчен сарайдан качып китә?

*(Идегәй Ак Урдадан Җантимернең биш улы һәм башкалар белән унсигез кеше булып качып китә. Юлда Кара Тиен Алып белән сугышып, аны үтерә, Аксак Тимернең кызы Акбеләкне тоткынлыктан коткара. Кара Тиен Алып, үләр алдыннан Идегәйгә аның туганы булуын әйтә, сине каргамыйм, әмма балаң белән ызгышып, уң күзең чыксын, ди. Идегәй Акбеләкне Сәмаркандка илтеп, этисенә тапшыра, би дәрәҗәсен алып, шунда яши башлый.*

*Идегәй качканнан соң, Туктамыш хан аның улы Норадынны мәсхәрәләп, Ак Урдадан куып җибәрә. Норадын, озын юллар үтеп, этисе янына Сәмаркандка килеп җитә.)*

Азамат ир Идегәй
Хәл сорашып белгәндә.
Норадынның ат-тунын,
Бар шайманын күргәндә,
Туктамышның нияте
Ни булганын аңлады.
Норадынга өй бирде,
Үз кулыннан сый бирде.
Менәренә ат бирде,
Уеннан уен калдырып,
Норадынга ял бирде.
Айлар-көннәр үткәчтен,
Норадынны чакыртып:
–Газизем, сөйлә, – дигәндә,

Анда әйтте Идегәй:
–Әй Норадын, Норадын Нидер
синең морадың?
–Әйтсәм әйтим морадым:
Ат та туйган җиренә,
Ир дә туган җиренә;
Кендек каным тамган җир –
Көмеш сулы Идел булганда,
Сине дә куган Туктамыш,
Мине дә куган Туктамыш;
Бабамның башын чаптырган
Әзәлдән яу Туктамыш;
Туктамышта кигем[45] бар,
Кик алганда кинә[46] юк.

[45] *Кик*– үч, үпкә.
[46] *Кинә* –гаеп.

Ир Норадын аны әйтте:
–Ат сөренми җир танымас,
Ил сөренми ил танымас,
Иделдәй илем барында
Шаһ Тимер иле тартмыйдыр,
Һич күңелемә ятмыйдыр,
Таңы таң булып атмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.

Анда әйтте Идегәй:
–Әй, Норадын, Норадын,
Сагынсам да илемне,
Санласам да санымны,
Туктамыштай бер ханны
Хан итеп белгән ул илгә
Янә бер кире кайтмыймын
Илемә ул хан булганда,
Ил күңелемне тартмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.
Анда әйтте Норадын:
– Әй газизем, әй атам,
Сарай белән Болгарның,
Иделдәге илеңнең
Халкы ханнан өркә инде,
Татар белән нугаең
Ханга каршы купты инде,
Идегәй безгә кайтсын дип,
Башыбызда торсын дип,
Сөт белән юган кылычын
Кан белән янә юсын дип,
Үч алганда үпкә юк;
И газизем, и атам,
Каерылып атны тартаек,
Ана Иделгә кайтаек,
Идел багында ятаек.
Ук-садак[1] билдә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!

Болгариның Бодай би
Артымнан куа җитеп әйтте инде.

Әй газизем, әй атам,
Каерылып атны тартаек,
Идел чыгып ятаек!
Ук-садак билдә булганда,
Ил-халык бергә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!
Анда әйтте Идегәй:
– Газизем, асыл икәнсең,
Рас сөйләрсең, морза улым.
Сарай белән Болгарның,
Чулман белән Нократның
Халкы ханнан өреккәндә,
Өркеп мине көткәндә,
Без дә анда булаек;
Ил сүзен тоткан – ир булыр,
Ил сүзен кабул кылаек!

*(Идегәй азатлыкка омтылган халкына ярдәмгә ашыкканда, Шаһ Тимер дә Актүбәне басып алу уе белән гаскәрен җыя, сансыз чирү, кара яу булып, Идел-йортка юнәлә.)*

Җаектан ары Актүбә,
Актүбәгә менгәндә,
Идел-йортны күргәндә,
Туфрагын үбеп ярсулап,
Идегәй аны тулгады[47]:
–И Идел-йорт, Идел-йорт,
Анам килен булган йорт –
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт;
Керем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;

[47] *Тулгау* – көйләп, такмаклап әйтү.

Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт –
Иелеп тәзем кылган[48] йорт;

Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам тоткан йорт,
Котлы булсын туган йорт!
Айдан якты нәрсә юк,
Кара болыт басмаса,
Адәм гарибә шул булыр –
Кайтып илен тапмаса!

Идел- Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Казан-Болгар арасы

Мин барамын, барамын,
Үз илемне аламын;
Яфракларың саргаеп,
Күк тугаең каралып,
Хан Туктамыш кулында
Син ни булдың, туган йорт?
Синдәй илдән аерылган
Мин ни булдым, туган йорт?

*(Туктамыш хан төш күрә, төш юраучы аның җиңеләчәген, кулыннан дәүләт китәчәген әйтә. Идегәй үзенең якыннары белән, Шаһ Тимердән аерылып, Туктамышка каршы кузгалган халкына барып кушыла. Аксак Тимер Туктамыш хан белән сугыша һәм җиңелә. Шуннан соң Туктамыш гаскәре белән Идегәй орыша. Чолганышта калган Туктамыш сараеннан качып китә. Аксак Тимер Сарай, Болгар шәһәрләрен, Ак Урданы җимерә. Туктамышны куа барган Идегәй җимерелгән ил-йортын күреп хәйран кала, Аксак Тимерне үз иленә кире җибәреп, шәһәрләр салырга тотына. )*

Яр салдырды калага,
Яр салдырды далага.
Туктамышның сансыз кол,
Барын-югын җыйдырды.
Җыеп азат кылдырды.
Угылларны сатуга
Бер чигара кылдырды[49].
Кисмә-кисмә сары алтын
Кисеп улҗа[50] кылдырды.

Идел-йортны җыйдырып,
Өлкән бер туй кылдырды.
Агаларны алдырып,
Киңәшсез үскән бу йортны
Киңәшле йорт кылдырды,
Каланы кайта торгызды,
Илне-илгә тутырды,
Уртасына ару урда кундырды.

*(Идегәй һәм аның улы Норадын башыннан бик күп хәлләр кичә, алар күп сугышларда катнашалар. Норадын Туктамыш ханны үтерә. Идегәй һәм Норадын арасын мәкер-хыянәт белән бозалар, ата белән улны бер-берсенә каршы котырталар. Үзара орышта Норадын атасы Идегәйнең уң күзен чыгара һәм аны илдән куа. Әмма үзе дә мәкерле Җанбай тарафыннан Туктамышның улы Кадыйрбирде кулына әсирлеккә төшә. Идегәй кулындагы җиде илчесенә алмашка Кадыйрбирде Норадынны*

[48] *Тәзем кылу* – олылау
[49] *Чигара кылу* – чик кую.
[50] *Улҗа* – сугышта кулга төшкән мал, трофей.

*әтисенә бирергә ризалаша. Норадын әтисе янына килеп җитеп гафу үтенә һәм алган җәрәхәтләреннән үлә. Идегәйнең батырлыгын дошманнары танырга мәҗбүр булалар. Дастан Идегәйнең үлемен тасвирлап тәмамланса да, ул халык канын койган ханның бәхетле була алмаячагын әйтеп үлә. )*

Кадыйрбирде яшь солтан,
Гайрәте килеп, анда әйтте:
–Идегәй андый ир икән,
Идел-йортта бер икән,
Ирекле кеше ул булып,
Илне тоткан ир икән;
Идегәй илдә бер икән,
Ир сыртланы ир икән;
Бүре булып бараем,
Бурбаеннан[51] алаем!
Җавап бирде Идегәй:
– Кабагыннан кар явып,
Керпегенә боз туңып,
Эзләп килгән Кадыйр белән
Ярышырга көчем бар.
Аны да бел, Кадыйрау,
Арслан хәлдән тайса да,
Бер сарыклык көче бар!..
Анда әйтте Идегәй:
– Үлем белән куркытмаң,
Курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән,
Котыла торган буем юк.
Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы – белалмам!
Аңламаса халыгым
Аңламастан үлалмам!

Барсын бердәй аралап,
Аттан атын яралап,
Анда батыр Идегәй
Унике ирне үтерде.
Кан ярасы ачылып,
Идегәй хәле беткәндә,
Барын морза бер җитеп,
Идегәйне бер чапты.
Башы тәннән аерылып,
Тәгәри биреп аны әйтте:
–Барын[52], сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын[53]!
Йортың-караң калмасын!
Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Сөт урынына кан койдың,
Канымны түгеп ни кылдың?
Идегәй башы аны әйтеп,
Көнгә табан әйләнде,
Әйләнгәндә янә әйтте:
–Алдагы көн агырга[54]
Без барабыз, ул килмәс!..
Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган тагы
Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аҗдаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

**Сораулар һәм биремнәр.**

[51] *Бурбай* – тез асты.
[52] *Барын* – кеше исеме, тарихта мәгълүм нәселдән.
[53] *Берең ике булмау* – нәсел үрчүдән туктау.
[54] *Агыр* – хөрмәт.

1. Бүлектә сурәтләнгән вакыйгаларны искә төшерегез. Норадын әтисенә туган җир турында нәрсәләр сөйли?

2. Идегәй ни өчен туган җиренә – Идел-йортка кире кайтырга була?

3. Идегәй Идел-йортка нинди сүзләр белән мөрәҗәгать итә? “Йорт” сүзенә нинди мәгънә салынган? Бу өзекне ятлагыз. Әлеге өзек бүгенге көндә дә җыр буларак яши. Аны кем башкара? Бу җырны тыңлагыз.

4. Идегәйдә идарәчеләргә хас булган нинди сыйфатлар бар?

5. Әсәрдә сурәтләнгән чордагы гореф-гадәтләр белән бүгенге көндәгеләре арасында охшашлыклар бармы?

6. Дастанда әкиятләргә хас булган вакыйгалар очрадымы?

7. Алтын Урда таркалгач, нинди ханлыклар барлыкка килә?

8. Сез укыган башка әдәби әсәрләрдә Идегәй белән чагыштырырлык геройлар бармы?

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1. Бакиров М. Эпос- дастаннар / М.Бакиров // Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б. Б. – 47-89.

2. Урманче Ф. Халык эпосы- дастаннар / Ф.Урманче // Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2002.- Б. 182-216.

3. Әхмәтова Ф. Татар халык дастаннары // Татар халык иҗаты. Дастаннар.- Казан: Тат.кит. нәшр., 1984. – Б. 5- 28.

***Өстәмә әдәбият:***:

1. Надиров И. Идегәй дастанының поэтикасы. Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность: Труды международной конференции в трех томах, 9-13 июнь, 1992 г. Казань, том. 2 . Академия наук Татарстана. – Москва: Инсан, 1997. – С. 165-167.

2. Надиров И. Идегәй нең шигърият дөньясы. // Казан утлары. – 1997. - №5. –Б. - 163-167.

3. Урманче Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. — Казан, 1997.

4. Урманчеев Ф. Героический эпос татарского народа. — Казань, 1984.

5. Ибраһимова Л. Төрки халыклар иҗатында “Чура батыр” дастаны. – Казан: Фикер, 2002. – 192 б.

6. Латыйфи Ф. Бер ананың игез уллары без / Чура Батыр: татар халык дастаны. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – Б. -3-11.

7. Закирова И. Алпамыш дастаны, Түләк дастаны / Болгар чоры халык иҗаты.- Казан: Фикер, 2003. –Б. 55-98.

8. Фахрутдинова А.Р. Дастан Туляк и Сусылу: тюрко-татарские варианты: Автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата филологических наук.- Казань, 2007.

***Фольклор әсәрләре текстлары:***

1. Татар халык иҗаты. Дастаннар (кереш мәкалә авторы Ф.Урманче). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1989.
2. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.
3. Заманалар узган – дастан туган: Дастаннар (Төзүчесе Ф.Урманче).- Казан: Мәгариф, 2001.
4. Идегәй: татар халык дастаны. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1994.
5. Чура Батыр: татар халык дастаны. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. – 63 б.

**«Татар халык дастаннары» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. «Идегәй» дастанының безнең көннәргә килеп җитү тарихы.
2. «Идегәй» дастанында мифик персонажлар.
3. «Идегәй» дастындагы тарихи шәхесләр.
4. Татар фольклорында һәм әдәбиятында Идегәй образы.
5. «Чура-Батыр» дастанында ил батырлары җыелма образының чагылышы.

## ТЕМА № 5. ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларның берсе.

Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Чын мәгънәсендәге әкиятнең туу вакыты – ул нәкъ менә изге хикәянең (әкият «баба»сының) нәфис хикәягә әверелеп киткән чагы. Бу хәл исә изге хикәянең ритуалдан аерылуы нәтиҗәсендә була. Чөнки йоланы барлыкка китергән шартлар вакытлар узу белән бетә (аларның иң мөһиме – аучылыкның бердәнбер яки төп яшәү чыганагы булудан туктавы). Бу исә, үз чиратында, әүвәлге изге мәгънәдәге йоланың да бетүенә китерә. Йоладан аерылган хикәя шулай ук үзенең «изге»леген җуя һәм барлык

кешеләр өчен дә сөйләнелә башлый. Әкиятнең шушы рәвешчә мөстәкыйль жанр булып формалашып җитүе борынгы община строеның таркалу чорына туры килә. Менә шул чордан башлап, әкият гамәллилектән арына һәм беренче чиратта эстетик вазифа үти башлый. Әлбәттә, аның идея вазифасы да (әхлакый, социаль һ.б.) мөһим урын тота [Җамалетдинов, 1981].

«Әкият» дигән сүз гарәпчә хикәят сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. өлкән буын вәкилләре арасында әкиятне хикәят дип атаучылар әле бүген дә очрый.

Әкият – фольклорда катлаулы күренеш. Әкияткә билгеләмә түбәндәгечә: әкият – ул халык поэтик авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик, башлыча чәчмә сәнгать әсәре. Фәнни-тикшеренү максатларында әкиятләр күп халыкларда нигездә өч төргә бүлеп карала:

- хайваннар турындагы әкиятләр;
- тылсымлы әкиятләр;
- көнкүреш әкиятләре.

Әлбәттә, бу бүленештә шартлылык шактый зур. Чөнки тикшеренүчеләр әкиятләр арасында үзенчәлекле сыйфатларга ия булган байтак кына төркемнәрне аералар (мифик, легендар, тарихи, героик, маҗаралы, сатирик, юмористик, новеллистик, табышмак, көлдергеч, алдавыч һ.б.) һәм бу төркемнәрнең кайберләре әлеге өч төр кысаларына гына сыеп бетә алмый. Шулай да күзәтү характерындагы хезмәтләрдә һәм әкият җыентыкларының төзелешендә нигез итеп жанрның өч төргә бүленешен алу гадәткә кергән.

Татар халык әкиятләре составында хайваннар турындагы әкиятләр күп түгел. Язмалар саны буенча исәпләгәндә, алар чама белән әкият репертуарының нибары 5 процентын тәшкил итә. Бу әсәрләрнең күләмнәре дә зур түгел.

Халык арасында «Салам-Торхан», «Аю Бабай, Төлке», «Кәтән Иваныч», «Төлке», «Шәрә бүре», «Торна белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрендәге сюжетлар аеруча киң таралган.

Мондый әкиятләрнең төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре һәм җәнлекләре, кошлар, балыклар, бөҗәкләр. Хайваннар турындагы әкиятләр әкият жанрының гына түгел, бәлки гомумән фольклорның иң борынгы күренешләреннән санала.

Хайваннар турындагы әкиятләрнең оешу чорларын Л.Җамалетдинов өчкә бүлеп карый:

1. Борынгы кешеләрнең ау вакытларында хайваннар белән булган кызыклы вакыйгаларны теркәп калдырулары.

*2.* Антропоморфик күзаллау нигезендә барлыкка килгән легендалар һәм мифлар хайваннар турындагы әкиятләр генезисында икенче этапны тәшкил итә.

3. Өченче этап хайваннар хакындагы хикәяләрнең сүз сәнгате әсәрләре булып җитешүе, ягъни аларның вазифадан арынып, эстетик вазифа үти башлавы белән билгеләнә. Бу әсәрләр хайваннар турындагы ышанулар, көнкүреш хикәяләре, мифлар һәм легендаларның органик кушылмасыннан гыйбарәт. Бу этапта инде фантазиягә киң юл ачыла, һәм әкиятләр ирекле үсеш ала. Шулай итеп, эстетик һәм идея вазифаларын үти торган сәнгать әсәрләренең бик борынгы төрләреннән берсе – хайваннар турындагы әкиятләр барлыка килгән. Соңрак, җәмгыятьнең социаль-тарихи үсеше нәтиҗәсендә, бу әкиятләргә аллегорик сыйфат өстәлеп, кайберләре мәсәлгә дә әверелә.

Тылсымлы әкиятләрнең нигезендә могҗизалы уйдырма ята. Галим М.Бакиров фикеренчә, «ул ике төрле башлангычка –тылсым һәм фантастикага нигезләнә. Тылсым борынгыларның мифологик карашлары нигезендә барлыкка килгән төрле саклану чараларын һәм ниндидер теләк-максатка ирешүдә ярдәм итәргә исәп ителгән магик предметларны һәм сүз-догаларны, шулай ук магик гамәл-йолаларны да үз эченә ала» [Бакиров, 2008:119].Төрле серле предметлар: каурый, көзге, тарак һ.б. тылсым көченә ия әйберләр әкият героена батырлыклар кылырга һәм дошманны җиңәргә ярдәм итәләр.

Тылсымлы әкиятләрдәге фантастиканы М.Бакиров, мифологик ышанулардан үсеп чыккан дип саный. Тотем булган хайваннарның кешегә булышуы, мифик явыз көчләрнең әкият героена төрле авырлыклар китерүе кебек мотивлар элекке хыялый-фантастик күзаллауларны чагылдыралар, дип билгели [Бакиров, 2008:120].

Тылсымлы әкиятләрнең бер тармагы булган батырлар турындагы әкиятләрдә (мәсәлән, «Ак бүре», «Камыр батыр», «Турай батыр», «Таң батыр», «Алтын алма», «Өч дус», «Өч күгәрчен» әсәрләрендә) геройның икенче дөньяга – еш кына җир асты дөньясына сәяхәте һәм аннан кыз алып кайтуы – шаманның үлеләр дөньясына барып, авыру кеше җанын алып кайтуын гәүдәләндерә. Димәк, бу төр әкиятләрнең генезисында шаман легендаларының да сизелерлек роле булган дип әйтергә мөмкин. Тотемизм, инициация, шаманизм - болар барысы да дини күренешләр, дөресрәге − кабилә диннәренең формалары. Димәк, без бу урында әкиятнең дин белән бәйләнеше дә күренә.

Тылсымлы әкиятләргә хас интернациональ сыйфатларның берсе - вакыйганың күп мәртәбә (гадәттә өч мәртәбә) кабатлануы. Бу - әкият композициясенең үзенчәлекле законы, һәр кабатлауда каршылык арта, хәл катлаулана бара. Бу бигрәк тә геройның авыр бурычлар башкаруы вакытында ачык күренә.

Тормыш-көнкүреш әкиятләренең эчтәлеге, исеменнән үк күренгәнчә, тормыш-көнкүрешкә аеруча якын тора. Кагыйдә буларак, алар күләм ягыннан кыска булалар.

Бу төр әкиятләрнең күпчелегенең нигезендә аерым кешеләр яки гаилә әгъзалары арасындагы мораль-этик конфликт, яки иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле конфликт ята.

Көнкүреш әкиятләрен М.Бакиров түбәндәге төркемнәргә бүлеп карарга тәкъдим итә:

1. Гаилә-шәхси көнкүреш әкиятләре (юмористик әкиятләр).
2. Социаль көнкүреш әкиятләре (сатирик әкиятләр).
3. Гыйбрәтле әкиятләр.
4. Маҗаралы әкиятләр.

Бу төр әкиятләрнең поэтикасы аларның комик табигатенә бәйле. Аларда һәрвакыт ниндидер көлкеле ситуация туа, һәм еш кына вакыйгалар акылга сыймаслык чишелештә тасвирлана. Геройлар да, вакыйгалар да гадәттән тыш күпертелеп сурәтләнә. Төрле образлар капма-каршы куела. Еш кына бу төр әкиятләрнең исемендә үк антоним төшенчәләр күзәтелә.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

**Тема. Халык әкиятләренең поэтикасы. Образлар системасы.**

1. Жанрга билгеләмә бирергә. Жанрның төп үзенчәлекләре һәм төрләрен санарга. Әкиятләрдә уйдырма-фантазиянең роле. Әкиятләрдә вакыт һәм урын гәүдәләнеше. Халык әкиятләренең тематик төркемчәләре.
2. Хайваннар турындагы әкиятләрнең поэтикасы, стиле. Хайваннар турында әкиятләрдәге популяр персонажлар: Төлке, Бүре, Кәҗә белән сарык, Әтәч.
3. Тылсымлы әкиятләрдә традиционлык. Тылсымлы әкиятләрдәге образлар системасы. Җир кешеләренең мифологик персонажларга каршы куелуы. Баш каһарманнарның берсе буларак – кече ул. Тылсымлы әкиятләрнең композициясе. Традицион башлам. Төп өлештә вакыйгаларның берничә мәртәбә кабатлануы. Бетем. Текстлардагы тылсым көченә ия предметлар, детальләр. Әкиятләрдәге эпик формулалар. Тылсымлы экияләрдә сюжетның катлаулылыгы, әмма бер генә сызык буенча баруы. Батырлар турындагы тылсымлы әкиятләрдә дастаннарның киң чагылышы.
4. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендәге персонажлар. Бу төр әкиятләрнең мәзәкләргә якынлыгы. («Тапкыр кыз», «Бай һәм ярлы», «Абага чәчәге», «Чибәр Хәдичә», «Саран белән юмарт»,«Зирәк карт», «Байдек, Шамак карак»). Тормыш-көнкүреш әкиятләренең шартлы төркемнәргә бүленүе: гыйбрәтле, маҗаралы, сатирик, юмористик. Тормыш-көнкүреш әкиятләренең сәнгати формасы.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1. Бакиров М. Әкиятләр // М. Бакиров Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008.- 359 б.- Б. 116-135.
2. Урманче Ф. Әкиятләр // Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 81-107.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Гатина Х. Вакытында табылган якутлар: Әкиятләр, истәлекләр, хатлар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.
2. Җамалетдинов Л. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан, 1984. – Б. 17-36.
3. Җамалетдинов Л. Әкиятләрнең кайбер поэтик үзенчәлекләре // Фольклор теле- шигърият теле. Казан: Фикер, 2001. – Б. 45- 66.
4. Җамалетдинов Л. Көнкүреш әкиятләре // Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 3 китап. Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. – Б. 5-18.
5. Җамалетдинов Л. Тукай һәм әдәби әкият // Казан утлары. – 1979. - № 4. – Б. 160-164.
6. Җамалетдинов Л. Тылсымлы әкиятләр // Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 2 китап. Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – Б. 5- 22.
7. Касыймов Э. Татар халык әкиятләрен җыю һәм бастырып чыгару тарихыннан // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: 1963. – 2 китап.- Б. 246-263.
8. Касыймов Э. Татар халык әкиятләрендә сатирик типиклаштыру // Совет әдәбияты, 1963. - №9. – Б. 144-150.
9. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1967.
10. Ярми Х., Җамалетдинов Л. Татар халык әкиятләре. Жанрның төрләре һәм аны өйрәнү тарихы / Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап. Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. - Б. 7-26.

***Фольклор әсәрләре текстлары:***

1. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап (кереш мәкалә авторлары Х.Ярми, Л.Җамалетдинов). Казан: Тат. кит. нәшр., 1977.
2. Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 2 китап (кереш мәкалә авторы Л.Җамалетдинов). Казан: Тат. кит. нәшр., 1978.
3. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 3 нче китап (төзүчесе һәм кереш мәкалә авторы Л.Җамалетдинов) Казан: Тат. кит. нәшр., 1981.
4. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.

## Укып анализлау өчен әкият текстлары:
## I вариант
## Ак бүре

Борынгы заманда бар иде бер патша. Аның дүрт улы бар иде. Бер заман патша, хатыны белән икәү, яхшы атлар, яхшы арбалар җигеп, ялан-япан сахрага чыктылар. Сахрада яткан вакытларында, төннең бер мизгелләрендә, боларның чатырларын бик каты җил исеп күтәреп ташлады. Шул ук вакыт һавадан бер дию патшасы пәйда булып, моның куенындагы хатынын күтәреп алып китте. Шул сәгать патша уянып, куенындагы хатынының юклыгын белеп, тиз генә кучерын уятып, икәүләп эзләргә киттеләр. Болар шул төнне эзләп, хатынны таба алмыйча, таң аткач үзенең шәһәренә кайттылар. Патша ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, төрле якка эзләүчеләр җибәреп хатынны эзләргә тотынды.

Хатынның югалганына тәмам бер ел булган вакытта, патшаның өлкән улы укудан, укуын бетереп, атасы янына кайтты һәм атасына әйтте:

– Инде, әти, мин укуның чигенә чыктым. Син инде миңа әнине эзләргә бер ел рөхсәт бир, – ди.

Атасы моңардан сорады:

– Рөхсәт иттем, сиңа ниләр бирим? – дип.

Атасыннан үзенә юлдашка бер йөз солдат алып, бер елга җитәрлек акча, азык-төлек алып, анасын эзләргә чыгып китте. Киткәннән киттеләр. Ай китеп, ел китеп, әйләнгән җирдә әйләнмә үсеп, тулганган җирдә кызыл тубылгылар үсеп, ташка тары үскәндә, бозга бодай үскәндә, аны шатыр-шотыр урып ятканда, болар барып җиттеләр бик куе бер урманның эченә. Шул урманның эче белән, беләк буе трубканың куышы белән барып яткан вакытта килеп җиттеләр бер суның буена – сахралык җиргә.

Шунда патшаның улы уйлады: Без шунда берәр көн ял итеп, атларыбызны ашатып китәрбез, – диде. Иптәшләре, атларыннан төшеп, куышларын корып, шул ук сәгать су эзләргә киттеләр. Суны алып килеп, ашларын пешереп, ашап утырган чакта, патша улының чатырына бер Ак бүре килеп сәлам бирде һәм әйтте:

– Әй, ахмаклар, кем рөхсәте белән минем урманыма кереп, үләннәрне таптап йөрисез? Рөхсәт юк, хәзер чыгып китегез, – диде.

Патша улы:

– Син үзең кайдан килдең, шунда кит. Минә минем йөз солдатым бар, хәзер аттырырмын да үтерермен, – диде.

Бу сүзләргә Ак бүренең ачуы килеп, һаман да боларга моннан чыгарга кушты һәм куды. Куган саен чыкмагач, Ак бүренең ачуы килеп боларга карап бер дога укып өргән иде, бар да торатащ булып каттылар.

Инде без килик патшаның үзенә. Биш айдан бирле улыннан хәбәр көтте. Алты ай көтте – улыннан һичбер хәбәр-хәтер юк. Бер елдан соң укый торган ике уртанчы улы укудан кайттылар. Исәнлек-саулык

сорашканнан соң, болар да аталарыннан рөхсәт сорадылар:

– Без дә әнине эзләргә чыгыйк, – диделәр. Патша боларга таба карап:

– Олы абзагызның киткәненә инде бер ел булды, һичбер хәбәр-хәтере юк. Инде мин, сездән аерылып, берүзем нишләрмен? – диде.

Болар аталарының ай-ваена карамыйча, һәркөнне рөхсәт сорыйлар иде. Бер дә беркөнне боларның аталары, бик күп сорый торгач, боларга да бер елга рөхсәт бирде.

– Ләкин бер елдан артык йөрергә рөхсәт юк, – диде. Һәм болар да, аталарыннан йөзәр атлы солдат алып, бер елга акча, азык-төлекләр алып, агай-эне, аталары белән саубуллашып, ике йөз дә ике кеше булып, юлга чыгып киттеләр; иртә киттеләр, кич киттеләр, арт итәкләре җирдән китте, төкерекләре билдән китте, ат өстенә ятып, агач мылтыклар атып, муеннары аладай булган чакта, битләре тургайдай булган чакта барып җиттеләр баягы урманның бер як читенә.

Боларга да бик яхшы су, үләнлек очрап, ял итәргә туктадылар. Нәм атларыннан төшеп, чатырларын корып, су эзләп алып килеп, аш пешереп ашарга утырган чакта, баягы Ак бүре килеп җитеп, баягыча:

– Кем рөхсәте белән килеп, бу чаклы солдат, атлар белән урмандагы үләннәрне таптап килеп кердегез? – диде. – Һич рөхсәт юк, – дип боларны да куа башлады.

Бу патшаның улы ике йөз атлы гаскәренә таянып, Бүредән алайрак ачуланып:

– Син үзең кайдан килдең, шунда кит, – диде.

Боларга яхшылык белән берничә әйткәннән соң, тыңламагач, Ак бүре баягыча бер әфсен укып өргән иде, болар да тораташ булып каттылар.

Инде без тагын патшаның үзенә килик. Иң өлкән улына ике ел, уртанчыларына бер ел булган чакта, төпчек улы мәдрәсәдән укудан кайтты. Кайтып керүгә, атасыннан исәнлек-саулык һәм абыйларын сорашып, хәбәр-хәтердән соң патша моңарга:

– Менә иң өлкән абыеңның китүенә ике ел, уртанчыларына бер ел булды, һичбер хәбәр-хәтерләре юк, – диде.

Моны ишеткәч, төпчек улы:

– Инде алар кайтмады, берәр хәл булгандыр. Миңа да рөхсәт бир дә, мин дә китим, – диде.

Патша:

– Мин синнән дә аерылгач, кемгә карап торырмын, югалганнар югала торсын, әмма сиңа һич рөхсәтем юк, – диде.

Бу атасына көн-төн ирек бирмичә сорый торгач, атасы моңа да рөхсәт бирсә дә бирде, бирмәсә дә бирде. Атасы моңа рөхсәт бирмәскә теләгәч, ул:

– Әти, мин сине гаскәр сорап, азык сорап борчымыйм бит, миңа бары бер елга, каябарсам да җитәрлек итеп, акча гына бир, – диде.

Моңа каршы атасы җитәрлек акча бирде.

Бер бик яхшы атка яхшы ияр салып, аллага тапшырып, юлга чыгып китте. Шул көннән соң, күп айлар, күп көннәр, сәгатьләр, күп минутлар киткәннән соң, әлеге абзалары яткан урманның читенә бу да ялгызы барып җитте. Бу да урманны үтәргә теләп бара торгач, юл буенда бер бик һәйбәт аланга очрады. Һәм: Бик күп көннәрдән бирле мин атымны ял иттергәнем юк, тукта, монда бераз туктап ашатыйм, – дип, атыннан төшеп, бер зур тирәкнең ботагына атның башын югары күтәреп бәйләп куйды. Муенындагы мылтыгын корып, үзенә ашарга берәр кош атып килә алмаммы икән дип, урманның эченә кереп китте. Бер ун адым гына киткән иде, баягы Ак бүре килеп очрады һәм әйтте:

– И егет, син монда нишләп йөрисең, кая барасың, кайдан килдең? Монда минем рөхсәтемнән башка үләннәрне таптау җитмәгән, тагы урмандагы кошларны атарга барасың, – диде.

Егет бүрегә:

– Әнә ул күренә торган кошны атып алып, үземә пешереп ашарга уйлаган идем. Бик арыдым, талдым. Бик ерак җирдән килдем. Инде алай булгач, синең рөхсәтеңнән башка мин монда бер эш тә эшләмим, кошыңны да атмыйм, атымны да ашатмыйм. Әнә күрәсең, атымның башын югары күтәреп бәйләп куйдым. Чыгам да китәм, – диде.

Бүре аңа каршы:

– Инде, егет, мин сине күрәм, үзең күркәм, сүзең ямьле, һичбер каршы килгән җирең юк. Алай булгач, мин сиңа урманымда йөрергә, атыңны ашатырга, кошларымны атарга рөхсәт иттем. Теләгәнеңне эшлә. Тик менә бу күренгән кошны атма. Әнә теге зур тирәкнең артында бер кош бар, тирәкнең башында утыра. Бар да шуның күкрәгенә төзәп ат. Бер атуда егылыр да төшәр. Аннан соң алып кайт та тазартып пешер. Аш ашарга мин дә килермен, – дип әйтте дә үз юлына китте.

Егет бүренең сүзен тыңлап, тирәккә якын барып, кошны күреп, күкрәгенә төзәп мылтыгының чакмасын сугып җибәргән иде, кошның нәкъ күкрәгенә барып тиде дә әйләнеп төште. Соңра егет, аты янына алып кайтып, арчып куйды. Үзенең чатырын корып, аш хәзерләп, атын үләнгә җибәреп, әлеге Ак бүрене көтеп калды. Моның чатыры янына искәрмәстән генә бер яктан бер яшь кенә егет килеп чыкты да моңа сәлам бирде. Егет тә, якты чырай белән каршы алып, хәзер булган ашны куеп, чатырга моны да ашарга чакырды. Кунак егет тә, сүзне тыңлап, чатырга кереп утырып, ашый башладылар. Карыннары бик ач булганга күрә, хәзерләнгән ашны тәмам ашап бетерә яздылар. Шул чакта келт итеп патша улының исенә Ак бүре төште һәм: Аңа куярга инде ашым азайды; бетеп үк бара, килә калса, ни куярмын, – дип йөрәгенә курку төште.

Кунак егет моның уйлаганын күреп:

– И дустым, яхшы гына, күңелле генә утырган чакта, әллә ни күңелсезләнеп киттең. Нәрсә уйлыйсың, ник эчең поша? – дип сорагач, егет кош атуын, Ак бүренең очраганын, аның белән бергә ашарга вәгъдә

куюларын – барын да аермачык иттереп баштанаяк сөйләп бирде:

– Хәзер шул Ак бүре килсә, ни ашатырмын икән дип уйлый башладым, – диде.

Кунак егет аңа каршы:

– Әй, егет, син аның өчен бер дә кайгырма. Ул бүре булып күренгән нәрсә мин идем. Минем җитмеш төрле һөнәрем бар, җитмеш төрле сурәткә керә алам, – диде.

Шуннан соң егетнең кайгысы бетеп, башка нәрсәләр сөйләргә тотынып, үзенең кая, ни өчен юлга чыгуын, анасының югалуын, агаларының аны эзләргә китеп тә юлда югалып калуларын – барын да баштанаяк сөйләп бирде.

Аңа каршы Ак бүре:

– Йә, егет, син ул агаларыңны хәзерге көндә исән-сау дип уйлыйсыңмы? – – диде.

Егет аңа каршы:

– Мин, әлбәттә, аларны исәннәр дип уйлыйм. Чөнки алар бер бозык юлга, яман уй белән киткән кешеләр түгел, өч агам өчесе дә йөзәр атлы солдат белән һәм акча, азык белән чыгып киткәннәр, – диде.

Ак бүре моңа каршы:

– Соң син ул агаларыңны күрсәң таныр идеңме? Әйдә әле монда, мин сине бер җиргә алып барыйм, – дип, иң олы агасының торараташ булып каткан җиренә алып китте. Алып барып, өстенә күкле-яшелле мүк үсеп беткән таш янына китереп:

– Менә бу нәрсә, син таныйсыңмы? – дип күрсәтте. – Алай булгач, син белмәсәң; мин әйтим: менә бусы синең өлкән агаң, әнә ул янында яткан ташлар аның батыр солдатлары. Алар минем сүземә каршы килделәр дә, мин аларны менә бу сурәткә керттем, – диде.

Егет, бу ташларның агасы һәм гаскәрләре икәнен белгәч, күңеле нечкәреп елап җибәрде. Ак бүредән аларны яңадан әүвәлге кыяфәтләренә кайтаруын сорап ялына башлады.

Ак бүре егеткә:

– Ярый, мин синең сүзеңне тыңлап, аларны әүвәлге кыяфәтләренә кайтарам. Мәгәр синең бу агаң һәм гаскәрләре синең эшкә вә сиңа юлдаш булырга ярый торган кешеләр түгел. Терелгәч тә син аларны тиз генә шәһәрегезгә кайтарып җибәр, – диде.

Шуннан соң Ак бүре, тискәре якка карап, озын бер дога укып, ташларның өсләренә өргән иде, бар да сикереп торып, үзләренең иске кыяфәтләренә кереп, кайсы мылтыгын тота, кайсы атын иярли, кайсы тәмәке төрергә башладылар. Боларны күреп патша улы:

– И егетләр, тизрәк булыгыз. Без бик озак йоклаган икәнбез. Тизрәк үз юлыбызга китик, – дип кычкырган иде, бу ике егет килеп, сәлам биреп, бик һәйбәтләп күрештеләр.

Патшаның өлкән улы, әлбәттә, моны танымады. Энесе, агасына

үзенең кем булганын сөйләп:

– И агай, мин синең иң кечкенә энең булам. Сез мин укыган чакта әнине эзләргә дип киткәнсез һәм ничә еллардан бирле әти сезне көтсә дә, сезнең һичбер хәбәр булмагач, елый-елый күзсез калды. Инде мин дә сезнең арттан, әтидән рөхсәт сорап, әнине эзләргә дип чыктым. Бу урманга килеп, Ак бүрегә очрадым. Сез, аңарга карышып, үзегезне үзегез һәлак иткәнсез. Әмма мин, аның белән дуслашып, сорашып, сезнең монда икәнлегегезне белдем һәм аңардан сезне әүвәлге сурәтегезгә кайтаруын үтендем. Ул да, мине кызганып, сезне аякка торгызды. Инде сез сау-сәламәт көенчә кире өйгә кайтып китегез, – диде.

Бу сүзләрне ишетеп, агасы үз гаскәрләре белән бергә шәһәренә кайтып китте.

Соңра уртанчы агалары янына барып, ал арны да әүвәлге сурәтләренә кайтаруын Ак бүредән үтенде. Ак бүре тыңласа да, болардан һичберсен үзенә юлдаш итеп алырга ярамаганлыгын белдерде:

– Бик кирәк булса, үзең теләсәң, бары үзеңнән бер яшь зур агаңны гына алып калырсың. Башкалары синең эшкә ярамаслар, алар кайтып китсеннәр, – диде.

Баягы кебек бүре бер дога укып, боларны да тергезде һәм болары да, агасы кебек саубуллашып, шәһәрләренә кайтып киттеләр. Әмма егет үзеннән бер генә яшькә олы агасын үзенә юлдаш итеп алып калды.

Соңра бу егет, агасы һәм Ак бүре белән өчәүләп, чатырларына кайтып киттеләр. Чатырга кайтканнан соң бу егет Ак бүрегә:

– Йә инде, Ак бүре, мин юл кешесе, юл кешесенең юлда булуы яхшы. Син мине тотма. Урманыңнан чыгып китәргә рөхсәт бир, – диде.

Ак бүре аңарга каршы:

– Ярый, мин сезгә рөхсәт бирәм. Мәгәр мин сезне, бу урманнан чыгып киткәнче, үзем озатып җибәрим. Алайса бу урманда бик зур ерткыч җанварлар бар, алар сезгә зарар китерерләр дип куркам, – диде.

Соңра чатырларын бозып, атларына атланып, үз юлларына өчәүләп йөри бирделәр. Юлда барганда, Ак бүре егеткә:

– Йә, егет, син озак юл кешесе, мин белгәнем кадәр юлларыңны өйрәтим, бәлки минем әйткәннәрем сиңа файда булып төшәр. Менә бу минем урманым. Шул җирдән өч көн, өч төнлек юл. Шул минем урманымнан чыгып, өч көн, өч төн киткәннән соң, дию патшасының җиренә барып чыгарсыз. Ул дию җиреннән өч көн, өч төн барганнан соң, бер алтмыш колач юанлыгы алтын тирәккә очрарсыз. Ул алтын тирәкнең астында бер кечкенә генә күл булыр. Ул күлгә җиткәч, аның янына бер землянка казып, абзаңны шул землянкада калдырырсың. Үзең тирәкнең бер ягына бер баз казып, үзеңне үзең күмәрсең, тик ике күзең генә калсын. Берничә сәгатьләр үткәннән соң, бу күлгә бер көтү елкылар килеп су эчәрләр. Алар менеп киткәч, бер сәгатьләрдән соң, күк күкрәтеп, җир дөбердәтеп, өермәләр өереп, алтмыш чакрымнан аяк тавышлары ишетелеп,

бер алтмыш колачлы ала айгыр килер дә алтмыш колачлы алтын тирәкнең бер ягына ялын ышкый башлар. Ышкып арганнан соң, бик сусап, әлеге күлнең суын бөтенләй эчеп бетерер дә әлеге агачка килеп, икенче як ялын ышкырга тотыныр. Шул вакытта, күлдә су беткәнлектән, күлнең төбендә булган балыклар барысы да җыелышып калырлар, агаң шуларны үзенең базына ташып куйсын. Алар ашарга азык булыр. Айгыр озак ышкына торгач, әлеге алтмыш колачлы алтын тирәкне сындырыр. Аның шатыр-шотыр сынган тавышына син базыңнан сикереп чык та бик тизлек белән әлеге алтмыш колачлы ала айгырга атланырга тырыш. Атлана алмасаң, ялына ябышырга, ялына ябыша алмасаң, койрыгына ябышырга тырыш. Әгәр дә син аңарга эләгә алсаң, бәлки анаңны таба алырсың. Инде бер аңарга эләксәң, ул утка керсә – утка кер, суга керсә – суга кер, ябышкан җиреңнән кулыңны ычкындыра күрмә. Әгәр дә ычкындырсаң, шул вакыт һәлак булырсың. Шушы михнәтләргә түзә алсаң, анаңны табарсың, чыдамасаң анаңны таба алмассың, – диде.

Егет:

– Инде мин, ни күрсәм дә чыдарга, анамның юлында корбан булырга җиттем, һәммәсенә түзәчәкмен, – диде.

Ак бүре аңа каршы:

– Ярый, егет, мин синең анаңны табуыңа да ышанамын. Анаңны табып, шәһәрегезгә кире кайтканда, минем яныма керми китә күрмә. Урманымның теләсә кай җирендә туктап, атыңны ял иттереп, үзең теләсә ни аша. Әмма миндә кунак булмыйча китәргә һичбер рөхсәтем юк. Инде бер килеп урманыма төшкәч, кайда туктасаң да, мин сине үзем табармын, – диде.

Егет, Ак бүре белән исәнләшеп, аның урманыннан чыгып китте.

Бүре әйткәнчә өч көн, өч төн барганнан соң, дию патшасының җиренә килеп кереп, әлеге әйтелгән алтын тирәкнең янына барып җиттеләр. Икәүләп, тиз генә күл буена берәр баз казып җир өстендә күзләрен генә елтыратып калдырып, үзләрен күмеп куйдылар. Азмы-күпме ятканнан соң, бер көтү елкы килеп, бүре әйткәнчә су эчеп үлән ашарга менеп киттеләр. Бер сәгать үткәннән соң, зил-зилә куптарып, күкне күккә очырып, җирне җиргә орып, өермәләр өрдереп, алтмыш колачлы ала айгыр алтын тирәкнең төбенә килеп, ялын ышкып, су эчәргә төшеп, күлдәге бар суны эчеп бетереп янәдән икенче як ялын ышкырга тотынды. Шул заманда, бик каты ышкуга чыдый алмыйча, алтмыш колачлы алтын тирәк шартлап төбеннән сынды. Тиз заман егет, үзен-үзе баздан атып ташлап, ала айгырның ялына ябышты. Бик биек булганлыктан, өстенә менеп утыра алмады. Шул ук заман айгыр, ялына адәм заты ябышканын белеп, җилтерәтеп, бер җиргә, бер күккә, бер ташка орып алып китеп, җиттеләр ут тавына. Ала айгыр ут тавының янына туктап, егеткә:

– И егет, инде син миннән кулыңны ычкындыр. Мин хәзер бу ут тавының аргы ягына чыгачакмын. Аның аркылы чыккан вакытта синең

һәммә җиреӊ көеп, янып бетәр, – диде.

Егет аӊа каршы:

– И айгыр, мин янган-көйгән җирдә син дә исән калмассыӊ. Синнән кулымны ычкындырмыйм, – дип, кулын ычкындырмады.

Ала айгыр шул сәгать егетне өстерәп утка алып кереп китте. Ут эчендә егетне өч сәгатьләп бутап йөрткәннән соӊ, аргы ягына барып чыктылар. Егетнеӊ тәннәре пеште, куырылды һәм бик әрнеде. Соӊра егет артына әйләнеп караса, әлеге ут тавы беткән, бернәрсә дә калмаган. Егет үз-үзенә: Бу атныӊ сөйләгәне дөрес түгел икән, бу бер шәһәр генә икән, – дип, курыкмыйча, атныӊ ялына тагын да катырак ябышып алды. Алтмыш колачлы ала айгыр егеткә янә:

– И егет, инде кулыӊны миннән ычкындыр, – диде. Шулай итеп низаглашып, болар бер диӊгезгә барып җиттеләр.

Ала айгыр:

– Инде, егет, кулыӊны ычкындыр, син ут тавыннан котылсаӊ да бу диӊгездән котыла алмассыӊ. Авызыӊа-борыныӊа су тулып, шунда гарык булырсыӊ, мин аныӊ аръягына чыгачакмын, – диде.

Егет:

– Инде минем синнән аерыласым юк. Син кая барсаӊ, мин дә шунда барырмын. Минем авызыма, борыныма су тулганда, синекенә дә тулар. Үлсәк, бергә үләрбез, – диде.

Ат, ачуланып китеп, егетне диӊгезгә алып кереп китте.

Өч көн, өч төн йөзгәннән соӊ, диӊгезнеӊ аръягына чыктылар. Чыккан вакытта ат егетне үлсен дип, башын суга тигезеп, болгап чыгарды. Ләкин егеткә һичбер зарар килмәде.

Бераз коры җир белән барганнан соӊ, бер бик куе урманга җиттеләр. Бу урман аша чыпчык үтәрлек тә юл юк иде.

Алтмыш колачлы ала айгыр егеткә:

– Әнә күрәсеӊ, нинди кара урман. Мин шул урманны ватып-җимереп аръягына чыгачакмын, инде син, исән вакытыӊда, миннән кулыӊны җибәр. Син аннан чыкканчы җибәрмәсәӊ, бары ялыма ябышып кулларыӊ гына калыр. Башка һичбер җиреӊ калмас, – диде.

Егет:

– Ычкындырасым юк, үлсәм үләрмен, һич ычкындырмыйм, мин ботарланган җирдә син дә коры калмассыӊ, – дигәч, ала айгыр, ачуы килеп, егетне урманга алып кереп китте. Урманныӊ куе агачлы бер җирендә егетне арлы-бирле агачларга сугып харап итмәкче булды. Әмма егеткә һичбер зарар килмәде.

Өч көн, өч төн үткәннән соӊ, меӊ мәшәкать белән, болар урманныӊ аргы ягына барып чыктылар. Азмы-күпме киткәннәр иде, бер бик биек тау-таш араларына килеп җиттеләр.

Ала айгыр:

– Йә инде, хәзер кулыӊны миннән ычкындыр, шул җирдә кал, – диде.

Әмма егет:

– Үлсәм үләрмен, һичбер ычкындырасым юк, – дигәч, ала айгыр ачуланып, моны бер тауга, бер ташка орып, өч көн, өч төн үткәчтән, бер ялан җиргә барып чыктылар. Ала айгыр:

– Инде, егет, син хәзер күп нәрсәләр күрдең. Бу сулар, утлар, таулар бар да дию патшалыгыннан адәм үтмәсен өчен эшләнгән эшләр иде. Инде афәттән котылдың, өстемә менеп утыр да, мин сине бара торган җиремә кадәр алып барыйм, – диде.

Шуннан соң ала айгыр, егетне атландырып, өч көн, өч төн барганнан соң, егеткә таба карап:

– И минем дустым, юлдашым, инде мин өстемнән бурычымны төшердем. Миңа моннан ары барырга рөхсәт юк. Син инде минем өстемнән төш тә бу ком тавының аръягына чыгарга тырыш. Ул ком тавының аръягында яман диюләр, усал арысланнар, аждаһалар яталар. Алар янына чыга алсаң, анаңны табарсың, – диде.

Егет моңарга күп рәхмәтләр укып, өстеннән төшеп, тау итәгендә калды. Алтмыш колачлы айгыр үз юлына китте.

Бу егет, шул сәгать азрак тамагын туйдырып, тауның өстенә чыгарга теләп тауга менә башлады. Бераз менгән иде, ком ишелеп янә түбән төште. Никадәр менәргә тырышса да, ком ишелеп, һичбер менә алмады. Бик арып-талып, күңеле тулып, анасы исенә тентеп, елап аптырап утырганда, һавадан бер кара болыт кисәге төшеп килгәнен күрде дә куркып китте. Карап торды, болыт һаман төшә дә төшә. Төшеп җитә башлагач, егет күрде – бер кош, пырылдап әйләнеп, моның янына килеп төште дә:

– И егет, әйдә минем өстемә менеп утыр. Мин сине бер җиргә алып китим, – диде.

Егет утырырга да, утырмаска да белмәде. Утырсаң да һәлак итәр, утырмасаң да һәлак итәр, – дип шикләнеп, аллага тапшырып, менеп утырган иде, шул сәгать бу кош күз күреме һавага алып менеп китте. Егет һавага менгәннән соң курка башлагач, кош:

– И егет, син куркасыңмы? – дип сорады.

– Мин куркам, – диде. Кош моңа:

– И дустым, син мин барында курыкма. Син үзеңнең егетлегең аркасында әллә нинди куркынычлардан котылдың. Инде мин сине: Ала айгыр белән бу ком тавына кадәр килгәндер дә, анда менә алмый торгандыр, – дип кызганып, сәмруг кош сурәтенә кереп килдем. Мин – күптәнге дустың Ак бүре. Мин сине хәзер Каф тавының башына илтеп куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк. Үзең ничек булса да чыгарсың да анаңны табарсың, – диде. Шулай итеп, сәмруг кош егетне Каф тавы башына китерде дә: Инде миңа монда озак торырга ярамый. Тизрәк үз юлыма китим. Сау бул, Алла ак юл бирсен, – дип, саубуллашып, үз юлына очып кире китте.

Егет тау башында бик күп ат, адәм сөякләре күреп хәйран-вәйран

булып торганнан соң, ике кулына ике ат сөяге алып, таяк итеп таянып, тауның бер ягына таба төшеп китте. Өч ай дигәндә тауның аргы ягына төшеп җитте. Бераз бара башлагач, бер көтү арыслан чыгып, бу егеткә ыргылдылар. Тәмам ашарга дигәндә генә, араларыннан берсе чыгып, боларга: Ашамагыз! – дигән кебек итеп, барын да егеттән куып җибәрде.

Шулай итеп, бу бәладән азмы-күпме котылып ятканда, янә бер кечкенәрәк кенә тауга очрады. Тауның башына менеп караса, еракта бер ялтыраган нәрсә күреп: Бу нәрсә икән? – дип, шул ялтыраган нәрсәгә карап китте. Ялтыраган нәрсәнең янына килеп җитсә, дөнья зурлыгында эшләнгән бер бакыр сарай булып чыкты. Бакыр сарайның бер тәрәзәсеннән караса, ни күрсен: кырык бер кол кыз озын өстәлгә салып адәм итләре юып яталар иде. Бу егет шуларны күреп, күңеле нечкәреп, куркып: Минем итемне дә шул кызлар бу өстәлгә салып юарлар, мин дә бу җирдә харап булырмын, – дип кычкырып елап җибәрде. Елый торгач: Елауда файда булмас, – дип, егет гайрәткә килеп, батырланып ишек янына килеп сәлам бирде.

Шул минутта бер бик сылу, матур, кызыл битле, кара кашлы бер кыз ишекне ачып, егетнең сәламен алды:

– И егет, син адәми затмы, пәри затмы? – диде. Егет аңа каршы:

– Адәми затмын, – диде. Кыз егеткә:

– Ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җиргә син адәми зат булып ничек килеп җиттең? – диде.

Егет аңа каршы:

– Минем күп заманнардан бирле ашаганым юк, бик ачмын, мине сарайга алып кереп, бераз ашарга бир, тамагым туйдыр, – диде.

Кыз моңа каршы:

– Алай булса, син бераз туктап тор. Минем абыстам адәми заттан – диюнең хатыны. Мин аңардан рөхсәт сорап чыгыйм. Ул ни әйтсә – мин шуны эшләрмен, – дип кереп китте. Һәм абыстасына барып: И җаным-солтаным, ишек төбенә бер адәми зат килгән. Кертеп бераз ашатыгыз, дип ялынадыр. Кертергә рөхсәт итәсезме? – дип сорады.

Абыстай:

– Адәми зат булса, керт, ашат, рөхсәт, – диде.

Кыз моны ишеткәч, ишеккә барып, егетне кертеп, абыстай янына алып килде. Егет сәлам биреп, абыстай белән күреште. Шуннан соң абыстай, бер урынга утырып, кызга ашарга китерергә кушты. Кыз шул заман төрле кош итләре куырып китереп егетне сый-хөрмәт итте. Егет ашаганнан соң, абыстай, аның янына килеп:

– И егет, син кайдагы кеше буласың, нинди җирдән? – дип сорады.

Егет әйтә:

– Мин фәлән җирнең патша улымын. Мин укуда вакытта анам югалган иде, мин, атамнан рөхсәт алып, анамны эзләргә дип чыгып китеп, бу җиргә килеп җиттем. Инде моннан соң кая барасымны үзем дә белмим,

– диде.

Абыстай аңа каршы:

– Инде, егет, ерак җирләрдән үк михнәтләр күреп килгән икәнсең. Әгәр дә анаңны табып кайта алсаң, минем сараема кереп кунак булмый китмә. Бу сарайның иясе җиде башлы дию тугыз айлык юлга китте. Әгәр дә тиз көннән кайта калсаң, һич курыкма, минем сараема сугылмый китмә, – диде.

Егет тә керергә вәгъдә кылды. Абыстай янә:

– Мин синең коры сүзеңә ышанмыйм. Син анаңны тапкан шатлыгыннан мине онытырсың. Син онытмасаң шуны онытмассың – менә мин сиңа шул үзеңә ишек ачкан кызны никахлап бирим дә, ул монда калсын. Син дә аны исеңә төшереп, минем яныма керерсең, – диде.

Егет, шуңа риза булып, агасы исенә килеп төште дә:

– Мин монда рәхәттә ятам, минем агамның ашый торган ризыгы бетеп, аптырап ята торгандыр. Инде мин бара торган җиремә барып җитим, – дип, абыстайдан рөхсәт сорап, юлга азыклар алып, бикәче белән саубуллашып, юлга чыгып китте.

Бу бакыр сарай буйлап өч көн, өч төн барганнан соң, бер көмеш сарайга килеп чыкты. Көмеш сарайның тәрәзәсеннән караган иде: баягы кебек, кырык бер кол кызларның өстәлләргә салып адәм итләре юып торганнарын күрде. Минем дә итләремне шул өстәлләр өстенә салып, шул кызлар юарлар микән? – дип куркып китте.

Янә гайрәткә килеп, ишеккә барып сәлам бирде. Баягыдан да матур бер кыз чыгып, моның сәламен алып:

– Адәми затмы син, пәри затмы син? – дип сорады.

– И кардәш, адәми затмын. Бик күптәннән бирле юлда йөреп, ачыгып киттем. Кертеп бераз ашатсана, – диде.

Кыз моңа каршы:

– Минем өлкән абыстам бар. Аңардан кереп сорыйм, – дип кереп китте. Кәм абыстасына барып: Юлдан арып бер адәми зат килгән, кертеп бераз ашатырга сорыйдыр, – диде. Кыз да, абыстасының сүзен тыңлап, егетне кертеп, баягы кебек хәл-әхвәл сорашып, егет боларга анасын эзләргә чыкканын, патша баласы икәнен сөйләгәч:

– Бик яхшы, – дип сыйлап, – кайтканда курыкмый-ни-ми минем сараема кер, керми китмә, – диде. Абыстай: Син болай гына онытырсың. Менә мин үзеңә каршы чыккан кызны никахлап бирим, аны исеңә төшереп керерсең, – диде. Абыстай кызны никахлап бирде.

Егет янә өченче кич кунганда, агасы исенә төшеп: Бу җирдә озак торырга ярамас, – дип, яңа кәләше белән саубуллашып, үз юлына китте.

Көмеш сарай буйлап өч көн, өч төн үткәннән соң, күрде – бер бик зур алтын сарай янына бик зур вә матур итеп бакчалар корылган. Егет бераз каранып, хәйран булып торды һәм алтын сарайның тәрәзәсеннән килеп караса, баягы кебек кырык бер кол кызларның өстәлгә салып адәм

ите юганнарын күрде. Баягы кебек янә ишеккә барып сәлам биргән иде, баягыдан сылу, бер бите ай, бер бите кояш кебек бик матур кыз килеп моның сәламен алды һәм:

– Адәми затмы, пәри затмы? – дип сорады.

Егет, кызның матурлыгына хәйран калып, бераз карап-карап торды да, исенә килгәч, адәми зат икәнен белдерткәч, бу кыз да абыстайдан рөхсәт сорап, бу егетне сарайга, туры абыс-тасы янына алып керде.

Абыстай белән күрешеп, күрсәткән урынына утырып, китергән кош итләрен ашап, китергән эчемлекләрне эчкәч, егет абыстайга карап:

– И абыстай, син кайсы шәһәрдән буласың? – дип сорады.

Абыстай моңа:

– Мин фәлән патшаның хатыны, фәлән шәһәрдән идем, мине урлап шушы дию бу җиргә алып килде. Инде минем югалганыма фәләнчә ел булды. Минем дүрт улым бар иде. Инде алар үсеп, синең кадәр була торганнардыр, – диде.

Егет аңа каршы:

– Соң улларыңнан берсе синең яныңа килсә, син аны таныр идеңме? – диде.

– Әлбәттә таныр идем, кеше үз баласын танымыймы, – диде.

– Соң алай булгач, мин кем булам? – диде.

Абыстай:

– Белмим, – диде.

Егет:

– Алай булса мин синең улың булам. Мин фәләнчә айлардан бирле сине эзләп монда килеп җиттем. Аллага шөкер, синең нурлы йөзеңне күрдем, – дип, муенына барып асылынды. Сорашып, шатлыктан елаштылар.

Атасының исәнлеген, ике агасының юлдан кайтып киткәнлеген, үзеннән бер генә яшь олы абзасының күл буенда базда калганын – барын да аермачык сөйләп бирде. Сүзләр тәмам булгач, абыстай улын алып чыгып, бер сарайның ишеге төбенә алып килде дә, сарайның ишеген ачып, алдан улын кертеп җибәрде. Сарай ачылгач, егет сарайның уртасында биш йөз пот авырлыгында бер шар күрде. Анасы шул шарны егеткә алып чыгарга кушты. Егет шарны алып чыгыйм дип, барып тотынып караган иде, урыныннан да кузгата алмады. Шуннан соң анасы улына:

– Синең кавырсының да катмаган икән. Диюебез унике айлык юлга киткән иде. Киткәненә инде ике ай булды. Тагын ун айсыз кайтмаячак. Ул дөньяда адәм итләре ашап кинәнә, өйгә дә алып кайтадыр. Диюнең шундый бер җимеш бакчасы, бер күле бар. Шул алмагачның алмасын ашап, күленнән су эчкән кеше дөнья йөзендә беренче батыр булачак. Син өч ай иркенләп шул алмагачтан алма ашап, күленнән су эч. Шуннан соң мин сине яңадан, теге шарны күтәртеп, сынап карармын. Бу көйгә син батыр түгел әле. Сиңа ышанып юлга чыгарга ярамый, – диде.

Егет анасының сүзен тыңлап, өч ай шунда ашап-эчеп ятканнан соң, янәдән килеп кергәч, анасы моңа шарны яңадан күтәреп карарга кушты һәм диде:

– Диюнең һөнәре шул иде, буш вакытларында шул шарны алып чыгып, менә шул биек тауның башына ыргытып җибәреп, шар төшкән чагында яңадан бер кулы белән тотып алып, һавага ыргытып җибәрә иде.

Егет анасыннан ишеткән сүзләргә гарьләнеп, шарны ачу белән алып, тау башына ыргытып җибәреп, тәгәрәп төшкәндә тотып алыйм дигәндә генә, шарны тота алмыйча, шар егетне бәреп егып, тагын да үз юлына китеп, тау итәгенә барып төште.

Анасы бу хәлне күреп:

– Балакаем, инде кавырсының яңа гына ката башлаган икән, тагын берничә айлар ирек алсаң, үзеңә бераз көч керер, – диде.

Егет, яңадан алма ашап, бакчада тора башлады. Егет шунда ай ярым торганнан соң, анасы:

– И балакаем, инде тагын бер сынап карыйм, вакытлар кыскарып бара, – дип егеткә яңадан шарны ыргытырга кушты. Егет, анасының сүзен тыңлап, әлеге шарны ыргытып җибәреп, шар төшкән вакытта бер кулы белән генә тотып, яңадан биек тауның башына сыңар кулы белән ыргытып җибәрде. Икенче кат тагын тотып алып, ыргытып җибәрде.

Шулай итеп уйнаганнан соң анасы улына:

– Инде хәзер көчең диюнеке белән тигезләнде. Дию аңсыз-ан кайтып керсә дә, көрәшерлек көчең бар, – диде.

Анасы улын җитәкләп өйгә алып кереп:

– Йә инде, улым, җитәр, кыз куеныннан чык, аңсыздан дию кайтып керсә яисә туганнарыннан берсе килсә, харап булырбыз, – диде.

Шуннан соң анасы, тагын бер сарайга алып барып, ишеген ачып, икәүләшеп һавада очып йөри торган бер зур иске машинаны алып чыгып, ватылган җирләрен төзәтеп, тузаннарын кагып, юлга китәргә әзерләп куйдылар. Кереп, ашап-эчеп туйганнан соң, сарайдан кырык бер кызны да, кәләшен дә үзләре янына утыртып, югарыга күтәрелеп киттеләр.

Киткән чакта егетнең анасы бер әфсен укып, алтын сарайларны һәм бакчаларны юк итеп, бер алтын күкәй итеп йомарлап, кесәсенә салды. Алтын сарайларның, бакчаларның беленмәслек булып бәгъзе урыннары гына калды. Шул машина белән иртәдән кичкә хәтле генә очканнар иде, килгәндә очып кунак булып киткән көмеш сарайның уртасына килеп җиттеләр. Егет, анасына карап:

– Әни, без бераз монда туктыйк әле. Син машинаның рулен бор. Монда минем тагын бер кәләшем бар. Аны да алып чыгабыз, – диде.

Анасы егетне тыңлап, машинаны борып, көмеш сарайга килеп төштеләр. Анда боларны бик тансыклап көтеп торалар иде. Каршы алып, ашап-эчеп, ял итеп, кунак булып бу сарайны, алтын сарайлар кебек, көмеш йомырка ясап, кесәләренә салып, эчендәге кырык бер кол кызны һәм

үзенең хатынын алып, тагын алга таба очып киттеләр.

Шунда чак кына очып барганнар иде, бакыр сарай турысына килеп җиттеләр. Бу чакта бакыр сарайның диюе кайткан иде. Болар килеп төшкәннән соң, каршы һичкем чыгып алмады. Анасы егеткә карап:

– Улым, без моннан китик. Күрәсең, монда безне каршы чыгып алучы юк. Боларның диюләре кайткандыр. Әгәр дә кереп китсәң, ул вакыт безгә зыян китерерләр, – диде.

Егет, анасына карап:

– Әни, монда кермичә китәргә һич ярамый. Монда минем өченче хатыным бар. Шулкадәр алмалар ашап, сулар эчеп, инде бу диюдән куркып торыр хәл юк, – дип, машинадан төшеп, бакыр сарайның ишегеннән кереп китте.

Ни күзе белән күрсен, моны диюнең хатыны һәм кол кызлары үкереп елап каршы алдылар һәм егеткә:

– Бәхетебез юк икән, диюебез кайтты. Җир астында, фәлән сарайда йоклап ята. Тора калса, сине дә, безне дә үтерер, – диделәр.

Егет үзенең хатынына карап:

– Кайсы подвалда йоклый? – дип сорап, подвалның ишеген ачып кереп китте.

Керсә, ни күрсен, тугыз башын тугыз якка салып, бернәрсә белмичә, җәйрәп йоклап ята. Керүгә, алмаз кылычын чыгарып, бер башын кисеп төшерим дигәндә исенә килеп: Тукта әле, йоклаган кешене кем дә үтерә. Мин моны уятыйм да көчемне сынап, сугышып карыйм. Үлсәм, хак үлем булыр, – дип, диюнең баш очына килеп бераз утырды. Дию һаман уянмады.

Соңра сарайга кереп, диюңең хатынына:

– Бар, диюегезне уят. Мин аның белән көрәшеп, сугышып, көчемне сынап карар идем, – диде.

Диюнең хатыны:

– Адәми зат килгәндә, аны уята торган бер без бар. Син шул безне ал да, табан астына кертеп бетереп бута. Шуны сизеп, ул уяныр. Уянгач та сиңа тәмле сүзләр сөйли башлар. Әмма син, аның алай йомшак сөйләвенә карап, алданма. Ул бик хәйләкәр. Йомшак торган саен, син каты тор. Юкса, ул алдар. Кара, алданырга тырышма! – диде.

Егет безне алып диюнең бер табанына тыгып бутаган иде, дию бернәрсә дә сизмәде. Икенче табанына ныграк тыгып бутаган иде, дию сизеп уянды да, хатынына кычкырып:

– Кая, адәми зат килгән икән. Нигә кунак итмисез? – диде.

Егет аңа каршы:

– Мин ач түгелмен. Мин бары синең каныңа сусап кына килдем. Кая, тор, әйдә чыгып алышыйк, – диде.

Дию, егетнең бу сүзләренә гарьләнеп, урыныннан сикереп торып шул ук сәгать мәйданга чыгып, алышырга тотындылар. Шулкадәр

алыштылар – тигез – түмгәккә, түмгәкле җирләр карашакка әйләнеп беттеләр. Озак алыша торганнан соң, егет диюне күтәреп алып ыргытып җибәргән иде, дию килеп тезенә кадәр җиргә батты. Диюнең ачуы килеп сикереп торып, егетне тотып җиргә күтәреп бәргән иде, бил кадәр җиргә батты. Соңра егетнең ачуы килеп:

– Юк, бездә алай бәрмиләр, менә болай бәрәләр, – дип, диюне күтәреп алып җиргә бәргән иде, бил кадәр җиргә батты.

Шулай нихәтле алышсалар да, берсен-берсе җиңә алмады. Соңра дию:

– И егет, инде берникадәр алыштык, бер-беребезне җиңә алмадык. Мин бик ачыктым, бераз ашап чыгыйм, – диде.

Егет диюгә:

– Оятсыз, үзең генә ашарга оят түгелме? Мин дә арыдым, хәлем бетте. Мине дә алып кер, – диде.

Дию, риза булып, егетне дә өйгә алып керде.

Диюнең өендә ике өстәл бар иде. Берсенә үзе генә утырып ашыйдыр иде. Икенчесенә килгән кунакларын утыртадыр иде. Дию хатынынннан ашарга аш, эчәргә су сорады. Диюнең ике төрле суы бар иде – берсе хәл кертә торган, икенчесе хәл китәрә торган. Диюнең хатыны, эшне аңлап, диюгә хәл китәрә торган суны, егеткә хәл кертә торган суны салып биргән иде, дию эчүгә бөгелеп төште. Шул ук сәгать дию эшне сизеп, хатынына карап:

– Сез мине бүген харап итәсез икән, – диде.

Үтерергә теләсә дә, егеттән куркып, хатынын үтерергә кыймады.

Соңра дию белән егет, сахрага чыгып, тагын алыша башладылар. Егет диюне күтәреп бер ыргытып бәргән иде, дию башларына кадәр җиргә батты. Шул вакыт егет, алмаз кылычын чыгарып, диюнең тугыз башын тугыз җиргә кисеп ташлады да үзе сарайга керде. Хатын һәм кызлар, бу хәлне күреп, егеткә күп рәхмәтләр укып:

– Бу көнне дә күрәсебез бар икән, – дип, бик шатландылар.

Соңра егет:

– Әйдәгез инде моннан китик, – диде. Аңа каршы хатыны:

– Тукта, монда тагын безнең кардәшләребез бар, аларны коткарыйк, – диде.

Егеткә ачкычларны биреп, сарайларны тикшерергә киттеләр. Бер сарайны ачып җибәргәннәр иде, күрделәр: сарай тулы картлар икән. Бу картлар диюнең гадәтен белеп: Симезебезне тотып ашар инде, – дип, куркытып кача башладылар. Егет боларның курыкканын күреп:

– И картлар, сез миннән курыкмагыз. Мин дә сезнең кебек адәми затмын. Мин сезне диюнең кулыннан коткарам. Әйдәгез, чыгыгыз! – диде.

Соңра тагын бер сарайны барып ачкан иде, анда карчыклар яталар икән. Алар да куркышын: Монысы симез, монысы симез, – дип, берсен-берсе күрсәтә башладылар.

Аларга егет:

– Курыкмагыз, әйдәгез чыгыгыз, мин сезне коткарам, – диде.

Аннан соң бакыр сарайның картлысында янә бер зур сарай бар иде.

Хатын егеткә:

– Инде, егет, диюнең үләксәсен шул сарайга илтеп куйыйк. Ул сарай диюнең тегермәне иде. Ул, шул тегермәндә әлегә хәтле ничә меңнәрчә адәмнәрне тарттырып, азык итеп ашады. Хәзер инде үзе җәзасын күрсен, – диде.

Егет күтәреп киткәннән соң хатын тегермәнне кузгатып җибәргән иде, бераздан соң өстәлләргә кырык табак белән тулы төялгән итләр, ашарга яраклы булып, суганы, борычы сибелеп килеп тезелделәр. Хатын, тегермәнне туктатып:

– Менә инде күрәсез, бу дию ничә еллардан бирле никадәр кешенең башына җитте. Ул болай булыр дип гомерендә бер мәртәбә уйлаганы юк иде, – дип, сарайга кереп ашарга утырдылар. Ашап туйганнан соң егет, үзенең кош ата торган мылтыгын алып, ерак та түгел бер куе урманга кошлар атарга дип, ауга китте. Ләкин егетнең киткәнен берсе дә сизми калдылар.

Егетнең анасы:

– Монда инде бик озак тордык, – дип, тизрәк ашыктырып, кызларны утыртып, машина белән югары күтәрелеп киттеләр. Өч хатыннан берсе дә егетнең кайда калганын белмәделәр.

Бу сарайда берәү дә калмады. Ике көн киткәннән соң һава көймәсен тикшереп карасалар, күрәләр, егет көймәдә юк. Болар кире кайтырлар иде, диюнең нәселеннән берсе очрап һәлак итәр дип куркып, алга таба йөрделәр дә, бер зур шәһәргә җиткәнче берничә чакрым җиргә туктап, алтын вә көмеш; сарайларын җәеп, егетне шул җирдә көтеп калдылар.

Егет бу урманда бераз йөреп, төрле кошлар атып, кесә һәм кәләпүшләренә җиләкләр җыеп кайткач, хатыннарыма булыр дип шатланып бакыр сарайга барып керсә, ни күзе белән күрсен, бакыр сарайның эчендә һичкем калмаган.

Ашыйсы килеп, бүлмәләрне карап йөргән чакта, бер кечкенә генә бүлмәгә туры килде. Аның уртасында бер кечкенә генә өстәл торадыр иде. Аның өстендә зәңгәр күк сыман бер әйбер белән бер генә карыш буйлыгында чыбык ятадыр иде. Егет, барып, аптырап чыбыкны кулга алып: Бу ни эшкә ярый икән? – дип, күккә бәреп караган иде, моның каршысына бер гыйфрит килеп:

– Ни кушасыз? – диде.

Егет шул ук вакыт, чыбык белән күктә хикмәт барын сизеп, гыйфриткә карап:

– Минем аналарым моннан киткәннәр икән. Мин берүзем калганмын. Инде мине күпме вакытта аналарым артыннан илтеп җиткерерсең? – диюенә каршы, гыйфрит:

– Өч көндә илтеп җиткерермен, – диде.

Егет, моны озаксынып, чыбык белән күккә яңадан суккан иде, гыйфритнең икенчесе, моннан шәбрәге килеп чыкты да:

– Ни боерасыз? – диде. Егет моңа да:

– Минем аналарым артыннан күпмедә илтеп җиткерерсең? – диде.

Гыйфрит аңарга:

– Бер көндә, – дигән иде, егет тагын озаксынып бер сукты.

Өченче гыйфрит килеп:

– Ике сәгать эчендә җиткерермен, – диде.

Егет, шатланып, моның өстенә менеп утырды да, егетне шул вакыт китереп җиткерде. Егет:

– Менә инде мин туры сарайга барып керсәм, килешмәс.

Алар мине кызык иттеләр, тукта мин дә ал арны кызык итим, дип: Инде син мине туры сарайга илтмә, шәһәрнең читенә илт, – диде.

Гыйфрит, егетнең сүзен тыңлап, шәһәрнең читенә илтеп ташлады да үзе шунда ук юк та булды.

Егет шуннан җәяүләп шәһәргә кереп китте дә бер картның артыннан барып җитте.

– Карт кая барыр икән? – дип, артыннан сынап карады. Карт бер өйгә барып керде. Егет тә аның артыннан керде.

Карт кергәч тә бер шешә эчемлек алып эчте дә чыгып китте. Картның артыннан күрә-күрә егет тә китте. Карт, тагын каранып, калган акчасын алып, яңадан кереп эчеп чыкты. Соңра бер өйгә барып керде. Аның артыннан егет барып керсә, күрде: карт бер итекче икән. Егет картка карап:

– И бабай, син бер яхшы итекче икәнсең. Моннан соң син болай хезмәт итеп тереклек итмәссең. Тик минем бер сүзем бар. Шуны эшләсәң, мин сиңа бер мең тәңкә акча бирермен, – диде.

Карт:

– Кулымнан килерлек булса, мөмкин, – диде.

– Беләсеңме, шәһәрнең читендә ике сарай бар. Шунда минем күреп гашыйк булган бер кызым бар. Син шуңарга яучы бул, – диде. Карт, егетнең сүзен тыңлап, шәһәрнең читенә чыгып сарайга туры китте. Кыз да, бүген үзенә бер кеше киләсен төшендә күреп, сизеп торадыр иде. Шул арада сарайга килә торган картны күреп, аны каршы чыгып алып керде. Карт та егет әйткән кыз шул булырга кирәк дип:

– И кызым, миндә бер кунак егете бар. Ул сине күреп гашыйк булган һәм мине сезгә яучыга дип җибәрде. Инде сез ни дип әйтәсез? – диде.

Кыз картка:

– Ярый. Тик минем калымым бик зур бит. Адәм кулыннан килә торган эш түгел. Әгәр дә булдыра алса, мин аныкы, ул минеке, – диде. – Калымым шул: бер ефәк күлмәк. Аның һич җөе булмасын, өстемә таман гына да булсын. Нечкәлектә бармактагы балдактан үтәрдәй булсын.

Кечкенәлектә йомарлагач учка сыярлык булсын. Тагын бер калуш. Аның һичбер кадагы булмасын. Аягыма тап-таман булсын, – диде. һәм үз-үзенә: Әгәр дә боларны эшли алса, ул минем ирем булыр, – дип уйлады.

Карт:

– Бик яхшы, – дип, кайтып егеткә әйтте. Егет картка:

– Ярый, син шунда торып тор, мин барып алып килим, – дип, сахрага, эт тавышы ишетелмәслек җиргә китеп, кесәсеннән тылсымлы таякны алып күккә бәргән иде, бер гыйфрит килеп җитте.

– И хәзрәт, ни боерасыз? – диде. Егет тә гыйфриткә:

– Әлеге күлмәк белән калушны ничә сәгатьтә табып китерерсең? – диде.

Гыйфрит:

– Өч сәгатьтә табып китерермен, – диде.

Өч сәгать көтүе озак булыр дип, егет икенче кат суккан иде, икенче гыйфрит килеп:

– Бер сәгатьтә табып китерермен, – диде. Егет моңа да разый булмаенча, өченчесен чакырган иде, анысы:

– Ярты сәгатьтә китереп алдыңа куярмын, – диде.

Егет:

– Мин урынымда көтеп торырмын, – дип, гыйфритне эзләргә җибәрде. Гыйфрит урыныннан торып, алтын сарайга кереп, кызның янына килеп, буен-иңен үлчәп, кушылган буенча табып китерде. Егет шул заманда чокырда көтеп утырганда, гыйфрит килеп егеткә күрсәтте. Егет карап, бик ошатып, бик күп рәхмәтләр укып, күлмәк белән калушны алып кайтып, картка китереп тоттырды.

Карт алып, сарайга илтеп, кызга китереп бирде. Кыз алып киеп, үлчәп караган иде, үзе әйткәнчә тап-таман булып чыккан. Бик яратып: Бу эшләр дию мәмләкәтендә булмаган бер кеше эшли ала торган түгел, шул минем киявем икән, дип, кичкә килсен, – дип, картка вәгъдә биреп җибәрде.

Кич булгач, егет карт белән икәүләп сарайга килеп керделәр. Боларны кол кызлар, аңасы чыгып каршы алдылар. Егет күреп, анасы белән күрешеп, танышып, бик куанышып, шул минутта ашап-эчеп, алтын-көмеш сарайларны бер йомырка ясап кесәгә салып, үзләре шарларына утырып, картка бирәсе акчасын биреп, анасы киленнәренә:

– Инде улым һәркемнән алда менеп утырсын, – дип, әмер бирде. Нәм егетне алдан утыртып, барысы бергә очып киттеләр.

Бераз көннәр яланда очып килгәннәр иде, агасының калган чокырына килеп җиттеләр. Агасы боларның килгәнен күрде, тик кем килгәнен генә белмәде. Болар килеп төшкәннән соң, агасы боларны каршы алып, сөйләшеп, шул ук вакыт аны да шул шарга утыртып шәһәрләренә таба кузгалып киттеләр.

Тагын бераз килгәннән соң, Ак бүренең урманына килеп җиттеләр дә

бер бик әйбәт аланга килеп төштеләр. Болар шардан төшеп ашап-эчеп утырганда, Ак бүре боларның килгәннәрен белеп, ул да болар янына килеп җитте. Бик матур егет сурәтенә кереп, болар белән килеп күрешкән иде, бөтен кызларның күзләре ут шикелле янып, аңардан күзләрен алмадылар. Шуннан соң; егет, моның Ак бүре икәнен белеп, танышып-күрешеп, бик ныклап сыйлап, эчереп, Ак бүрегә карап:

– И, дустым Ак бүре, минә сиңа сүзем шулдыр: (өч кызны күрсәтеп) менә болар минем хатыннарым, (янә өчне күрсәтеп) боларын агаларыма багышладым. Шул алтыдан калганнарыннан үзегезгә ошаган берсен сайлап алыгыз, – диде.

Бүре сайлап алганнан соң, кыз да:

– Бигрәк матур егеткә туры килдем, – дип шатланды. Соңра болар саубуллашып янә үзләренең шәһәрләренә очып киттеләр. Ничә көннәр очып киткәннән соң, бер зур шәһәргә туры килеп, көмеш сарайның хуҗасы – унике башлы диюнең хатыны:

– Минем шәһәрем, – дип, егеткә күп рәхмәтләр укып, үз шәһәренә төшеп калды. Бу хатын шул шәһәрнең патша хатыны иде. Кайтып керүгә, үз патшасы белән күрешеп, бик шатланып үз йортларында тора башладылар.

Янә аз гына очып барганнар иде, тагын бер зур шәһәрнең турына килеп җиттеләр. Тугыз башлы диюнең хатыны бу шәһәрне:

– Бу минем шәһәрем, – дип, егеттән рөхсәт сорап, күп рәхмәтләр укып, төшеп калды. Егет шулай үзенең хатыннарыннан һәм агаларына атаган кызлардан башкасын, үзләренең теләүләре буенча, барысын да азат итеп, бу шәһәрдә калдырды.

Бу шәһәрдән озак бармадылар, үзләренең шәһәрләренә кайтып җиттеләр. Шәһәргә биш: чакрым кадәр калганда, көн кич булгач, инде иртә белән керербез дип, шунда туктап калдылар. Егетнең анасы кесәсенә йомырка ясап салган сарайларны, бакчаларны чыгарып, нәкъ дию шәһәрендәге кебек итеп корды. Хатынның ике улы, үзләренең бүлмәләренә хатыннарын алып кереп, ятып йокладылар.

Шуннан соң егетләрнең анасы тышка чыгып, диюдән алып кайткан балдагын бармагыннан алып, сызгырып җибәргән иде, – җирдәге чүпкә сан бар, гыйфриткә сан юк, – шулкадәр күп гыйфритләр килеп моның катына җыелдылар.

– Ләббәйкә, хәзрәт, ни боерасыз? – диделәр. Хатын боларга:

– Менә бу сарайдан шәһәргә хәтле таң атканчы бер алтын күпер эшләгез. Ул алтын күпернең ике ягыннан ике елга – берсе анда, берсе монда агып торсын. Ул елгалар өстендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән үрдәкләр, казлар йөзеп, бакылдашып, каңгылдашып торсыннар. Елганың ике читендә алмагачлар үсеп торсын. Алмалары пешеп, суга өзелеп төшеп торсын. Аны йөзеп йөри торган кошлар ашап торсын. Ул күпернең өстендә җигүле бер тройка ат булсын. Арбасының көпчәкләре алтыннан булсын.

Өстенә утырган чакта селкенерлек булмасын. Ул атларның дилбегәләрен тотучы кеше куркырлык – чуеннан да кара, бер зур мыеклы гыйфрит булсын. Шуларны таң атканчы тәмам итегез, – диде дә үзе йокларга ятты.

Хатын берничә сәгатьләр генә яткан иде, гыйфритләр килеп моның ишеген кактылар. Чыгып караган иде, бар да үзе дигәнчә тәмам булган. Соңра, гыйфритләрне үз юлларына җибәреп, бераз торган иде, таң да атты.

Таң атып яктыргач, патша, урыныннан торып, ишектән чыккан иде, ишек төбеннән сузылып киткән күперне күреп:

– Ах, харап булганбыз икән – ишек төбенә кадәр су баскан, – дип, йөгереп кереп китте дә, вәзирләренә: Әйдәгез, тизрәк чыгыгыз, – диде.

Вәзирләр чыгып карасалар:

– И падишаһым, ялгышкансыз. Бу – су түгел. Озакламый бер хәбәр булыр. Йә хатының, йә балаларың кайткандыр, – дип, патшаны сөендерделәр. Патша, шатланып үзенең киемнәрен киеп, тәхеткә утырып, көтеп торганда, патшаның хатыны хат язып, гыйфрит аны патшага китереп тапшырды. Хатта болай язылган иде: Хөрмәтле патша хәзрәтләре, сезгә сәламнәрем бәгъдендә үтенеч шулдыр: Аллага шөкер, без исән-сау кайтып җиттек; сәгать унда шушы күпернең башында кардәш-кабилә, мулла-мәзиннәр белән көтеп торыгыз. Шушы гыйфрит сезне безгә кунаклый алып килер.

Сәгать унга кадәр патша, агай-энеләрен җыеп, яхшы киемнәрен киеп, көтеп тора иде, гыйфрит килеп болар янына туктады да:

– Әйдәгез, утырыгыз, – дип, боларны утыртты һәм шул ук минут әлеге алтын сарайга китереп җиткерде.

Патшаның уллары белән килениәре, боларны каршы алып, бик зурлап, ашатып-эчертеп, аш тәмам булганнан соң, килгән кунакларга кайтырга рөхсәт бирелеп, алар өйләренә гыйфрит арбасына утырып кайтып киттеләр. Монда патша бары мулла-мәзиннәр, уллары белән үзе калып, патшаның кечкенә улы атасына анасын сау-сәламәт алып кайтканын әйтеп һәм аны яңадан никахлап алуын үтенеп, аңа патша да разый булып, шул ук сәгать никах укытып, ун көн уен ясап, тугыз көн туен ясап, тумаган туры бияне суеп, шуның сөяген патша үзенең хатыны белән көн дә тотып кимерә иде, ди.

Шуннан соң патша хатынын үзенең өенә алып кайтып, бергә тора башладылар. Егет янә агаларына дигән кызларына да аларны никахландырып, утыз көн уен ясап, кырык көн туен ясадылар. Агалары да хатыннарын үз өйләренә алып кайтып тора башладылар. Әмма егет үзенең хатыны белән шул сарайда утырып калды. Тыныч кына торган вакытта тугыз башлы диюнең һәм унике башлы диюнең хатыны, егеткә хат язып, хатыннары белән кунаклый килүен үтенделәр. Шул ук сәгать егет, өч хатыны белән, боларга кунакка барып, алар да егетне бик зурлап каршы алып, бик күп бүләкләр биреп, кадерләп кире сараена озатып җибәрделәр. Егет үзенең сараена кайтып, өч хатыны белән үз сараенда рәхәтләнеп тора

башлаганнар, ди.

## II вариант
## Таңбатыр

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер патша. Бу патшаның булган, ди, өч кызы. Патша кызлары берсеннән-берсе матур булганнар, ди. Көннәрдән бер көнне бу өч кыз болынлыкка йөрергә дип чыкканнар. Болар болынлыкта йөргән вакытта гына бик каты җил-давыл чыга да кызларның өчесен дә күтәреп алып та китә. Патша, үзенең кызларының югалганын белеп, бик зур кайгыга төшә. Көн эзләтә патша бу кызларны, төн эзләтә, үз патшалыгында урманы, су буйлары калмый моның, бөтен җирдән эзләтеп карыйлар, кызларны таба алмыйлар.

Шулай патша торган шәһәрнең читендәге кечкенә генә бер йортта яшәгәннәр икән, ди, бер ир белән хатын. Болар бик фәкыйрь булганнар. Боларның булган икән, ди, өч уллары. Олы улларын Кичбатыр дип, уртанчысын Төнбатыр дип, ә иң кечесен Таңбатыр дип йөрткәннәр, ди. Бу егетләр, ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, бик тиз вакыт эчендә дәү булып җиткәннәр, ди.

Үсеп җитү белән болар урамга уйнарга чыгалар. Яшьләр арасында болардан да көчле берәү дә булмый. Уйнаган вакытларында кешенең кай җиреннән генә тотсалар да умыралар да алалар, ди, болар. Кәшәкә шаралы уйнаганда да бол ардан да оста уйнаучы юк, көрәшә башласалар да, кешене имгәтми калдырмыйлар, ди, болар.

Бу өч туганның көчләрен кая куярга белми йөргәннәрен күреп, бер карт кына кеше әйткән, ди боларга: Сез, ди, анда-монда сугылып, урынсызга кеше имгәтеп йөргәнче, әнә патша кызларын табып алып кайтып бирер идегез, менә шунда күренер иде сезнең батырлыгыгыз, – ди.

Шуннан соң болар, өйләренә кайтып, ата-аналарыннан рөхсәт сорыйлар:

– Әти, диләр, патша кызлары югалган, дип әйтәләр, без шул кызларны алып кайтып бирик микән әллә? – диләр. Ата-аналарының боларны бер дә җибәрәселәре килми, ризалык бирмиләр икән, ди.

– Әй, улларым, без сезне теләп кенә алдык бит инде, сез чыгып киткәч, безне кем карар, кем туйдырыр? – ди әтиләре.

Малайлары әйтә:

– Әй, әти, без патша эше белән йөргәч, сезне патша тәрбияләр әле, – диләр.

– Юк инде, безгә патшадан бер рәхим дә, бернинди ярдәм дә буласы юк, – дип әти-әниләре елашалар.

Бу өч батыр әти-әниләреннән бик инәлеп сорыйлар да, рөхсәт алып, патшага барып әйтәләр:

– Менә без синең кызларыңны эзләргә чыгарга уйлыйбыз, безнең үзебез белән чыгарга бернәрсәбез дә юк; әти-әниләр дә бик фәкыйрь торалар, –диләр.

Патша боларга ашарга-эчәргә бераз азык бирергә була.

Әти-әниләре белән саубуллашып, өч егет чыгып китәләр юлга. Баралар-баралар болар, атна китәләр, бара торгач барып керәләр бер урманга. Урманның эченәрәк керә барган саен, болар бара торган юл тарайганнан-тарая барып, соңыннан тар гына бер сукмакка калган, ди. Шул тар сукмак белән бара торгач, болар барып чыккан, ди, бик матур күл янына. Ул вакытта инде ашарларына беткән була. Таңбатыр әнисе юлда кирәк булыр дип биреп җибәргән энәсен ала да, ут ягып, шул энәне утта кыздырып, бик шәп бер кармак ясый. Шуннан соң, су буена төшеп, балык тота башлый. Кичкә хәтле бер-ике пот балык тота да бу, шул балыкларын пешереп, абыйларын туйганчы ашата. Хәзер тамак кайгысы бетте инде боларның. Таңбатыр әйтә абыйларына:

– Безнең өйдән чыгып киткәнгә бик күп вакыт үтте, ди, без кай җирләрдә йөргәнебезне дә белмибез, бернәрсә дә күргәнебез юк әле безнең, – ди. Абыйлары бер җавап та бирмәгән моңа. Шуннан соң бу, бик биек бер агач башына менеп, тирә-якны карый башлый. Таңбатырның агач башына менеп утыруы гына була, кузгала җил-давыл, кузгала җил-давыл, бу давыл шулхәтле көчле була, юлына туры килгән калын-калын агачларның башларын кыеп кына алып китә икән, ди. Таңбатыр бу җил-давылның котырганын карап тора да: Әллә бу теге патша кызларын күтәреп алып киткән җил-давыл микән? дип уйлый. Озак та үтми, әлеге җил-давыл бер җирдә бөтерелеп, коточкыч булып өерелеп-өерелеп тора да бер биек тау башына барып туктый. Тау башында бик яман бөтерелеп тора-тора да бик ямьсез бернәрсәгә – дию пәриенә әверелә. Дию пәриенә әверелә дә бу, тау кырыена төшеп, шундагы бер зур тишеккә кереп китә.

Таңбатыр, тиз генә агач башыннан төшеп, дию кергән тишекне эзләп таба. Бик зур тишек икән, ди, бу. Шуннан соң Таңбатыр, зур гына бер таш алып килеп, әлеге тишекнең авызын томалап куя да тиз генә барып абыйларын уята. Абыйлары бер дә ашыкмый торган кешеләр булалар. Әкрен генә торып, Таңбатыр хәзерләп куйган балыкны пешереп, туйганчы ашап-эчкәннән соң гына, теге тау тишеге янына китәләр.

– Менә ул шушы тишеккә кереп югалды, без аның артыннан төшәргә уйласак, башта менә шушы ташны алып ташлыйк, – ди Таңбатыр.

Кичбатыр ташка барып тотына – кузгата алмый. Төнбатыр барып тотына – аннан да бернәрсә дә чыкмый. Шуннан соң Таңбатыр ташны, күтәреп алып, селтәп кенә җибәрә – таш тау астына тәгәрәп төшеп китә. Таңбатыр әйтә абыйларына:

– Безнең беребезгә менә шушы тишектән төшеп, теге диюне эзләп табарга кирәк, ди, патша кызларын шул урламадымы икән? – ди.

Өч туган бергәләп киңәшәләр дә, урманга кереп, кочак-кочак юкә суеп алып чыгалар. Шул юкәләрдән бик калын итеп аркан ишә башлыйлар. Өч көн, өч төн буена бик нык, бик озын итеп ишәләр болар арканны. Шул арканның бер очын Кичбатырның биленә бәйләп, аны тау тишегенә

төшереп җибәрәләр. Төшеп китә бу. Кич булды дигәндә генә арканны селкетә Кичбатыр: Тартып чыгарыгыз, дип. Энеләре тартып чыгаралар.

– Төбенә җитә алмадым, аркан кыска булды, – ди Кичбатыр.

Шуннан соң болар тагын бер тәүлек аркан ишәләр. Хәзер инде шул арканга бәйләп Төнбатырны төшереп җибәрәләр. Көтәләр-көтәләр болар, тегеннән бер хәбәр дә юк. Бер көн, бер төн үтте дигәндә, теге арканны селкетә. Моны да тартып чыгаралар.

– Бик тирән икән, төбенә җитеп булмады, аркан җитмәде, – ди Төнбатыр. Шуннан соң болар тагы ике төн, ике көн буена утырып аркан ишәләр. Арканны тагын да озын итеп ишеп, аның бер очын Таңбатырның биленә бәйлиләр. Тау тишегенә төшәр алдыннан Таңбатыр әйтә абыйларына:

– Тиз генә чыга алмасам, сез мине нәкъ бер ел көтегез, ди. Бер ел тулды дигәндә чыгып җитмәсәм, көтеп тормагыз, үз юлыгызны карагыз, – ди. Шулай ди дә бу Таңбатыр, абыйлары белән саубуллашып, тау тишегенә төшеп китә.

Ярар, Таңбатырның абыйлары шунда калып торсыннар. Без хәзер Таңбатыр белән аска төшик.

Төшә-төшә Таңбатыр, нихәтле вакыт төшеп тә, тау тишегенең төбенә җитә алмый, арканы тагын да кыска була моның. Кире чыгасы килмичә, кылычын алып арканны кисеп җибәрә бу. Бик озак очканнан соң, барып бәрелә бу бик каты нәрсәгә. Шунда ук һушыннан китеп, өч тәүлек аңына килә алмыйча ята, ди, бу. Шуннан соң, әкрен генә торып, тагын да китә бу. Бара-бара бу, шулай итеп бара торгач, моңа бер тычкан очрый. Бу тычкан бер генә мәртәбә селкенә дә кеше була.

– Нихәл, Таңбатыр, нишләп йөрисең монда? – ди.

– Менә, – ди егет, – бер дию пәриен эзләп төшкән идем дә, монда китәргә урын юк, чыгарга җай юк, – ди.

Тычкан әйтә:

– Ул дию пәрие сезне алдады бит, ди, сезнең элекке арканыгыз да тау тишеге төбенә җиткән иде, дию, сезне алдап, чокырның төбен аскарак төшереп җибәрде, ди. Хәзер син бик тирәндә инде, мин булышмыйча, моннан чыга алмассың, – ди.

Егет нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап торганда, тычкан әйтә:

– Менә мин сиңа дүрт полк тычкан солдаты бирим, ди, алар җирне казып торырлар, ә син таптап менеп кенә торырсың, ди. Шулай итеп, алар сине менгереп җиткерерләр бер сукмакка хәтле ди. Шул сукмак белән җиде көн, җиде төн буена, бернәрсә күрмичә, караңгыда барырга туры килер, курыкма, ди. Шул юл белән бара торгач, сиңа очрар җиде кат чуен капка, ди, шул капкаларны ватып чыга алсаң, якты дөньяга чыгарсың, вата алмасаң, сиңа бик авырга килер, ди. Якты дөньяга чыгу белән, янә бер сукмак булыр, син шул сукмак белән китәрсең. Шул сукмак белән җиде тәүлек барганнан соң, күренер сиңа бер сарай, ди. Шулай ди дә бу, яңадан

бер генә мәртәбә селкенү белән тычкан сурәтенә кереп, күздән югала.

Егет, дүрт полк тычкан солдатлары казыган юл белән бик күп вакытлар барганнан соң, барып җитә теге җиде чуен капка янына. Барып җитү белән, үзенең чукмарын алып, капкага бик каты итеп сугып җибәрә, чуен капка таралып китә. Шулай итеп, бу җиде капканы да бәреп үтеп китә. Бара-бара бу, барган саен, дөнья яктырганнан-яктыра бара, ди. Җиде тәүлек юл киткәч, моңа зур кирпечкә охшаган бер кызыл нәрсә күренә. Барып җитә бу, янына барып карый, зур бер кирпеч икән бу. Кирпеч өстендә бакыр атка атланган, бакырдан коелган киемнәр кигән бер каравылчы тора икән, ди.

– Әй, адәм заты, – ди каравылчы, – бу тирәдән кит җәтрәк, ди. Син бу тирәгә ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, дию патшасы кайтып керсә, тотып ашар үзеңне, – ди.

Егет әйтә:

– Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, анысын белеп булмый әле, ди. Хәзергә минем бик каты ашыйсым килә, китер әле берәр нәрсә ашарга, – ди.

– Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк шул, ди, менә хуҗам кайткач ашатырмын дип хәзерләп куйган бер түшкә үгез ите, бер мич ипием, бер мичкә әче суым бар, шуннан башка бернәрсәм дә юк, – ди.

Егет әйтә:

– Ярар, ди, хәзергә миңа шулар да җитеп торыр, ә хуҗаңа ашап-эчеп торырга туры да килмәс, – ди.

Шуннан соң теге кеше, атыннан төшеп, бакыр киемен сала да, Таңбатырга ашарга хәзерләп бирә. Бу солдат киеме кигән кыз кеше икән. Егет бу кыз китергәннәрнең барын да ашап бетерә дә йокларга ятарга җыена. Ятар алдыннан сораша инде бу кыздан:

– Ул дию пәрие кайчан кайтыр икән? — ди.

– Ул иртәгә иртә белән менә шушы бакыр күпер өстеннән кайтыр, – ди кыз.

Егет әйтә:

– Менә сиңа бер без, ди, дию кайта башлагач, шушы без белән минем чигәмә чәнчеп уятырсың, – ди. Шулай ди дә йокларга ята бу. Диюнең кайтыр вакыты җитү белән, теге кыз моны уятырга тотына, уята алмый. Без белән чәнчергә кызгана, уятмый калдырсам да яхшы түгел дип уйлый. Шулай да бик каты итеп уята башлагач, Таңбатыр сикереп тора:

– Әй, ди, мине без белән чәнчеп уятырга кирәк иде, ул вакытта мин тагын да зәһәрләнебрәк китәр идем, – ди.

Таңбатыр теге кыз әйткән бакыр күпер астына кереп ята. Бервакытны, җил-давыл куптарып, дию бакыр күпергә якынлаша башлый. Күпер янына иң элек моның эте килеп җитә. Диюнең эте күпер янына килеп җитә дә, күпергә кермичә, шыңшып, хуҗасы янына кире китә. Дию, аңа камчысы белән генә селтәп, атына атланган килеш күпергә барып керә.

Күпергә барып керү белән, моның аты да шып туктый. Диюнең ачуы килеп атына сугып җибәрә:

– Һәй, ди, нигә куркасың? Әллә монда Таңбатыр килеп яткан дип уйлыйсыңмы, ди, әле ул монда килү түгел, анадан да тумагандыр, – ди.

Диюнең шулай дип әйтеп кенә бетерүе була, бакыр күпер астыннан тып итеп Таңбатыр килеп чыга. Килеп чыга да:

– Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән, – дип, дию пәрие каршысына килеп баса.

– Килсәң, – ди, дию әйтә, – әллә ни олы гәүдәле түгел икәнсең әле, ди, ике кабып, бер йотарга гына җитәрсең, – ди.

Таңбатыр әйтә:

– Гәүдәсе чуклы булыр, алай тиз генә йота алмассың, – ди. Дию әйтә:

– Күп сөйләшеп торма, ди, алыш бармы, көрәш бармы? – ди.

– Алыш агаң башына булыр, әйдә көрәшик, – ди. Шуннан көрәшергә тотыналар да, алыша алмыйча шулкадәр

Озак йөриләр болар, шул тирәләр бөтенләй казылып чокырга әйләнеп бетә. Йөри торгач, диюнең хәле бетә башлый. Шул вакытта Таңбатыр моны күтәреп сала да, кылычын суырып алып, диюне тураклап, әрдәнә итеп өеп куя. Шуннан соң бу диюнең атына атланып, аның сараена китә. Диюнең әлеге каравылчысы моңа каршы йөгереп чыга:

– Хәзер куркыр кешем юк, әйтергә ярый, ди, мин фәлән патшаның олы кызы идем, мине бу дию пәрие урлап алып киткән иде, зинһар, мине монда калдыра күрмә, алып кына кайта күр үзең белән, – ди.

Таңбатыр әйтә:

– Без өч агай-эне сезне эзләргә дип чыккан кешеләр, – ди. Патша биргән язуны кесәсеннән чыгарып күрсәтә. Патша кызы шатлыгыннан нишләргә белми. Таңбатыр әйтә:

– Атаңның вәгъдәсе буенча, син минем олы абыйга булырга тиешсең, хәзергә шушы бакыр сарайда торып тор, кайтышлый мин сине кереп алырмын, – ди.

Өч көн ял иткәннән соң, юлга чыгар алдыннан, Таңбатыр сорый теге кыздан:

– Синең сеңелләрең кая, аларны ничек эзләп табарга? – ди. Кыз әйтә:

– Дию пәрие мине бик каты тотты, беркая да чыгармады. Минем барып күргәнем юк, уртанчысына хәтле җиде тәүлек юл барырга кирәк, – ди.

Таңбатыр, кызга исәнлек-саулык теләп, юлга чыгып китә. Тау-ташлар үтеп, җиде тәүлек киттем дигәндә барып җитә бу бер көмеш сарайга. Көмеш сарай кояшта ялт итеп тора икән, ди. Барып керү белән, көмеш атка атланган, көмештән койган киемнәр кигән бер солдат каршылый моны. Туктата. Таңбатыр янына килеп әйтә бу:

– Әй адәми зат, ди, син монда ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, исән-сау чакта чыгып кит моннан, хуҗам кайтса, ашар сине, бер генә

йотар, – ди.

Таңбатыр әйтә:

– Хуҗаң тизрәк кайтсын иде әле, ди, әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, ди. Менә минем җиде тәүлек буена рәтләп ашаганым юк, иң элек син миңа ашарга китер, – ди.

– Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк, хуҗама дип әзерләп куйган ике түшкә үгез итем, ике мич ипием, ике мичкә эче суым гына бар, – ди.

– Ярар, хәзергә җитеп торыр, китер әле шул арны, – ди.

– Хуҗама ничек дип җавап бирермен икән соң? – ди.

– Курыкма, ди, хуҗаңа ашап-эчеп торырга туры килмәс, – ди егет.

Шуннан соң теге көмеш киемле солдат Таңбатырга ашар-га-эчәргә китереп бирә. Таңбатыр, туйганчы ашап-эчкәннән соң, яхшылап кына сораша бу солдаттан:

– Хуҗаң кайчан кайта? – ди.

– Ул иртәгәләргә кайтып җитәргә тиеш, – ди.

– Кайсы яктан кайта ул? – ди.

– Менә шушы сарай артыннан ага торган елга аркылы бер көмеш күпер булыр, ди. Һәрвакытта шул көмеш күпер аркылы кайта ул, – ди.

– Мин хәзер ял итәргә ятам, хуҗаң кайтып җитәрәк, мине уятырсың, ди, әгәр дә бик каты йоклап китсәм менә шушы без белән чигәмә кадарсың, – дип, солдатка бер без чыгарып бирә дә йокларга ята бу.

Таңбатыр бер көн, бер төн йоклаганнан соң, дию пәриенең кайтыр вакыты җитә. Дию пәриенең якынлаша башлавын сизеп, теге каравылчы солдат уята башлый, уянмый гына бит теге. Уята алмый аптырагач, утырып елый бу моның янында, Без белән чәнчер иде, кызгана, башкача уята алмый. Инде без белән чәнчеп уятыйм, дип кенә торганда, Таңбатыр моның елавын ишетеп уянып китә. Солдат әйтә:

– Тизрәк тор, ди, югыйсә, дию пәрие кайтып җитә инде, кайтып керсә, икебезне дә харап итәр, – ди.

Таңбатыр тиз генә тора да, кылычын алып, теге көмеш күпер астына барып ята. Күп тә үтми, җил-давыллар чыгарып, дию пәрие кайтып та җитә. Иң элек моның эте күпергә килеп керә. Бер-ике генә атлый да эт шыңшып хуҗасына таба кире чаба. Дию пәриенең моңа бик каты ачуы килеп камчысын селти дә көмеш күпергә чабып кереп китә. Күпер уртасына җитүгә, ат шып туктый. Дию атына тагын бер сугып җибәрә, аты урыныннан да кузгалмый моның.

– Их, син, – ди, дию әйтә, – котың чыккан икән, ди, әллә син монда Таңбатыр килеп җитәр дип уйлыйсыңмы, Таңбатыр анадан да тумаган әле, – ди. Диюнең шулай дип әйтеп бетерүе генә була, Таңбатыр көмеш күпер астыннан килеп тә чыга.

– Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән, – ди.

– Килсәң, бик шәп булган, – ди дию, – мин сине ике кабармын, бер йотармын, – ди.

– Йота алмассың, сөяге каты булыр, – ди.

– Ярар, алай булса, алыштанмы, көрәштәнме? – ди.

– Алыш агаң башына булыр, әйдә көрәшәбез, – ди Таңбатыр.

Шуннан болар көрәшергә тотыналар. Таңбатыр диюне күтәреп ала да җиргә китереп бәрә, тегенең сөякләре өзгәләнеп-өзгәләнеп китә. Шуннан соң Таңбатыр моның сөякләрен әрдәнә итеп өеп куя да, диюнең атына атланып, солдат янына кайта.

Солдат әйтә:

– Әй, абый, ди, зинһар, син мине монда калдыра күрмә, ди, мин солдат түгел, шулай киендем генә, мин фәлән патшаның уртанчы кызы идем, син мине үзең белән алып кайта күр, – ди.

– Ярар, – ди егет, – минем уртанчы агама булырсың, ди. Моңарга да патша биргән язуны чыгарып күрсәтә.

– Син шушы көмеш сарайда торып тор, ди, мин сине кайтышлый кереп алып китәрмен, хәзер синең сеңлеңне эзләргә китәм, ди. Ул кайсы якта, моннан еракмы? – ди.

– Шушы көмеш атка атланып барсаң, моннан җиде тәүлек юл ул, – ди кыз.

Егет көмеш атка атланып китә. Җиде тәүлек дигәндә, теге алтын сарайга барып җитә. Алтын сарай калын стена белән әйләндереп алынган. Алтын капка төбендә алтын кием кигән, алтын атка атланган бер сакчы йөреп тора икән, ди. Таңбатыр килеп җитү белән, теге сакчы әйтә:

– Әй, адәми зат, монда нишләп йөрисең, ди, сине бит дию ашар, – ди.

Егет әйтә:

– Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, хәзергә минем бик нык ашыйсым килә, тамагымны туйдыр әле син, – ди.

Сакчы әйтә:

– Минем хуҗам өчен хәзерләп куйган өч мичкә эче суым, өч мич ипием, өч түшкә үгез итеннән башка бернәрсәм дә юк, – ди.

– Миңа шушылар җитәр, – ди егет.

– Алай булса, – ди сакчы, – әнә тегендә чуен капка булыр, шул капканы ачып керә алсаң, ашарыңа бирермен, – ди.

Шуннан егет чуен капканы сугып вата да сарайның эченә кереп китә. Сакчы моның көченә шакката. Бу сакчы Таңбатырны, бер бүлмәгә алып кереп, ашата да эчертә. Ашап-эчкәч, егет сораша бу сакчыдан:

– Хуҗаң кайчан кайта, кая таба китте? – ди.

– Әнә теге калын урман ягыннан кайта, ди. Анда бер алтын күпер булыр, ди. Дию пәрие, алтын атка атланып, әнә шул күпердән кайтыр, үзенең этен иярткән булыр, – ди.

Егет әйтә:

– Мин хәзер ял итәргә ятам. Хуҗаң кайтыр вакыт җитү белән, мине уятырсың, уянмасам, менә шушы без белән чәнчерсең, – дип сакчыга бер без бирә.

Егет яту белән йокыга китә. Бер көн, бер төн үтте дигәндә, теге диюнең кайтыр вакыты җитә. Сакчы егетне уятып карый, кая ул, теге кузгалып та карамый. Шуннан соң сакчы егет биргән безне алып бот итенә чәнчеп җибәрә, егет: Ай, рәхмәт, бик вакытлы уяттың әле, – дип сикереп тора. Сакчы шунда утырган бер мичкәдән бер чүмеч су алып бирә:

– Менә бу суны эчеп кит, көч кертә торган су бу, — ди. Егет суны эчә. Шуннан соң сакчы, Таңбатырны тагын бер бүлмәгә алып кереп, әйтә тегеңәр:

– Диюнең үзенә килгән кешене өйгә алып кайта торган гадәте бар. Менә монда ике мичкә бар, аның берсендә көч кертә торган су, икенчесендә хәл бетерә торган су, син туларның урыннарын алыштырып куй, – ди. Егет мичкәләрнең урыннарын алыштырып куйганнан соң сакчы белән саубуллашып чыгып китә дә теге алтын күпер астына кереп ята.

Бер дә бер вакытны дию алтын атына атланып, этен ияртеп күпергә кайтып җитә. Диюнең эте күпергә кермичә, койрыгын бот арасына кыстырып, кире хуҗасы янына чабып, елагансыман итә. Диюнең моңа бик каты ачуы килә. Бик нык камчы белән сугып җибәрә дә күпер өстенә кереп китә бу. Ат күпер уртасына килеп җитү белән шып туктый. Дию атына сугып та карый, ат бер генә адым да алга атламый, ди. Шуннан соң дию атына бик каты ачуланып:

– Нәрсә син, әллә монда Таңбатыр килер дип куркасыңмы, Таңбатыр анасыннан да тумагандыр әле, – ди. Дию пәриенең шулай дип әйтүе генә була, Таңбатыр күпер астыннан килеп тә чыга:

– Таңбатыр анасыннан да туган, килеп тә җиткән , – ди.

Дию пәрие әйтә:

– Мин сине бик олы гәүдәлеме дип уйлаган идем, син бик бәләкәй икәнсең. Сине ике кабарга, бер йотарга була икән, – ди.

– Ашыкма, тамагыңа торыр, – ди. Шуннан соң дию әйтә:

– Алай булгач, көрәштәнме, алыштанмы? – ди.

– Алыш атаң башына булсын, көрәш синең башыңа булсын, мин синең агаларыңны үтереп бетердем инде, – ди.

Шуннан тотыналар болар көрәшергә. Көрәшәләр-көрәшәләр, бер-берсен җиңә алмыйлар. Көчкә көч туры килә инде боларның. Бик озак йөри торгач, Таңбатыр тегене арыта. Шуннан соң дию пәрие сизенә башлый. Тукта, ди, бу минем хәлне бетереп үтерә күрмәсен, өйгә кайтып ял итим әле мин, – дип уйлый. Әйтә Таңбатырга:

– Өйгә кайтып бераз ашап-эчик, ди. Аннан соң яңадан көрәшергә тотынырбыз, – ди.

Дию пәриенең сараена кайтып ашыйлар-эчәләр болар. Дию пәрие мичкәләрнең алыштырылуын белмичә, көч кертә торган су урынына, көч бетерә торган мичкәдәге суны эчә. Таңбатырга көч кертә торган суны бирә. Шуннан соң болар китәләр яңадан теге күпер янына. Барып җитәләр. Дию әйтә:

– Алыштанмы, сугыштанмы? – ди.

– Алышудан курыксаң сугышырга да була, әйдә сугышабыз, – ди.

Күпер янындагы аланга төшәләр. Шуннан шобага салалар – кемгә алдан сугарга килеп чыга. Дию пәриенә алдан сугарга килеп чыга. Иң элек дию пәрие китереп бәрә Таңбатырга. Таңбатыр тубыгыннан җиргә кереп бата. Аягын җирдән тартып алып, Таңбатыр сугып җибәрә тегеңәргә – дию пәриенең аягы тезеннән җиргә бата. Дию пәрие торып сугып җибәрә, Таңбатыр тезеннән бата. Таңбатыр яңадан сугып җибәрә, дию пәрие биленнән бата. Дию пәрие кабалана-кабалана чыга да Таңбатырга китереп суга, Таңбатыр биленнән бата, чыгарга тырышып карый, чыга алмый. Дию әйтә:

– Чык-чык, борча, ди, нишләп ятасың туфракта? – ди.

– Кайгырма, ди, борча чыгар ул, менә син ничек чыгарсың икән! – ди.

Шулай ди дә, бөтен көче белән бер селкенеп җибәрүе була, сикереп чыга бу. Дию каршысына килеп баса да кизәнеп диюгә сугып җибәрә, дию муеныннан җиргә бата. Шуннан Таңбатыр әйтә:

– Чык, күсәк, ди, нишләп ятасың анда! – ди.

Дию пәрие тәмам хәлдән тая. Таңбатыр кылычын алып дию пәриенең башын өзеп төшерә, гәүдәсен өстерәп чыгарып вак-вак итеп тураклый да әрдәнә итеп өеп куя.

Таңбатыр, диюнең атына атланып, алтын сарайга кайтып китә. Моны теге сакчы бик шатланып каршы ала:

– Әй, егет, ди, мин сакчы солдат түгел бит, мине шулай киендерделәр генә, мин фәлән патшаның кече кызы бит, ди, мине дә алып кайт, үзеңнән калдырма, – ди.

Таңбатыр моңа патша язуын бирә дә әйтә:

– Мин сезнең апаларыгызны да коткардым инде, ди. Апаларың абыйларыма чыкмакчы булдылар, риза булсаң, син минем җәмәгать булырсың, – ди.

Риза булышалар да үзләренчә шунда ук туй да ясап алалар. Берничә көн кунак булып ял иткәч, туталары янына кайтырга хәзерләнәләр. Юлга чыгар алдыннан егет әйтә:

– Әй, бу алтын йортлар әрәм булып калалар бит, – ди.

Кыз әйтә:

– Син алар өчен кайгырма, җае табылыр, – ди. Шуннан соң болар, юл кирәкләрен алып, атка атланып чыгып китәләр. Бераз киткәч, кыз алтын сарайга таба әйләнеп кулъяулыгын селтәгән иде, алтын сарай алтын күкәй булып тәгәрәп килеп керде кызның кулына. Кыз бу алтын күкәйне яулыкка төрә дә егеткә бирә:

– Мә, син сакла инде моны, – ди.

Баралар-баралар болар, җиде тәүлек үтте дигәндә, барып җитәләр теге көмеш сарайга. Патша кызлары елашып күрешәләр. Өч көн, өч төн

көмеш сарайда кунак булганнан соң, хәзерләнеп юлга чыгып китәләр. Бераз җир баргач, патша кызы көмеш сарайга борылып кулъяулыгын селкеп җибәргән иде, көмеш сарай көмеш күкәйгә әверелеп моның кулына тәгәрәп килеп керә. Патша кызы көмеш күкәйне яулыгына төреп егеткә бирә дә әйтә:

– Мә, ди, бусын да син сакла инде, – ди.

Баралар-баралар, ди, болар, җиде тәүлек киткәч, барып җитәләр теге бакыр сарайга. Барып керәләр. Апалары белән елаша-елаша күрешәләр. Апалары сый-хөрмәт күрсәтә боларга. Бу сарайда өч көн, өч төн кунгач, болар, хәзерлегеп күреп, юлга чыгып китәләр. Бераз җир киткәч, кече сеңелләре бакыр сарайга таба карап кулъяулыгын селкеп җибәрә. Теге сарай бакыр күкәй булып йомарлана да тәгәрәп килеп керә кызның кулына. Патша кызы бакыр күкәйне яулыгына төреп егеткә бирә:

– Мә, ди, син сакла инде боларны, – ди. Таңбатыр бакыр күкәйне дә алып кесәсенә салып куя. Ярар. Китәләр болар. Бара-бара барып җитәләр теге кое төбенә. Кое төбенә җитү белән, Таңбатыр арканның очыннан тотып селкетә инде, тартып чыгарыгыз безне, дип белдерә. Иң элек олы апалары арканга тотына. Аны тартып чыгаралар. Ул килеп чыгу белән, Таңбатырның абыйлары үзара сугыша башлыйлар: Бу миңа да, бу миңа, – дип.

Патша кызы әйтә:

– Мин олы апалары, иң олыгызга булырмын, без өч кыз, өчебез өчегезгә булырбыз, сугышмагыз, – ди. Боларга арканны төшерергә куша. Арканны төшереп, уртанчы кызны тартып чыгаралар. Уртанчы кыз чыккач, болар тагын сугышырга тотыналар. Уртанчы кыз апасыннан матуррак икән.

Кызлар әйтәләр:

– Сез алай сугышмагыз, әле анда безне табып, дию кулыннан коткарган энегез бар. Безнең сеңлебез бар, аларны кое төбеннән тартып чыгарыгыз, – диләр.

Сугышып аргач, тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Аркан төшү белән, кыз әйтә:

– Башта сине тартып алсыннар, ди, үзең чыккач, син мине тартып чыгарырсың, югыйсә, алар сине тартып чыгармаслар, – ди.

Егет әйтә:

– Юк, ди, мин синең үзеңне генә монда җир астында калдыра алмыйм, башта син чык, аннан соң гына минем чыгу турында уйларга булыр, – ди.

Егет аркан очын элмәкләп бәйләп, кызны шуңа утыртып чыгарып җибәрә. Кызны тартып алалар да, матурлыгын күреп, яңадан сугыша башлыйлар болар. Кыз әйтә:

– Мин барыбер сезгә булмыйм, ди, сезнең энегез Таңбатыр белән сүз куештык бергә булырга, – ди. Кызлар өчәүләп тегеләрне кыстыйлар

Таңбатырны тартып чыгарырга. Ярар, тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Таңбатыр арканга ябышып чыгып җитәм генә дигәндә, абыйлары арканны кисеп җибәрәләр. Таңбатыр кое төбенә төшеп китә. Кызлар елашып калалар. Таңбатырның агалары юлга чыгарга җыена башлыйлар.

Ярар, инде без Таңбатырга килик. Таңбатыр, кое төбенә килеп төшкәч, бик озак вакытлар һушына килә алмый ята. Өч көн, өч төн ятканнан соң, бу әкрен генә кузгалып торып китә. Йөри-йөри бу, йөри торгач, тагын теге тычканга очрый. Тычкан моның каршысына килеп чыгып тилпенеп җибәрә дә кеше сурәтенә керә:

– Нихәл, Таңбатыр, тагын да бу хәлгә төшкәнсең икән син, – ди.

Таңбатыр әйтә:

– Шулай булды шул, ди, җир өстенә чыгарга юл эзләп йөрим дә, бер дә җай юк әле, — ди.

– Сиңа моннан чыгарга бу тирәдә бер хәйлә дә табып булмас, – ди тычкан. – Теге соңгы дию белән сугышкан җирдән узып китәргә тырышып кара, шул тирәдән узып китә алсаң, бер-бер хәл булыр, ди. Шул алтын күперне узгач, булыр бер биек тау, шул тауда йөрер ике кәҗә тәкәсе, ди. Ул кыр кәҗәләренең берсе ак, берсе кара булыр. Алар бик йөгерек булырлар, ди. Менә шул ак кәҗә тәкәсен тотып атлана алсаң, ул сине җир өстенә чыгарып куяр, ди. Ә кара кәҗә тәкәсен тотсаң, ул сине йә үтерер, йә тагын да тирәнгәрәк алып төшеп китәр, ди. Аны тота күрмә, – ди.

Шуннан Таңбатыр, тычканга рәхмәтләр әйтеп, әлеге юл белән китә. Атна китә, ай китә. Бара торгач барып җитә, ди, бу теге тауга. Кәҗә тәкәләрен эзләп табып, шуларның агын куып йөри башлый бу. Артыннан җитеп тотып алыйм гына дигәндә, кара кәҗә тәкәсе арага килә дә керә, тотарга җайсызлый. Күп йөри торгач, ак тәкәне эләктереп ала. Тотылгач, тәкә сорый инде моннан:

– Йә, егет, син мине тотарга бик тырыштың инде, ди, нинди теләгең бар иде соң? – ди.

– Теләгем шул, мин якты дөньяга чыгарга телим, – ди. Ак кәҗә тәкәсе әйтә:

– Мин сине якты дөньяга чыгарып җиткерә алмам анысы, шулай да чыгу юлына төшереп җибәрермен, теге ягын синең үзеңә эзләп табарга туры килер, – ди.

– Озак булырга туры килерме соң безгә? – ди егет.

– Байтак җир барасы булыр, ди, син менә миңа атлан, ди, йом күзеңне, мин әйтмичә ачма, – ди.

Шулай ди дә кыр кәҗәсе җилдереп китә, ди, егет көчкә генә тотынып утыра, ди, моның өстендә.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, теге кәҗә тәкәсе Таңбатырга әйтә:

– Ач күзеңне, – ди.

Күзен ачып җибәрсә, егет күрә: тирә-як яп-якты. Бик шатлана бу. Ак

тәкә кәҗәсе әйтә егеткә:

– Вакытыңны үткәрмә, ди, әнә тау битеннән бер юл китәр, шул юл белән барсаң югалмассың, – ди.

Шулай ди дә күздән дә югала.

Ярар, Таңбатыр китә шул юл белән. Бара-бара бу, бара торгач барып чыга бер ут ягылган урынга. Килеп көлне актарып карый, көл астыннан бер бөтен ипи чыга. Ипи өстенә Таңбатыр дип язылган була. Шуннан соң бу: Әһә, мин болар артыннан төшкәнмен икән, өйгә таба кайтам икән, – дип уйлый. Ипине алып ашый да шул урында ятып ял итеп ала. Торып китә бу, бара торгач янә килеп җитә бу ут ягылган урынга. Көлне актарып карый, моннан да бер бөтен ипи килеп чыга. Ипи пешәр-пешмәс кенә булып, җылы гына булып ята, ди. Ипине алып ашый да, ял итеп тә тормыйча, юлга чыга бу. Бара торгач, барып җитә егет кешеләр туктап, утлар ягып, ашлар пешереп утырган бер җиргә. Көлне актарып карый, моннан бер чи ипи чыга. Әле ипи диярлек тә түгел, камыр көе генә, пешеп тә җитмәгән. Әһә, ди, боларның артыннан җитеп киләм, ахры, – ди. Китә бу, ару-талуны да белми. Бара торгач, барып җитә урман буендагы аланлыкка. Бу барып җиткәндә, абыйлары ял итәргә туктап, шалашлар корып кына торалар икән. Бу килеп җитү белән, абыйлары аптыраашта калалар; кызлар елаша-елаша Таңбатырны каршы алып, аңа сый-хөрмәт күрсәтәләр. Кич җитү белән, өч агай-эне өч җиргә йокларга яталар. Таңбатыр йокыга китү белән, агалары үзара киңәшләшә, сөйләшә башлыйлар, ди. Олы абыйсы әйтә: Без моңа бик күп зыян эшләдек, ул барыбер бездән үчен алмый калмас, –ди. Уртанчы абыйсы әйтә: Яхшылык көтмә инде син аннан, ди, ничек кенә итеп булса да котылырга кирәк, – ди. Сөйләшеп сүз беркетәләр дә Таңбатыр яткан шалашның ишегенә аркылыга кылыч куялар үткен ягы белән палаткага каратып. Төн уртасы җиткәч, болар: Харап итәләр, талыйлар! – дип, яман тавыш белән акыра башлыйлар. Таңбатыр йокысыннан уянып, палаткадан йөгереп чыгыйм дигәндә, үткен кылычка килеп бәрелә дә ике аягын да өздерә. Инде бу кузгала да алмый, шып итеп утыра да шунда. Агалары әйберләрен алай-болай җыештыралар да кызларны алып кайтып китәләр. Таңбатырның хатыны инәлеп-инәлеп сорый абыйларыннан: Мине аның янында калдырыгыз, – дип, тегеләр, кызның аи-ваена карамыйча, аны көчләп алып кайтып китәләр.

Ярар, тегеләр өйләренә кайта торсыннар, без Таңбатыр янында калыйк. Таңбатыр ята тегеләрдән янып калган ут янында. Шуыша-шуыша йөреп, аннан-моннан утын-фәлән китерә бу, утны сүндерми тота, юкса эш начар бит.

Көннәрдән бер көнне, моннан ерак түгел генә бер җирдә бер кеше күренә. Бу кеше киекләр артыннан куып җитә, тик тота алмый, ә үзе тегермән ташы бәйләгән. Таңбатыр моны үзе янына чакырып ала. Сорый моннан:

– Син монда нишләп йөрисең? — ди.

— Мин сукыр кеше, ди, минем йөгереклектән көнләшеп, агаларым минем ике күземне сукырайттылар да шушы җирләргә китереп калдырып киттеләр, – ди.

– Аягыңа нәрсә бәйләдең соң син? – ди Таңбатыр.

– Күрәсең ич, бәйләмәсәм йөгерүем чамасызга китә, – ди. Болар шулай сөйләшә-сөйләшә танышалар да икесе

Бергәләп көн итәргә булалар. Ике-өч көннән соң болар янына өченче берәү килеп чыга. Бу кулсыз бер кеше икән, ди. Бу да абыйларыннан зыян күргән яшь егет икән, үзе чиксез-чамасыз көчле икән. Яши башлыйлар болар өчәүләп, бик дус булып. Сукыр белән кулсыз ашарга китерә, ә Таңбатыр ашны хәзерләп тора.

Көннәрдән бер көнне болар үзара сөйләшәләр: Безгә аш пешерүче табарга кирәк, – диләр. Китәләр болар шәһәр эзләп, аяксыз сукырга атлана, сукыр аргач, аяксызны кулсыз күтәреп йөртә. Шулай итеп, бик озак вакытлар йөри торгач, бер шәһәргә барып керәләр. Бөтен шәһәр халкы боларны карарга чыга. Шул халык арасында патша кызы да бар икән, ди. Ул арада булмый, болар шул патша кызын эләктереп алып та китәләр, ди. Куалар болар артыннан, кая ул теге йөгерек артыннан җитү, тегеләрне син күр дә, мин күр.

Кайтып җитә бу өч батыр үзләре торган җиргә. Кызга әйтәләр:

– Без сине үзебезнең сеңлебез кебек кенә тотарбыз. Син безгә аш хәзерләрсең, тик утны гына сүндермә, диләр. Бүтән эш юк сиңа, – диләр.

Болар һәркөнне өчесе дә җәнлек ауларга чыгып китәләр, кыз өйдә кала. Беркөнне шулай кыз ничектер йокыга китә дә уты сүнә. Уянып китә бу, утның сүнгәнлеген күреп, куркуга төшә: Агаларым ачуланырлар инде мине, – ди. Йөгереп чыга да, бер биек агач башына менеп, тирә-якларны карый. Брактаеракта, елтыр-елтыр итеп, тычкан күзе хәтле генә бер ут күренә. Шул утны эзләп китә бу кыз. Бара торгач, килеп җитә бу кечкенә генә бер җир өйгә. Бәләкәй генә ишеген ачып керә. Аның эчендә бер карчык утыра икән, ди. Бу убырлы карчык икән. Кыз килеп керү белән, убырлы карчык сорый кыздан:

– Йә, кызым, килдеңме, ди, нәрсә эзләп йөрисең? – ди.

– И әби, ди, утым сүнде, ут эзләргә дип чыккан идем, – ди.

– Ярар, кызым, мин сиңа ут бирермен, минем бер кешем дә юк, миңа бик күңелсез, иртәгә мин сиңа кунакка барырмын, икәү иркенләп кенә сөйләшеп утырырбыз, – ди.

– Ярар, әби, – ди кыз, – тик син ничек табарсың икән безне, – ди.

– Менә мин сиңа бер чиләк көл бирәм, ди, шул көлне үзең кайта торган юлның ике ягына сибә барырсың, мин шул юлдан, шәт, сезнең янга барып чыгармын, – ди карчык.

Кыз карчык биргән утны өенә алып кайтып, абыйлары кайтканчы аш-суны хәзерләп куя. Тегеләр ашап-эчеп ятып йоклыйлар да икенче көнне

тагын да ауга чыгып китәләр.

Абыйлары чыгып китү белән, теге карчык килеп керә бу кыз янына. Бераз утырганнан соң, карчык әйтә:

– Балакаем, ди, син минем башымны кара әле, – ди.

Кызның алдына ята, кыз моның башын караган вакытта, карчык кызның ботыннан канын суыра икән, ди. Бу карчык кызның канын суыра-суыра да торып кайтып китә. Шуннан соң бу карчык, кызның абыйлары юкта килеп, һәр көнне кызның канын суырып китә торган булган. Кыз көннән-көн ябыга, кибә барып, тора-бара коры сөяккә генә калган, ди. Абыйлары кызның ябыкканнан-ябыга баруын күреп:

– Сеңлем, соң син нигә болай ябыгасың, сагынасыңмы, чирлисеңме? – дип сорыйлар кыздан.

Кыз әйтә:

– Сагынмыйм да, чирләмим дә, тик болай гына ябыгам, – ди, яшерә инде болардан.

Тора-бара кыз бөтенләй йөри алмый башлый, аяксыз кала. Шуннан соң гына кыз әйтә абыйларына:

– Менә шулай-шулай, ди, утым сүнгәч, мин бер карчыктан ут алып кайткан идем, ди, шул карчык миңа ияләнде, һәр көнне килеп минем канымны суыра, – ди.

Абыйлары, үзара сөйләшеп, бу карчыкны тотып үтерергә булдылар. Шулай сөйләштеләр дә кыз янында сукырны калдырып киттеләр. Сукыр мич башына менеп утыра. Озак та үтми, карчык килеп керә дә, мич башында утырган сукырны күреп: Ә, бу сукыр мине сакларга калдымыни? – дип, сукырны мич башыннан өстерәп төшерә, аның аягын-кулын чәче белән бәйләп, үзе кызның канын суыра-суыра да чыгып китә.

Икенче көнне кыз янында калдыралар кулсызны. Карчык аны да шулай чәче белән бәйләп сала да, кызның алдына ятып, канын суырып китә.

Өченче көнне кыз янында Таңбатыр үзе кала. Кызга әйтә:

– Мин сәке астына кереп ятам, карчык бүген кайсысы калды дип сораса, алар бүген гел кайтмаслар, синнән курыктылар, калмадылар дип әйт, ди. Карчык алдыңа ятып, каныңны суыра башлагач кына, аның чәчен сәке ярыгыннан төшер, – ди.

Бер заманны карчык килеп керә, бер дә шикләнмичә, кыз алдына ятып, аның канын суыра башлый. Кыз карчыкның чәчен ярыктан сәке астына төшереп җибәрә. Таңбатыр, карчыкның чәчен тартып алып, сәке астындагы аркылы агачка бәйләп куя да, үзе сәке астыннан килеп чыгып, карчыкны ярырга тотына – кай җирең кычыта! Шул арада моның иптәшләре дә кайтып керәләр. Кулсыз тотына карчыкны типкәләргә, ә сукыр кай җиренә эләксә, шунда суга, ди. Карчык бөтенләй эштән чыга. Ялына башлый, ди, боларга:

– Кыйнамагыз, ди, күзсезне – күзле, аяксызны – аяклы, кулсызны –

куллы итәм, – ди. Шуннан болар карчыкны ант иттерәләр. Карчык ант итә. Иң элек йоттыралар, ди, болар кызны. Кызны йотып җибәрде дә китереп чыгара авызыннан, элеккедән дә матур, элеккедән дә чибәр кыз булып чыга, ди, бу. Аннан соң сукырны йоттыралар. Сукыр да ике күзле булып килеп чыга, ди. Аннары кулсызны йотып җибәрә, ди. Кулсыз ике куллы булып килеп чыга. Таңбатыр әйтә:

– Карагыз, сак булыгыз, ди, ул мине йотуын-йотар, кире чыгармас, ди. Мине чыгармыйча җибәрмәгез сез аны, – ди. Теге убырлы карчык Таңбатырны да йотып җибәрә. Көтәләр моны, көтәләр, килеп чыгар дип, карчык космый гына бит. Карчыкны кыйнап та карыйлар, чыгармый. Шуннан соң теге сукырдан күзле булган батыр кылычын ала да карчыкны тураклый башлый. Кискәләп бетерәләр моны, ә Таңбатыр юк. Карыйлар, бу карчыкның бер баш бармагы юк. Баш бармагын эзли башлыйлар, бу баш бармак карчыкның өенә таба китеп бара икән. Тотып алып ярып җибәрәләр – Таңбатыр килеп чыга, элеккедән дә матур, таза булып. Бу өч батыр бик шатланышып берничә көн бергә торалар да үз илләренә кайтырга булалар. Таңбатыр әйтә:

– Без сеңелкәйне үз иленә илтеп куйыйк башта, – ди. Бу кызга бик күп бүләкләр бирәләр дә, саубуллашып, теге

Бик шәп йөгерә торган батыр, кызны үзенә атландырып, бик тиз генә илтеп куя. Кызны илтеп кую белән, өч батыр дусларча саубуллашып, бергә-бергә торган чакларын онытмаска сүзләр куешып, һәрберсе үз илләренә кайтып китәләр.

Ярар. Таңбатыр, бик күп илләр үтеп, бик күп сулар кичеп, кайтып җитә үз иленә. Патша тора торган шәһәр читендәге бер карт белән бер карчыкка килеп керә. Таңбатыр әкрен-әкрен генә сораштыра башлый:

– Патшаның батырлары кайттымы, нәрсәләр алып кайттылар, патша кызларын таба алганнармы? – ди.

– Патша кызларын табып алып кайттылар, – ди карт, – тик батырларның берсе үлеп калган бугай, – ди.

– Туйлары булдымы соң? – ди.

– Юк әле, ди, менә бер көннән булырга тиеш, – ди. Шул сүзне ишетү белән, бу тиз генә бер вывеска чыгарып кадаклый: Мин, фәлән-фәлән итекче, патша кызлары туйда киярлек читек тегеп бирә алам, – дип яза. Патша кызлары моны ишетеп, теге картны эзләп киләләр дә өй алдына чакыртып чыгаралар.

– Бабай, син шулай-шулай дип әйткәнсең икән, син безгә иртәгә иртә беләнгә берәр пар читек тегеп җитештер, – диләр.

— Фәлән хак бирерсез, вакытына җитештерербез, – дип ышандырып алып калалар.

Патша кызлары китү белән, теге карт эшләргә утырмакчы була. Ә егет уйлап та карамый. Карт эләгермен дип курка башлый. Егет әйтә:

– Ят та йокла син, бабай, мин үзем тегеп куярмын, – ди. Карт белән

карчык ятып йоклый. Төн уртасы килеп җитү белән, егет, урамга чыгып, өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә, өчесеннән өч пар читек килә дә чыга. Егет боларны алып кайтып өстәл өстенә кертеп куя. Иртәнчәк карт тора. Егет әйтә:

– Менә, бабай, ди, мин читекләрне тектем, ди, алырга килсәләр, үзем тектем дип әйтерсең. Никадәр сорасалар да, мин теккәнне әйтмә, – ди.

Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Картны чакырып чыгаралар.

– Бабай, тектеңме? – диләр.

– Тектем, – ди.

– Йә, чыгар әле, – диләр.

Карт читекләрне чыгарып бирә.

– Менә карап карагыз, ошыймы сезгә? – ди.

Кызлар читекләрне алалар, бик ошый боларга.

– Моны кем текте? – дип сорыйлар.

– Үзем тектем, – ди карт.

Картка акчаны күп кенә итеп бирәләр. Шуннан соң тагын кайтарып сорыйлар болар:

– Йә, бабай, дөресен әйт, кем текте боларны? – диләр, моны кысалар инде. Теге һаман үзем тектем ди. Патша кызлары картка ышанмыйлар. Картка әйтәләр:

– Ярар, бабай, без эти белән сөйләшеп туйны чигерәбез, син андый һөнәрле оста булгач, безнең өчебезгә өч җөйсез күлмәк тегеп бир, күлмәкләр иртәгә өлгергән булсын, – диләр.

Карт тагын ышандырып алып кала инде. Алып калмас иде, Таңбатыр, ни эшләргә кушсалар да, алып кал, дип өйрәткән. Карт бу күлмәкләрне ничек кенә өлгертербез икән дип чәбәләнә. Егет әйтә:

– Син кайгырма, ят та йокла, бабай, – ди.

Төн уртасы җитү белән, шәһәр читенә чыга да теге өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә. Өч күкәйдән өч .күлмәк килеп чыга. Алып кайтып элеп куя бу күлмәкләрне. Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Карт күлмәкләрне чыгарып бирә. Патша кызлары шаккатып карап торалар да:

– Бу күлмәкләрне кем текте? – дип сорыйлар, шикләнәләр инде болар.

Карт әйтә:

– Үзем тектем, – ди.

Патша кызлары картка тиешле хакын бирәләр дә:

– Менә без сиңа тагын бер эш кушабыз, болай һөнәрле кеше булгач, син бу эшне дә эшләрсең, – диләр.

Карт нишләсен, теләсә-теләмәсә дә:

– Ярар, әйтеп карагыз, – ди. Патшаның олы кызы әйтә:

– Иртә белән шәһәр читендә бер бакыр сарай салынган булсын, – ди.

Уртанчы кызы әйтә:

– Көмеш сарай да салынган булсын, – ди. Кече кыз әйтә:

– Ике апама ике төрле сарай салынгач, минем өчен алтын сарай салынган булсын, – ди.

Карт каушап кала да соңыннан, теге егеткә ышанып: Ярар, тырышып карармын, – ди.

Кызлар кайтып китү белән, карт өйгә кереп әйтә:

– Бетте баш, патша кызлары безгә шундый-шундый эшләр кушып киттеләр, – ди. Үзе калтырана, күзләреннән яшьләр килә. – Нишләрбез икән инде, безнең бетүебез шушыдыр, – ди.

Егет әйтә:

– Кайгырма, бабай, ди, син ят та йокла, ди, мин үзем башкарып чыгармын, – ди.

Таңбатыр, төн уртасында чыгып, күкәйнең өчесен өч җиргә тәгәрәтеп җибәрә, өч җирдә өч сарай калкып чыга. Иртә белән егет бабайны уята:

– Кара әле, бабай, ди, өч җиргә өч сарай салдырып куйдым, – ди. Бабай бик шатлана, патшаның җәзасыннан котылабыз икән, ди.

Иртә белән патша кызлары иртүк бабай янына килеп җитәләр. Берсеннән-берсе матур өч сарайны күрү белән, болар. Таңбатырның кайтуын беләләр. Картны чакыртып чыгаралар да әйтәләр:

– Нихәл, бабай, без кушканны эшләдеңме? – диләр.

Бабай әйтә:

– Күрмисезмени, – ди.

– Үзең эшләдеңме, бабай? – диләр.

– Үзем булмыйча, – ди карт, һаман теге егетнең барлыгын сиздерәсе килми, әйтмәм дип сүз биргән бит.

Кызлар, ышанмыйча, көлешә-көлешә, бабайның сакалларын тарткалап карыйлар. Юк, йолкынмый. Аннары үзара сөйләшеп алалар да:

– Ярар инде, бабай, без сине гаепләмибез, син безгә бу сарайларны салдыручы егетнең үзен күрсәт инде, – диләр.

Бабай, теләсә-теләмәсә дә, егетне чакырып чыгара. Патша кызлары Таңбатыр белән елаша-елаша күрешәләр.

Таңбатырның кайту хәбәре патшага да ишетелә. Патша егетне үз янына чакыртып ала. Кызлар әйтәләр этиләренә:

– Безне дию кулыннан коткаручы менә шушы егет, агалары аңа бик каты зыян иттеләр, – диләр.

Шуннан соң патша, Таңбатырның көченнән куркып, кече кызын, теләсә-теләмәсә дә, аңа бирергә мәҗбүр була. Агаларыңны теләсә нишләт, үзең хөкем ит, – ди.

Таңбатыр агаларын үз янына чакыртып ала да әйтә:

– Сез миңа зур зыян эшләдегез, шулай да астырмыйм, кистермим мин сезне, тик бу шәһәрдән чыгып китегез, күземә күренмәгез, – ди.

Тегеләр башларын иеп чыгып китәләр. Таңбатыр, патшаның кече кызын хатынлыкка алып, кырык көн уен итеп, кырык көн туен иткәннән

соң, үзенең әти-әниләре янына кайтып тора башлый.

Хәзер дә бик шәп кенә яшиләр икән, ди, болар. Кичә бардым, бүген кайттым.

**Әкиятләрне анализлау өчен сораулар**:

1. Әкияттәге уңай һәм тискәре геройларны атагыз, аларга хас сыйфатларны күрсәтегез.
2. Төп геройга кемнәр ярдәмгә килә?
3. Әкияттә нинди тылсымлы предметлар бар, алар нинди вазифа башкара?
4. Вакыйгалар ничә мәртәбә кабатлана?
5. Кешегә яки предметка әверелә алу мотивы кайсы әкияттә күзәтелә?
6. Кайсы әкияттә йоту мотивы бар?
7. Әлеге әкиятләрнең уртаклыгы нәрсәләрдә чагылыш таба?

## Студентларның фольклор практикасы вакытында тупланган әкиятләр

### Килен пелән кайнә

**Информант:** Чапарова Гульчайра Рифкать кызы, 1937 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Хәбибуллина Наилә Наил кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы, Сөләйман авылы, 26.07.2006 г.

Элек-элек саманда пулган ди пер килен пелән кайнә. Алар пер-перзен сөймәгәннәр игән.

Пергөннө киленнең көнтә саен кайнәсе пелән орожонып ултырыу теңгәзенә тейепте, и ул китепте выратка кайнәсен үлтереү өцөн йат сурап. Выратка килгән дә игән:

– Миңә йат пирең, – тип сурапты.

–Нимәгә сиңә йат, – тип сурапты вырач.

–Мене, кайнәм пелән орожоноу теңкәгә тейте, польже цытайалмайым, - типте. Аннан зуң мыңа туктыр әйткән игән:

–Мин сиңә йат пирәмен, туликә син аны көндә заен кайнәңнең ажайтан ажына перәр жавала салып ултыр, но пы йатның пер секреты пар: ул пер атнаның эцентә генә тействаәт итәте и син атна пуена кәйнәңне көрмәтләп карарга тейеш, алай итмәсәң, пернимә килеп цыкмайты, – типте тә, киленгә йатны пирепте.

Ул өйгә кайтып, врач әйткән шигелле кыла пашлапты. Кәйнәзен көрмәтләп пашлапты, кәйнәзе тә мыңа ыспайлап атнаситца кыла пашлапты. Пы атнаның эцендә алар туслажып китептеләр. Аннан зуң киленнең кәйнәзен үлтергезе килмәй киткән игән. Игенце гөнне иртгән тороп ул тагын да выратка киткән игән:

–Мин инде кәйнәмне үлдергем килмәйте, перәй пративайәтийәгес йукмаң, - тип сураган игән.

–Мин сескә йат түгел, а витамин пиргән, кәйнәгескә ицимә пулмайты, –типте.

Мыны эжетеп килен мазайып өйөнә гайтып китепте. Аннан зуң килен блән кайнә перттә орошмай йәжәптеләр.

## Йес кунак

**Информант:** Азанова Айникамал Закир кызы ,1930 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Хәбибуллина Наилә Наил кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы, Сөләйман авылы, 26.07.2006 г.

Порон-порон саманда пулган пер корткайак. Аның паллары көн пулган, ә үзе ул йарлы пулган. Палларын үстерү өцөн ул көнө-төнө йөн иргән. Пер көннө төннә, йөн иреп ултырганта аның йанына йес кунак кергән.

Ул йес кунак йөн ирешәтән шайтан, йел пулган. Йөннө арттырышмак пелән иргән, если перәй йес кунакны арттырып китсә, ул аны үлдергән. Ул корткайакның йанына килеп утырган да, йөн ирә пашлаган. Корткайак мыны арттыра пашлаган игән. Аның урцыгы шытыртап кына утыраты игән, аннары корткайак курга пашлаган. Аннан суң:

–Син утырып тор, мин тышка цыгып киләйен – тип, тышга цыгып китепте. Тышга цыгып кәйлә уйлап керепте тә:

–Тышта пер өй көйәте, – типте.

Йес кунак сикереп торопты та:

–Вай, алайса пы минең өйөм, палларым көйәте гуй, – тип йөгөрөп цыгып китепте.

Алай итеп ул корткайак йес кунактан котолган игән.

## Аю белән кыз

**Информант:** Гилачева Гөлбану Закировна,1937 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Хәбибуллина Наилә Наил кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы, Сөләйман авылы, 26.07.2006 г.

Борын заманда яшәгән бер карчык, аның бер генә кызы булган. Бер вакыт ул кыз һәм егет төскә җиләк җыярга чыкканнар. Егет кызга әйткән, мин бу җирне кереп карап алаен дигән. Чыкса – кыз юк. Егет бер урынында катып калган, багырган-багырган ичкайда юк. Бер атна эстәп куйган, ләкин табалмаган һәм кайтып китмән, бу хәлне әнисенә сөйләп биргән. Әнисе җылый-җылый авылдан егетләрне җыеп, кызын эзләтергә җибәргән. Егет бер кырга чыккан һәм анда аю белән көрәшкән, ике көн шул аю белән көрәшкән, һәм өченче көндә мин бу аюны алдап пагаен дип уйлаган. Килгән кырга, тик көрәшмәгән, ә борылып атлап киткән һәм сиздерми генә аюның артыннын барган. Аю барган да, бер оры эчкә кереп

киткән, ә егет, сөйгән кызын көтеп утырган, агачка агынып. Иртәгелек ул аю ородан чыгып киткән, азык эзләргә. Егет керепакса – ул оры эчтә кыз утырган, ике бала кочаклап. Егет елаган, әйткән кайтарга, ә кыз болай чавап биргән: «Минең ирем аю, дигән. Мин аны ташлап ицкалай китмәем»,– дигән. Кайтып егет кызның әнисенә әйткән: «Ничәмә еллар буе эзләдем кызыңны, таптым»,– дигән. Һәм кызның әнисе авылдагы егетләрне җыеп, җибәргән кызына. Егет ялынган, «Босма тормышын»,– дигән. Болар киткәннәр дә, кызны апкилгәннәр. Егетләр барганында аю оры эчтә булмаган. Болар әйткәннәр: «Бәрбер дә авылга эзләп киләр кызны, шул вакытта килгәнендә без аны үлтерәрбез»,– дип. Аю оры эченә кергәч, балалары елап яткан һәм бу балаларының ике ботларын аерган да, кызны эзләп авылга киткән. Авылга җитеп килгәнендә, авылдагы кешеләр аны үтергәннәр, кыз елап килеп чыккан да, аюның күкрәгенә ятып елаган. Өйенә кереп киткән дә, асылып үлгән. Егет елаган кызның әнисенә: «Ник алай кызның тормышын бостың?!» – дип. Хәзер бит инде кызың да юк»,– дип әйткән егет. Кызның әнисе үксеп елап калган.

### Ятим кыс

**Язып алучы:** ТДСПА студенты Рабикова Лилия
Омск өлкәсе, Усть-Ишим районы, Ашеваны авылы, 1993 г.

Борн заман яшәгән бер ир катыныман, ирнең бер ятим калган кечкәсе бергә яшит игән. Акасы сәүдегер булат икән өйтән башка йерләргә чыгып китәт. Пы чыгып китсә, катыны өйтән чыгып китәт игән, пашка ирләрмән йөргеле. Кыс мыны белеп куят. Акасы кайткач, йиңгәсе кысның әйтәт:

–Кечегәң син юкта ирләрмән йөрит. Син өйтән чыгып китсәң йөрит, ә син өйтә булсаң – тып-тыныч. Әйтә аны яланга чыгарып ташлыйк, безне йат кылып йөремңсен.

Акасы моны эшетеп күнәт хатыныман. Икенче көн атны егеп торганта кечкәсе йөгереп чыгып өйтән сурыйт:

–Ака, кай китәсес, йиңгәм мән мине тә алмассысмы?

–Әйтә, алатык.

Кыс кийнеп чыгып ултырты арбага. Киттеләр. Яланга йетеп, урманга кереп киттеләр.Акасы атны туктатат, «Бес чия-чимер караппагыйк». Кыс та төшеп шыеш арасына кереп китәт. Ул кереп киткәч, акасы хатыныман арбага утырып увчатлар, кыс моны күреп еврәт арбага тотнып игән ите, акасы пармакларын чавып ият. Кыс сыктап калат. Көс еткәнче йөрит чия ашап. Бер көнне эшетәт көчек тавыш, агач башына чыгып утырат. Көчекләр аның есын сисәтләр тә, агач астына килеп өрәтләр. Потаклар арасынта кысны патша бала та дусларыман күрәтләр. Төшкәле эйтәтләр, кыс төшмәс. Әйтәт:

–Минең киемләрем пөткән, төшмәсмен.

Паллар сурыйтлар:

–Ничек син мондый хәлгә килтең?

Кыс кәпләп пирәт ничек суфичылыкка калганын. Кыс кәпләгәнче патша бала күс төшереп куят кысга. Сурыйт:

–Син миңа пуласыңма?

–Пулам, син элек инәң мән атаңтан кәпләш, алар риса булса, син миңа бер кат кием апкил. Суң мин төшермен.

Патша бала кыс качып китер тип көтәт дусларын. Өйтә эшетеп ней пулганын, нүнәләр суфи кызны килен кылгалы, бер кат кием ебәрәтләр. Кыс кийнеп төшәт. Кушлатлар. Бала бер елтҗан суңугуга китәт. Үс хатынына әйтәт:

–Минтән прәр яман хәбәр килсә эшәнмә, китеп калма. Прастан аларның кыс тувлат, матур кысчыгач пулат. Пы хәберне ясатлар, кысың тувлган тип. Еберетләр кат бер ирмән. Ул ир урнына катны көннең эчентә еткесәлми, кунат бер авылта ялгыз корткаякта. Ул корткаяк мунча ягып куйган игән, әйтәт:

–Балам, мунча төшеп чыгыр итәң, еклагалы әйбәт, йеңел булыр.

Алый әйткәнечә кереп китәт. Пы кереп киткәнемән, корткаяк каснып пашлат, катны табып угыт та, яңатан ясат: «Кысың тувылган, кеше тә түгел, хәйван та түгел, ний эшлик инте?»- тип. Катны яңатан урнына салып куят. Ир мунча төшеп, ятат йоклагалы, иртесемән юлга чыгат. Корткояк, тагы кил, тип чакрып калат. Аппарып катны еткесәт патша балага. Катны угыйт та өйтә ний булганын, ясат хат: «Я, кеше түгел, хайван түгел булса та, минең балам, өйгэ кайтсам, үсем әйтермен ний эшләгәле. Ич кой китеп калма» – тип ясат. Кат йөрткән ир апкитәт, ул ук өйгә киләт кунгалы. Корткаяк тагы мунча ягып куйган. Тагын мунча төшергөле кыйстыйт, пы кыстаганга ир күнеп, кереп китән мунчага. Ул кереп киткәнемән корткаяк катны табып угып китәт тагы. Яңатан кат ясат: «Миңа антый кыс кирәкмес, мин кайтканымчы юлың булмасын»,–тип.

Катны кыс угып йыйнып китәт киткәле. Моны пушатмаска итәтләр, ну кыс күнмәс. Кысчыгачын алып китәт. Тагы ялаңларта йөрит, кысы атлап биш яшь тулгынынчы. Бер көнне чыгатлар кысыман Ишен елганың йар буена. Намас уккалы вакыт йиткән. Кысына әйтеп, елга буена төшмә, тип, ултырат намаз уккалы. Намас угып торгонынта кысчыгачы суга төшөп китәт, инәсе күтәрлеп караппокса, кысы юк. Ишен буена төшөп, сыктыйт: «Уф, Аллам, ник син мине пылый кылаң, минең бер гонам юк бит». Алый әйтет тә, кулыман су эчкәле итәт, сутан кулын чыгарса, акасы чабып ийгән пармаклары үсеп куйган. Пы тагы сыктат: «И, алла, син мине масайтаң та, янтыраң та». Алый тип кенә өлгөрөт, кысы аръяктан бакырат:

– Әни, кил пыякка!

–Ий кысым! Ә ничек мин улякка чыгын, мин йөсөлмән куй?

–Әни, бисмилла иррахман ирахим, титә атла суга сиңа юл ачлыр. Әние алый ук кылат ничек кысы әйтте. Су ачлып юл булат, кысының янына чыгат. Суң икәве сыкташып авылга китәтләр. Авылта сурашатлар,

баерак кеше бармы, тип. Пыларга әйтәтләр: «Я пар мында пайлар, менә мынта гына яшитләр». Күргәсетләр кайта яшиткәннәрен. Кереп сразу таныт акасын, йиңгәсен. Алар тың баеп киткәннәр пулат, кысны танымаслар та. Йиңгәсе палтысын эшкә алат, тышта малуганы пирәт яшәгәле. Кыс пешеренәт. Бер йингәсе әйтәт: «Иртәгә патша киләт пескә, син тәмлерәк прәр нәрсе пешерерсен». Кыс пешеренәт тә, кысчыгачыман тирәс ячнта ултыратлар көтөп патша килүвен. Менә капкалар шат-шыт ачылты, яхшы атлдар алтыннан кутубка. Төшәт патша, кыс таныт ирен.

Патша керәт өйгә, мыңа тәмле ашлар утысатлар. Патша ашап ултыргач исенә килеп төшәт мындый ашларны пер саман ашаганын үсенең өйендө, пичәсен күсенә килтерәт. Йә йарыт ашанып алып патша ятат урынга әйтәт йомок кәпләгәле. «Мин пелмән куй йомоклар, ә менә минтә эшлиткән хатын кән пеләт, мин аны чакрыйн». Алый тип чыгып китәт. Кыска әйтәт патша килгәнен, йомок тыңлагысы килгәнен: «Син кен йомок пеләң куй, әйтә кереп кәпләпал». Кыс күнмәс: «Юк, минең яман йысымны ул йыслап ултыргысы юк». Йиңгәсе үсемнед үлгән палтысымның киемнәрен пирим ти, кереп китәт тә, апчыгат. Кыс үс киемнәренә кийнәттә керәт патшаның янына. Кыс кергәнемән патша пичәсен кыста таныт. «Я, − тит, ултыр кәплә нимә пеләң.” Кыс читәрәк ултыргалы итсә, патша әйтәт: «Юк, син минең яныма килеп ултыр». Кыс килеп ултырат та кәпләп пашлыйт. Кыс кәпләгәнен патша сывыкланып тыңлыйт, кәпләп пөткөч, әйтәт патша: «Инде үс тормышың турынта кәплә, күсләреңтән күрәм кән күрәчек күргәнең, әйтә кәплә».Кыс кәпләп пирәт кайта тувылганын, кайта яшәгенен, ничек йиңгәсе акасын алтап мыны яланга аппарып ташлаганын, ничек аны патша бала урманта очротоп кийөвгә алат, ничек ул кат ясат. «Юлыңта булмасын»,– тип әйтәп пирәт.

Патша суң кысның йеңгәсенең и кат йороткән кешенең башларын чабтырат. Үсенең пичәсен, кысын, пичәсенең акасын та апкайтып китәт. Алар касыр та яшитләр. Бәхетмән көн күрәтләр.

### «Татар халык әкиятләре» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары

1. Татар халык әкиятләрен өйрәнү тарихы.
2. Хайваннар турындагы әкиятләрнең иң популяр персонажлары.
3. Тылсымлы әкиятләрдәге сан символикасы.
4. Тылсымлы әкиятләрдәге серле предметлар.
5. Тылсымлы әкиятләрдәге мифик персонажлар.
6. Әкиятләрдә «кече туган» образы.
7. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә әхлак тәрбиясе.
8. Әкиятләрнең композициясе.
9. Тылсымлы әкиятләрнең поэтик үзенчәлекләре.
10. Урта мәктәптә халык әкиятләрен өйрәнү.

## ТЕМА № 6.РИВАЯТЬЛӘР ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАР

Галимнәр халык хикәяләрен икегә аерып тикшерәләр һәм борынгы ышанулар, дин белән бәйле магик яки илаһи характердагы чәчмә әсәрләрне **легенда** дип, ә хыял һәм ышанулар катнашкан булса да, тарихи характердагы һәм нигездә чынбарлык яткан эпик әсәрләрне **риваять** дип атарга тәкъдим итәләр.

Соңгы елларда күпчелек галимнәр әкият жанрына кермәгән әсәрләрне риваять (предание), легенда, мифологик хикәят (быличка), сөйләк (сказ, устный рассказ) дигән жанрларга бүлеп өйрәнү ягында торалар.

«Татар халык иҗаты» җыйнамасының С.Гыйләҗетдинов тарафынна төзелгән риваять һәм легендалар тупланган җыентыгында фольклор әсәрләренең зур күпчелеген риваятьләр тәшкил итә. Гарәпчәдән алынган «риваять» атамасы татар телендә ике мәгънәдә кулланыла. «Борынгылардан, буыннан буынга сөйләнелеп (күчеп) килгән хикәя, тарих» мәгънәсендә бу сүз К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдинов әсәрләрендә киң кулланыш тапкан.

Күпчелек галимнәр риваятьләрне, чыгышы белән истәлекләргә барып тоташа дип исәплиләр. Вакыт узу белән риваять телдән-телгә күчеп үзгәрә, соңрак хәтта бөтенләй онытылырга да мөмкин. Аларның халык хәтерендә саклану чорын тикшеренүчеләр 200-500 ел белән чиклиләр. Шуңа күрә төрле риваятьләрнең чынбарлыкка мөнәсәбәте дә төрлечә, кайберләрендә анахронизм, ягъни, бер чордагы вакыйгаларны икенче чорга күчереп сөйләү дә күзәтелә. Димәк, мондый әсәрләрне без төгәл беркетмә яисә тарихи елъязма сыйфатында кабул итә алмыйбыз. Хәер, риваять ул – күп очракта тарих түгел, бәлки тарихи вакыйгаларга, тарихи шәхесләрнең эшчәнлегенә халыкның мөнәсәбәте. Бары тик башка материаллар җитәрлек булмаган очракта гына риваятьләр тарихи чыганак буларак та файдаланылырга мөмкин.

Кайбер риваятьләрнең сюжетлары хәтта тулысынча уйдырмага корылган булырга мөмкин. Ләкин әкият, легенда, мифологик хикәятләрдән аермалы буларак, риваятьләрдәге уйдырма, гадәттә, реаль характерда була. Әкият, җыр, бәетләрдәге кебек үк, риваятьләрдә дә халык үзе кичергән вакыйгаларны сәнгатьчә гомумиләштереп бирә, моның өчен традицион фольклор мотивларыннан һәм образларыннан файдалана.

Композицияләре ягыннан риваятьләр, гадәттә, бик гади һәм кыска – бер эпизодлы гына булалар. Әкиятләргә хас традицион башламнар һәм бетемнәр аларда бөтенләй диярлек очрамый.

Тикшеренүчеләр, гадәттә, риваятьләрне тематик төркемнәргә бүлеп өйрәнәләр, ләкин фольклористикада гомум кабул ителгән бүленеш әлегә

юк. Г.Рәхим белән М.Васильев, мәсәлән, татар риваятьләрен унбишләп төркемгә бүләләр: дини, тарихи, кешеләр һәм тарихи вакыйгалар турында, таулар, чокырлар, авыллар турында, хайваннар турында, үсемлекләр, йолдызлар, табигать күренешләре, өрәкләр, җеннәр, мәрткә киткән кешеләр, дөнья йөзендә гизеп йөрүче кешеләр, тауларга кадакланган батырлар, ачлык, сугыш, революция һәм аның башлыклары турында риваятьләр

С.Гыйләҗетдинов, үзенең хезмәтләрендә риваятьләрне түбәндәге төркемнәргә бүлеп карый:

1) тарихи;

2) авылларның килеп чыгышлары турындагы;

3) топонимик;

4) көнкүреш риваятьләре.

**Тарихи риваятьләр** үзләренең тамырлары белән кешелек тарихының бик борынгы чорларына барып тоташалар һәм генетик яктан 160турыдан-туры ыру-кабилә хикәятләре белән бәйләнгәннәр. Ыру-кабилә хикәятләре кебек үк, алар халык аңында тарихнын мөһим вакыйгалары, күренекле шәхесләр турыңдагы мәгълүматларны беркетеп калу функциясен үтиләр һәм булган хәл дип кабул ителәләр. Әмма тарихка караш һәм сурәтләү формалары белән алар бер-берләреннән шактый аерылалар. Әгәр беренчеләре, ягъни ыру-кабилә хикәятләре, мифка һәм борынгы фикерләүгә корылган булса, риваятьләрне исә тарихи фактлар кызыксындыра. Башка төр риваятьләрдән аермалы буларак, тарихи риваятьләр халык язмышында, тарихында күренекле роль уйнаган вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышланган.

Татар тарихи риваятьләренең тематикасы бай. Алар халык үткән озын һәм катлаулы юлның мөһим этапларын яктырталар. Болгар чорына караган риваятьләр циклы болгар халкының килеп чыгышына багышланган «Болгар каласының корылуы турында» риваяте белән ачыла. Әсәрнең сюжеты бик борынгы һәм «һичшиксез Болгар чорыннан ук килә».

Болгар чорына караган «Янмый торган кыз», «Бүләрне яндыру». «Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәяте» һ. б. борынгы бабаларыбызның чит ил басып алучыларына каршы батырларча көрәшен тасвирлыйлар.

Казан шәһәрен салу һәм Казан белән бәйле риваятьләр циклына кергән әсәрләрдә елан белән көрәш мотивы шактый кызыклы. Татар халкы бу риваятьләрне, гадәттә, Казан шәһәрен яңа урынга күчереп салу уңае белән сөйли. Елан белән көрәш мотивы кергән мондый риваять беренче тапкыр XVI гасырда яшәгән билгесез рус авторының «Казан тарихы» дигән әсәрендә урын алган-. Соңрак чорларда Казанның төзелүенә багышланган риваятьләр күп тарихчыларның игътибарын үзенә җәлеп иткән. Риваятьләрдә күрсәтелгәнчә, яңа шәһәр өчен сайлап алынган урын еланнар белән тулы була. Еланнарны юк итүне бер сихерче уз өстенә ала (кайбер вариантларда ханның батыры}. Кыш көне еланнар яткан

урынга күп итеп салам өя дә. яз җиткәч, еланнар җыелган саламга ут төртә («Сихерче кыз», «Яңа Казан»).

Тарихи риваятьләр арасында татар крестьяннарының социаль һәм милли-колониаль изүгә каршы көрәшен чагылдырган әсәрләр зур урын алып тора. Бу төр риваятьләрдә хезмәт ияләренең гасырлар буе алып барган көрәш тарихының күп кенә мөһим эташтары чагылыш тапкан, дип әйтергә була. Дөрес, борынгы чорга караган риваятьләрнең саны күп түгел. Аларнын күләмнәре дә кечкенә. Әмма бу әсәрләрнең әһәмияте зурлыгында түгел, бәлки гасырлар буе. буыннан буынга тапшырылып, халык күңелендә сакланып калуларында. Циклга кергән риваятьләр арасында Пугачев восстаниесе турындагы әсәрләр аеруча игътибарга лаек. Алар арасында Бәхтияр Канкаев, Салават Юлаев, Рахманкол Дуслиев һ. б. шәхесләрнең көрәшен, Оренбургны камау, Казанны алу кебек мөһим вакыйгаларны тасвирлаган күләмле хикәяләр дә, восстаниечеләрнең хөкүмәт гаскәрләре белән сугышкан урыннары турында кыскача мәгълүмат кына бирә торганнары да бар.

Сыйнфый көрәш темасына багышланган татар риваятьләренең күбесенә тарихилык хас. Бу әсәрләрдә татар крестьяннары алып барган көрәшнең колониализмга каршы, сыйнфый характерда булуы тарихи дөреслек белән тасвирлана. Күп риваятьләрдә гади халыкның восстаниечеләргә ихтирамы, аларга ярдәм итүе сурәтләнә.

Тарихи риваятьләрдәге сюжетлар, образлар һәм күтәрелгән мәсьәләләр шул дәвердәге чынбарлык һәм чорның ихтыяҗлары белән бәйләнгән. Борынгы риваятьләрдә күбрәк халыкларның килеп чыгышы, ыру-кабилә башлыклары, гадәттән тыш көчкә ия булган мифик кешеләр турында сөйләнелсә, соңрак чорларда иҗат ителгән әсәрләрдә шәһәрләр төзелү, дәүләтләр барлыкка килү, ханнар, патшалар эшчәнлеге, чит ил басып алучыларына каршы көрәш төп урынны алып тора. Феодализмның соңгы дәверендә исә, риваятьләрнең үзәк герое – сыйнфый һәм милли азатлык өчен көрәшүче халык батырлары, яшәп килә торган стройга каршы чыгучы бунтарьлар-качкыннар һ.б.

Татар риваятьләренең күп өлешен (барлык әсәрләрнең яртысы диярлек) **авылларның килеп чыгышына багышланган риваятьләр** алып тора. Халык арасында һәм фәнни әдәбиятта аларны кайвакыт авыл тарихлары дип тә йөртәләр. Бу төр риваятьләр, гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утырган кешеләр, авыл, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә топонимик риваятьләргә хас күренеш.

Авыл тарихлары татар халкын тәшкил иткән этник төркемнәрнең төрле чорларда урнашу чикләрен, күченү күренешләрен һәм аның тарихи сәбәпләрен ачыклау өчен мөһим бер чыганак булып тора.

**Топонимик риваятьләр** кыска, гади хикәяләрдән гыйбарәт. Халык алар-да авыл, урман, кыр, тау, елга, чишмә һ. б. географик объект исемнәренең килеп чыгышын аңлатырга омтыла. Шуның белән алар башка төр риваятьләрдән азмы-күпме аерылалар, ләкин бу аерма шактый шартлы диясе килә. Кайбер тикшеренүчеләр, мәсәлән, «тарихи риваятьләр бер үк вакытта топонимик та була» дип исәплиләр.

**Көнкүреш риваятьләрендә**, кагыйдә буларак, гаилә тормышындагы вакыйгалар, егет белән кыз арасындагы мәхәббәт тарихлары («Тамерлан манарасы», «Шикәрле күл»), аерым кешеләрнең фаҗигале язмышлары («Налог өчен сатылган кызлар») тасвирлана. Мондый төр риваятьләрнең байтагы көйләр, җырлар, бәетләр белән органик рәвештә бәйләнгән.

**Легенда** − нигезендә фантастик образ яки күзаллау яткан халык хикәясе. Риваятьләрдән аермалы буларак, легенда эчтәлеге белән фантастик, ул үткән, хәзерге һәм киләчәк заман турында сөйли. Хыял, фантазия нәтиҗәсендә барлыкка килгән уйдырма, билгеле булганча, әкият сюжетында да мөһим урын тота. Ләкин аның функциясе башка: ул сәнгать чарасы булып хезмәт итә. Легенда һәм риваятьләрдә исә уйдырма, төрле вакыйгаларның, табигать күренешләренең һ.б. сәбәбен аңлату өчен кулланыла. Әкияттә уйдырма – «реаль тормыш, шулай ук кеше хыялларының үзенчәлекле чагылышы», ә легенда сюжеты күбрәк Коръән, Библия хикәяләре фантастикасына корылган.

Легендаларның эчтәлекләреннән күренгәнчә, аларнын кайберләре ислам дине тәгълиматы һәм дини китаплар аша таралган. Ләкин легендалар кешелек тарихының бик борынгы чорларында ук барлыкка килгән, ә ислам дине − чагыштырмача яна тәгълимат. Татар халкының ислам кабул итүе исә тагын да соңгырак чорларга карый. Шуңа күрә легендаларда халкыбызның борынгы ышанулары дини мотивлар белән үрелеп, алар белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Мәсәлән, болгарларның ислам кабул итүе турындагы легендада Болгарга килгән сәхабәләргә ханның авыру кызын терелтү өчен каен себеркесе кирәк була. Габдрахман сәхабә рәсүлулла биргән таякны җиргә кадый да намаз укый. Таяк утырткан җирдән су чыга, күз алдында каен себеркесе үсә («Айдархан һәм сәхабәләр»). Легендада халкыбызның борынгы исламга кадәргә ышануы буенча ук изге сыйфатларга ия саналган каен бу әсәрдә дини могҗиза ярдәмендә үсеп чыга (Габдрахман коесының булуы).

Татар легендаларының тематикасы бай һәм эчтәлеге күптөрле. Аларны:

1) космогоник;
2) зоогоник;
3) дини;

4) топонимик;
5) тарихи;
6) социаль-утопик;
7) көнкүреш легендаларына бүлеп карарга мөмкин.

Күк җисемнәре турындагы легендалар циклына кергән әсәрләрдән татар халкы арасында иң күп таралганы – «Ай өстендәге Зөһрә кыз». Легенда нигезендә айны илаһилаштыру, ул җирдәге бөтен әйберне үзенә тарта торган көчкә ия дигән борынгы ышану ята. Гомумән күккә, күк җисемнәренә табыну борынгы төркиләрнең ышануларында зур урын тоткан. Күк (тәңре) рухи тереклек чыганагы итеп каралган.

Үсемлекләр һәм хайваннар турындагы (зоогоник) легендаларның, сюжеты төрле кошлар, хайваннар, агачлар, үләннәр һ. б. барлыкка килүе һәм аерым төр үсемлекләргә яки тереклек ияләренә генә хас булган үзенчәлекләрнең килеп чыгышын аңлату (этнологик) мотивына корылган («Чыршы нигә мәнге яшел». «Карлыгачның койрыгы нигә аерылган?», «Кәккүк каян барлыкка килгән?» һ.б.). Тереклек ияләре турындагы легендалар, төп персонажлары белән хайваннар турындагы әкиятләрне хәтерләтәләр. Бу төр әсәрләрдә әкиятләргә хас традицион башламнар һәм бетемнәр дә очраштыргалый: «Борын-борын заманнарда, әле җир өстендә кешеләр бөтенләй юк вакытта, дөньяда яшәүче кошларның берсенең дә исеме булмаган, ди», яки «Шуннан бу кошларның беренчесен − сыерчык, икенчесен – тартар һәм өченчесен бытбылдык дип атап йөргә башлаганнар» («Кош исемнәре»).

Легендалар арасында хәзинәләр темасына багышланган әсәрләр үзенчәлекле урын алып тора. Бу хикәяләр җир астына күмелгән һәм кайчан да булса табылачак байлыклар турындагы ышануларга нигезләнгән. Тикшеренүчеләр күп халыкларнын хәзинәләр турындагы хикәяләре охшаш яисә бер үк төрле сюжетларга корылуын да ышануларның борынгылыгы белән аңлаталар. Бу хикәяләр, гадәттә, курганнар, тау куышлары, каберлекләр, күлләр һ.б. топонимнар белән бәйле рәвештә сөйләнәләр.

Көнкүреш вакыйгаларын тасвирлаган байтак легендаларның үзәгендә ана белән бала арасындагы («Сак-Сок», «Игелексез угыл», «Ана йөрәге» һ. б.), гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр («Килен тавы», «Катын таш тавы») тора. Мондый әсәрләрдә халыкның борынгы ышануына нигезләнгән каргау мотивы зур роль уйный. Каргау мотивы кешенең табигать белән мөнәсәбәтенә багышланган легендаларда да киң таралган («Иске Кама», «Түбән Орны су басу», «Уразлыны җир убу» һ.б.).

Тарихи шәхесләр турындагы легендалар шул ук төрдәге риваятьләрдән эчтәлекләренең үтә фантастик, гадәтгән тыш вакыйгаларга корылган булуы белән аерыла. Мәсәлән. Г.Кандалыйның бабасы Ибраһим бабай турындагы легенда. Кыш көне хатыны кура җиләге сорагач, Ибраһим бабай шунда ук идән астына төшә дә таягын җиргә

кадый. Шул моментта ук таяк кадаган җирдә кура җиләге куагы үсә дә башлый («Ибраһим бабай җиләге»). Кыш көне идән астында кура җиләге «үстерү» − татар легендаларында күп кабатланган мотивларның берсе («Яхъя хәзрәт», «Уразбәхи» һ. б.).

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

1. Риваять һәм легендаларга билгеләмә бирергә. Уртак һәм аермалы якларын аңлатырга
2. Риваять һәм легендаларны җыю һәм өйрәнү тарихы.
3. Болгар чорында иҗат ителгән риваятьләр һәм легендалар.
4. Казан ханлыгы чоры белән бәйле риваятьләр һәм легендалар.
5. Ана йөрәге легендасының эчтәлеге һәм тәрбияви әһәмияте.
6. Сезнең туган һәм яшәгән төбәк белән бәйле топонимик риваятьләрне табып алып килергә.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1. Бакиров М. Риаятьләр һәм легендалар / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б. Б. – 136-146.

2. Урманче Ф. Риваятьләр һәм легендалар / Ф.Урманче // Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2002.- Б. 149-151, 228-232,255-265.

3. Гыйләҗетдинов С. Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – Б. – 5-18.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Гыйләҗетдинов С. Крестьян чыгышлары турында татар тарихи риваятьләре // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан, 1984. – Б . 77- 92.

***Фольклор әсәрләре текстлары:***

1. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар (кереш мәкалә авторы С.Гыйләҗетдинов). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.

2. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.

3. Татар халык риваятьләре һәм легендалары (Төзүчесе С.Гыйләҗетдинов). – Казан: Раннур, 2000.

4. Болгар, Казан төшми телләрдән: Риваятьләр һәм легендалар. (Төзүчеләре - Мәхмүтов Х., Гыйләҗетдинов С. ). – Казан: Мәгариф, 2001.

## Студентларның фольклор практикасы вакытында тупланган риваятьләр һәм легендалар

### Сөләйман авылы турында

**Информант:** Азанова Айникамал Закир кызы, 1930 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Хәбибуллина Наилә Наил кызы
Түмән өлкәсе Вагай районы Сөләйман авылы, 26.07. 2006 г.

Песнең йакка уналтты шәйк килгән пулган мөсөлман тиненә үрәткәле. Кайткалы вакыт йеткәц араларынтагы пер шәйк калып калган. Ул үзенә озак урын эстәп йөрөгән өй салгалы тип. Суңыннан тапкан пер урын, анта өй залган, туликә йәжәйалмаган анда. Ул йер тыныцсыс пулган, ул игенце йертә өй залган, и анта та йәжәйалмаган. Суңыннан тагын пер йер тапкан, анта та өй залган. Менә анта ыспайлап йәжәп киткән. Ул кәсерге Әсгәп момагызның өй урыны пулаты. Аннан кежегара күцеп килгән, алар өй салып йәжәй пашлаганнар. Озак йәжәгән суң ул килгән шәйк үлгән. И авылны аның иземе пелән ататканнар Сөләймән тип. Аннан и калган авылның иземе Сөләймән пулып.

### Казан кайнаган йер

**Информант һәм язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Түмән өлкәсе, Вагай районы, Ишаир авылы, 1994ел.

Карагай аулыннан алыс түгел йертә Ишайыр (Вагай районы) аулынта «казан кайнаган йер» пулган игән. Пес моны көцкөнө цактан ук ишетеп килеп утыртык картлардан. Пергөннө менә мынтай кәл пулыпты.

Мыннан пайтак йыллар әүәл ике оста мулла ул пуйтан усып парганта, йуан пер казан, йар пуйта үләнлектә күрептеләр. Ул казан ицни паусыс эленеп торган сынны пулган. Ул уакытны пы ике мулла пер үгес асраганнар игән. Өц йәшенә үгес йетсә, астанага парып уачипкә суйгалы тип. Инте өц йәшенә йеткәц, пылар пер сал эшләп, үгесне һәм казанны алып «ык» йакка киткәле пулганнар. Мынта олло астана түгел, йарамайты мынта уачип кылу тип уйлаганнар. Пылар шул уакытны казанны салга тийәгәнтә, үгес әллә калай йугалып китепте. Шулай пулса та пы ике мулла казанны тийәп алганнан суң, «ык» йакка су пуйлап йулга цykkaннар игән. Пылар Ишайыр йылганы цыгып, пүрәнне усгац, Иртеш пуйлап «ык» якка перәй астананы эстәгәле тип парып утыргапта, әллә кайтан каты тулгын цыгып, пыларның салларын актарып ташлапты. Шул уакытны пыларның казаны та Иртешнең суынта патып китепте. Пы ике мулла үсләре тә сутан йарга нәсилә цыгып, кәлләре пөтөп Иртеш пуйта йоклап калыптылар. Шунта пер мулла мынтай төш күрепте: төшөнтә мыңа пашынта ак чалмалы, йәшел тайаклы пер карт йанына килеп, пылай тип әйтепте: «Сес йалгышлык эшләтегес, казанны урыныннан кусгамау кәрәк ите». Шуннан пы мулла уйангац, игенцесенә күргән төшөн пәрен кәпләп пирепте. Аннан

пылар икәү тә, инте нишләйвес тип торганта пыларның йаныннан пер кешәе усыпты. Шул ук кеше пыларга әйтепте: «Ник үгесегесне суймайсыс?» – тип, ә пылар әйтептеләр: «Пес йугалтывейгән аны,» – тип. Шуңа ул кеше: «Әнә казан утырган йанта үгесегес йөрите гуй», – тип әйтепте пыларга. Шуннан пылар парса, ней күсләре пелән күрсен, казан үс урынынта тораты, ә йанынта пыларның үгесе үлән ашап йөрите игән. Пыларның мыңа карап тороп исләре китепте: ницек алай суга паткан казан агым оторога килеп, үз урынынта, Ишайыр йылга пуйынта йаңатан килеп утырып куйиган, − тип. Аннан пылар ул ук йертә үгесне суйып, ул ук казанта пешереп, антагы пулган пөтөн кешегә ашатканнар игән. Менә шул көннән алып, пөгөнгө көннәргәцәк әле тә Ишайыр йылганың йар пуйынта «казан кайнаган йер» мынта тип йөртәтләр.

## Кыслар утраунта

**Информант:** Алиева Кәтирә Вахит кызы, 1937 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студентыЯхин Руслан
Омск өлкәсе, Усть-Ишим районы, Ашеваны авылы, 2006 ел.

Нейәү тигән йертән (Нейәү әүвәл ауыл ите) алыс түгел йертә Кыслар утрау тигән пейек йер пар. Ул пейек кашны кыслар итәкләре пелән ташып өйгән тип әйтәтләр. Пес аны, көцгенә цактан ук, алай ишетеп килтек.

Пы пулты унике йыл әүәл. Пергөнне пес күрше татар Сопра аулның Инәш корткайак пелән килеп утырганта, йулта караңкыга калтык. Шул уакытны пес икәүвес тә, әллә кайтан пер кысның сыктаган тауышын ишеттек. Пес икәүвес тә йак-йакка карапаксак та, ицкемне күрмәтек. Шуннан пиш-алты атлам атлауга пес Кыслар-утрау тигән йергә килеп цыктык. Карапаксак кашның пашынта пер кысны утлы шәм ошлап пасып торганын күртек. Шул уакытны икәүвес тә: «Әстәгевиралла, әстәгевиралла», – тейеп, угына пашлатык. Чәнки икәүвес тә аннан ары ицнимә пашка нимәне угына пелмәйвес. Шулай пулса та ул кыс әллә калай йугалып китте. Пес ул көнне акшам нәсилә өйгә кайттык. Ә ике йыл шүвәл июнь айынта, тойаркалар тагынта Кыслар утраунта пер кысның кулына шәм ошлап торганын күрептеләр. Ә менә пы усган йәйне пастук палама шәм ошлап торган ике кыс өсәрә пулыпты, кыслар-утрау тигән йертә кайуаннарын эстәп йөргәнтә. Шуннан ул тис генә атын котортоп кайтып китепте. Ә август айынта песнең аулның ир кешеләре косокка парганта, кыслар-утраута пер кыс кулынта ут ошлап, пыларга оторо тороп куйыпты. Шул көнне пар ир кеше пер паш косоксос өйләренә кайтыпты. Менә мынтай кәлләр пулган ите.

## Татарка ауылы турынта

**Информант: Юсупов Айтмөхәммәт**
**Язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Түмән өлкәсе Вагай районы Йышайыр авылы, 1994

Пы йердә пер татар ауыл әүәл пулган икән. Пергөннө урыслар килеп, ул ауылны көйтергәннәр һәм калыкны антагы пәрен кырганнар имеш. Ул ауылта пер 13 йәшлек кыс кына йәшенеп йатып калыпты. Ул үсе генә имеш анта төтен арата йөргәндә, шул уакытта өц урыс усып парган икән. Аннан аларның перәүе пы кысны цакырыпты, ну, тулькә ул ицнимә аңламапты. Шыуннан ул кыс алардан кацып йылга йакка йөгерепте. Ул татар кыс йылга йанга килгәндә, урысларның килгәнен күреп, тере килеш ул урысларга тотолмаек тип, пиек йартан сыуга сикерепте. Шыулай итеп, кыскарецка, ул патып үлепте. Менә шыуның өцөн ауылга Татарка тиген исем пирелгәнте тип, кәпләте Әйтмөхәммәт абый Юсупов. Ул кысныф алылап калык йөртәте кәсертә ауылны Татарка тип.

## Ишмән-каш турында

**Информант:** Мөкътәсимов Әптәлмокый Мөкътәсим улы
**Язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Түмән өлкәсе Вагай районы Йышайыр авылы, 1994

Әүәл мынта йул ике цакырымга әйләнец пулган. Йөсләгән йыл мыннан әүәл Ишмән тигән кеше пы турата Иртешнең пийек кашын, ат йөргелек итеп перүсе эшләп цыгыпты. Шуннан суң пайтак уакытлар ул үсе генә пы йултан ат пелән йөрепте. Кешеләрнең мыңа исләре китәте игән «Пестән суң китеп, алттан ницек киләте игән? Ә пит йулта та куып узганын күрмәйпес» – тителәр игән.

Пергөннө аратан перәү, атай пашкалартан суңка калып, көтөптө мыны аргасыннан ируастан гына атын әйтәп. Игенце көннө аннары ул пашгаларга пылай тип әйтепте: «Әйтән, Ишмән эшләгән каә йагы пелән парайык!» – тип, «Алай цыннан та йуык игән», – тип. Шул көннән алып, перәйе сураса, әйтәтләр игән: «Ишмән каш йагы пелән паравыс!» – тип. Аннан суң пы пуйта ауыл та парлыкка килепте. Ауылга исемне тә Ишмән каш тип пиргәннәр игән. Ауылның игенце йагынта Иртешнең Ишмән кашы тигән пер йер пар.

## Кан-күлцәк исеме кайдан?

**Информант:** Алиева Кәтирә Вахит кызы, 1924 елгы
**Язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Омск өлкәсе, Усть-Ишим районы
Ашеваны авылы, 10.07.1993ел

Мыннан ун цагырым йертә Йәйләү тигән ауыл пар. Аны игенцеләй Телгәле тип йөртәтләр. Аның йанынта Кан-күлцәк тейгән пер кецкенә генә күл пар. Ул, ник алай тип аталган игән сурау мине күптәннән

кызыксынтырты. Менә шуның өцөн пөгөн мин Кәтирә апайга пы сурауны пиртем. Менә ул миңа тувәнтәге нимәләрне кәпләте.

Мыннан пайтак йыллар әүшл мынта өц әүлиә килепте. Дин өцөн парган сугышларта алар өцөсө тә пы күл йанынта йараланганнар игән. Ул өц йаралы әүлиәләрнең арасынта перәү кыс пулган имеш. Ул аларның йараларын йуып пы күлнең суынта, аннан ул ук күлтән алып, пертөрлө үлән пелән пыларның әм үсенең йарасын пәйләпте. Пы өц әүлиә атка менеп, пашга йакка киткәннән суң, пашка кешеләр пы пуйга килгәннәр игән. ул кешеләр карасалар күлнең суы канга ошап, кыскылт тәстә күренгән игән. Аннан алар өсәрә пулган кешеләргә әйтептеләр: «Анта пер көцгөнә генә күлцәк пар, аның суы канга ошайты»,– тип. Аннан аны Канлы күлцәк, ә суңыннан пара-пара Кан-күлцәк тигән исем йатып калыпты. Пөгөнгө көнгәцәк ул көцкөнә генә күлцегәцне Кан-күлцәк тип йөртәтләр.

## Кыслар тора (шәһәре) һәм аларның асатлыкка омтолуы

**Информант һәм язып алучы:** Әсхәт Ниязов

Төмән өлкәсе, Вагай районы, Ишаир авылы, 1994 ел.

Пэснэң йакларта пайтак йэрлэртэ кыслар тора тигэн йэрлэр пар. Мэсэлэн, Йышайыр ауылының уа өстөнтэ Ныршы пүрэн өстөнтэ Йалан йар, Йыгайыр, Сэмтэ, Иксинэр ауыллары йанынта, Кайнаул ауылы йанынта Кырык кыс уа тигэн ауыл йанынта Өц кыс тип аталган урыннар пар. Кайтан килэп цыккан игэн мынтай исэмнэр?/

Әлэгэцэ шунтай сорауларга чауап табалмагац, мин күршэ өлкэгэй улга цыктым. Кэшэлэртэн сурашатыгац, мин аларның үсэнэ карата пэр таригы пар икэнэн пэлтэм. Аның турынта мин пөгөн йасгалы пултым.

Мыннан кэп йыллар әүэл пэснэң йэрлэртэ Сэвэр канлыгы пулган. Аның эр ауыллартан коллокка алынган кыслары пулган. Калык паш күтэрмэсэн өцөн кан эрпэр аултан пэрэр пайырак кэшэнэң кысын коллокка алган. Аларны эшлэтмэгэннэр, тик күңэл ацкалы гына ошлаганнар. Аларны канның кэшэлэрэ көнө-төнө каравыллаганнар. Лэкин иргэнлэктэ ирэктэ үсэп пуй йэткэн кысларның кол пуласылары килмэгэн.

Пэргөннө өцйөс кыс каравыллыларны үлтэрэп уа йакка кацканнар. Туган өйлэрэнэ кайтсалар, аларны тотоп йаңатан алыуларын аңлап, кыслар төстэ өцйөс кэшэтэн торган атрэт төсөп, уаның пэйэк йэрлэрэнтэ тукталалар. Кыслар сайлаганнар антай йэрлэрнэ, пэр йактан пэйэк йар, э игэнцэ йактан кэшэ цыгалмаслык шарлап килэп агып утырган йылгалы йэрлэрне.

Кан үсэнэң сугышцыларына кысларын тотоп алгалы тип пойрык пиргэн. Шуннан кысларын аргаларыннан куып цыкканнар пылар. Йыгайыр ауылы йанынта кысларны куып йэткэннэр. Кысларның кайпэрлэрэ пэйэк йартан аларның өстөнэ агацлар йомарлаганнар, э икэнцэлэрэ санайтан атканнар. Йыгайыр аулы йанынта кыслар сикэр тигэн

йэртә уникэ кыс үлгән. Ауыл кэшэләрэ аларны анта ук күмгәннәр. Калганнары агацлартан саллар йасап, кайпэрсэ кимәләр пэлән, төннө икэнцэ йэргә кицэп киткәннәр.

Айлар пуйына сусылган пы сугышларта әшгәрә кән кыслар үлгән. Кысларның кайпэрсэ Иртэш аша кицкән пулган. Йаланйар аулы турысынта, ләкин сасатага эләгэп тагын та йэтэ кыс үлгән, ә калганнары сугыша -сугыша кирэ поролоп киткәннәр. Кәсәр тә Йаланйар аулы йанынта Кыслар тора тигән йэр пар. Анта йэтэ кыс күмэлгән. Йаралы кысларны ауыл калыгы кайпэрсэн тэрэлтэп, айакка пастырган. Кайпэр ауыллартан төннәрэн кысларга йәшэртэн йуллар пэлән асык ташыганнар.

Пэргөннө төннә Йышайыр аулыннан икэ кэшэ асык алып парганта каравылга эләгэп киткәннәр. Аларның шунта ук пашларын цапканнар. Аларның исэмнәрэ тә пилгэлэ, пэрсэ Кәйтәр, ә игэнцэсэ Кәнәви. Аларны сыйаратка күмгэлэ пойормаганнар. Ауылның калгы аларның икәүэ тә аултан икэ цагырым төстэгэ Көцөгәннэ тигән йэртә күмгәннәр.

Ә Кайнауыл ауылы йаныннан усганта олло атрәткә өсәрә пулып, тагын та кырык кыс үлгән. Аларны шунта ук күмгәннәр. Уа тигән ауыл йанынта өц кыс Иртэш аша расвэткага цыккан пулган. Ләкин шунта сасатага эләгэп өцәүэ тә үлгән. Өц кыс тигән йэртән усганта пар кэшэ көмөш акца ташлап усаты. Мин тә шулай эшләтэм. Шул өц йөс кысның арасыннан икәүэнэң исэмнәрэн тә пэлтэм пэрсэ Салига пиби, игэнцэсэ Гафифә пиби алар икәүэ тә Саургац ауылта күмэлгәннәр.

Пара-пара кысларның кәлләрэ кыйынлаша. Исән калган кысларны Иксинэр ауылы йанынта төрлө йактан камап алганнар. Шул уакытны кыслар пэрәүэ тә исән килэш пирэлмәгән. Шунта парысы та кырылып пөтөп үләләр.

Пы лэгэнтата Сэбэр татар калыгының төрлө коллоктан асат пулу, пәйсэслэк алу кыйалы, ирэклэ рухы йәшәйтэ.

Кыйал йәшәргә пулышаты, лэгэнта тормышка ашмас кыйал турытагы йыр кэбэк.

Пы кәлләр кайсы канлык уакытынта пулганын төгәл әйтэп пулмайты.

Шунтай кысыклы лэгэнталарны кэшэләртән йыйып алганнан суң мин шал уакыттагы татар кысларының шунтай патырлыгына исэм китэп, чиксэс соклантым. Шул уакытны пөгөнгө көнтәүсэмнэң татар пулуыма пик корурлантым. Шуннан пэр йэртә түсэп торалмайын. Кыслар тора тигән йэргә йөгөрөп цыгып, «Мин тә татар кэшэсэ пулам!» тип пөтөн көцөмә кыцкырасым килтэ. Ләкин ицнимә тә әйтә алматым, тик күсләрэмнән йәшләр гэнә туктаусыс акты.

## Булыга авылы турында

**Информант:** Нурмөхәмәтов Моклетдин
**Язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Төмән өлкәсе Вагай районы
Аксурка авылы, 14.05.1994ел

Мыннан пайтак йыллар әүәл пы ауыл Өц өйле тип аталган имеш. Шул уакытны ул өйләртә татар угатник та рываклар йәшәгәннәр имеш.

Пергөннө пы йергә бер урыс килепте. Урыс мынтагы пер угатниктан йәшәгәле тип йер сурапты.

Татар кеше төгө урыска: «Ә синең йерне алышып алгалы перәй нимәң парма?» – тип. Шуңа ул урыс пер икмәк күрсәтепте: «На булку», – типте. Шуннан суң осак та пулмаган пы йакка пашга урыслар та килә пашлаган. Аларның сурауына әйтепте: «Булка икмәккә алышып алтым», – тип. Калганнары та аларның алай эшләпте. Шул уакытларны пашга угатниклар пы пуйтан парганта сураптылар: «Пы нейтәй ауыл?» – тип. Пыларга өсәрә пулган кеше урыс пулганга рәтләп ул та аңламапты. «Булка» тип кенә әйтепте. Төгө татар угатниклар шуннан суң, пы ауылның исеме шулай пулыр тип уйлаптылар. Аннан суң ауыл тора-пара Булыга пулып киткәнте. Кәсер тә йылганы Булыга тип йөртәтләр.

Инте пөгөнгө көнтә аны легенда итеп кенә кәпләйтеләр.

## Сопра ауылы турынта

**Информант һәм язып алучы:** Әсхәт Ниязов
Төмән өлкәсе, Вагай районы, Ишаир авылы, 1994 ел.

Пэснэң киң сэвэр йэрэнтэ татар халыкның төрлө-төрлө таригы уакыйгалары ривайэтләрэ әм бәэтләрэ сакланаты. Кэсэр шуларның пэрәүэ турынта йасамын.

Мыннан пайтак йыллар әүәл кэттэ эллә ницә касырлар пулыр пы йэргэ Сопра исэмлэ кэшэ килгэн игэн. Ул пы йэрнэ эшкэрэ йаратып үсэ гэнэ пулса та йәшәй пашлапты. Аннан тора пара аны пы йэрнэң кучасы тип уйлаганнар. мыннан суң килгэн кэшэлэр. Шуннан суң пашка татар кэшэлэр тэ мынта йәшәй пашлаптыкилэп мыннан рисалык сураганнан суң. Мының ул уакытта интэ үсэнэң йэрлэрнэ кайваннары пулган, ну ат интэ, пар татар кэшэлэргэ пулган тилэр. Сопра тигэн кэшэ ухатага йөрүнэ йараткан пулган, эм палык антыган игэн. Шуннан пашка кэшэлэр Сопра тигэн кэшэнэ пытирэктэгэ йэрлэргэ пашлык кылып сайлаганнар игэн.

Пэргөннө пыйэргэ пэр урыс килэптэ.Ул Сопратан йэр үсэнэ сурапты. Сопра аннан моңа эйтэптэ: «Нимэ пирэп аласың, пэрэй нимэң парма синэң? Йэрнэ түлэп алгалы» тип. Урысның пэр үгэснэң тирэсэннэн пашка ицнимэсэ пулмапты, түлэп алгалы. Шуннан Сопра уйлап торып алгац эйтэптэ: «Энэ ул үгэс тирэ кэтлэ йэр пирэм сиңа, ну мынта түгэл, Иртэшнэң игэнцэ йагынта йарайтыма. Әгэр тэ күнмэсэң минэң эйтүэмэ, кайтан килтэң, анта кит, мин синэ ошламайым» –тип эйтэптэ. Шуннан

урыс күнэптэ: «Йарайты, пулаты миңа ул кәтлэ йэр»– тип. Сопра үсэ ухатага китэптэ, ә килсә, урыс үгэс тирэн пилпау шигэллэ кисэп түгәрәкләп, мынэн пайтак осонлыкта килэп цыгыпты. Сопра мыны күрэп: «Пы нимәгә тирэнэ кистэң?» тип әйтэптэ. Ә пы урыс шуннан мыңа әйтэпт: «Минэ тирэ мин ул тирэнэ түгәрәкләп пилпау шигэллэ кистэм, ыштоб йэтсэн пы тирэ миңа көцкөнә пулса та өй салгалы, әлэ аның йанына пакца кылгалы. Пылай тип урыс әйткәц, Сопра пар көцөнә шагараклап көлөптэ. Аның алай көлүэннән кэттә урманнар йаңкырап утырыпты. Шуңа карап урыс кыйынсынып утырыпты, пирэрмә, әллә йукма, тип. Шуннан суң Сопра көлөп туйгац, әйтэптэ: «Йарайты, пашың эшләптэ, Иртэшнэң арйагынта ни кәтлэ тәләйсэң, ул кәтлэ ал йэрнэ, йәшә»,–тип. Шуннан суң интэ ул йөртә пашка урыслар та килэп йәшәй пашлаптылар. Кәсэр ул ауылны Олло сопра тип әйтәтләр. Ә Сопра тигән кэшэ йәшәгән йэрнэ Татар сопра тип йөртәтэләр. Олло Сопрата кәсэр урыс пэлән татарлар аралаш йәшәйтэләр, ә Татар Сопрата татарлар гына йәшәйтә. Пыикэ Сопраны өц цакрым ара пэлән Иртэш йылгасы айырып тораты. Ауылларның исэмэ Сопра тигән пәлки шуннан килэп цыкканты.


## Изге урыннар

**Информант һәм язып алучы**:
ФһСИ студенты Азат Хәлилов
Татарстан Республикасы Биектау районында
Әйшә авылы, 2011 ел

Безнең якларда Мулла Хаҗи дип аталган бер изге урын бар. Аны тагын Изгеләр урыны дип тә йөртәләр. Тарихы болайрак: борынгы Казан каласында Хаҗимулла исемле гаскәр башлыгы булган, ул бик күп яхшылыклар эшләгән, шуңа күрә аны әүлиягә тиңләгәннәр. Хаҗимулланың Гайшәбикә исемле хатыны була. Хаҗимулла иртә үлеп китә. Аны тау өстенә алып менеп җирлиләр. Хатыны Гайшәбикә кабергә килеп зиярәт кыла торган булган. Гайшәбикә озак тормый, үлеп китә. Аны Хаҗимулла кабереннән ике чакрым ерак җиргә күмәләр.



Хаҗимулла кабере тирәсендә чишмәләр бәреп чыга, ул чишмәләрнең сулары шифа китерә. Ә Гайшәбикә абыстай күмелгән җирдә авыл төзелә һәм исеменә охшатып Әйшә дип атала башлый. Үзең беләсен инде, анда бик ераклардан да киләләр, дога кылып , садака биреп, шифалы су алып китәләр. Эшеңне бетергәч, шундагы каберләр тирәли “бисмилла” әйтеп, 7 тапкыр әйләнергә кирәк. Хәзер анда мәчет салдылар.



Елга аръягында изге кабер бар әле. Анда Бибигайшә исемле бер әби күмелгән, теше сызлап үлгән дип сөйлиләр бугай. Башта чардуганы агач булган иде. Бер 15 ел элек микән, Клачыдан Хәмит исемле бер абый тау башыннан трактор белән төшеп әйләнгән. Исән калган, адаранган булгандыр инде, тимер чардуган куйдырган. Шул кабергә барып, догалар кылып садака куялар.

### «Риваятьләр һәм легендалар» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары

1. Болгар чоры риваятьләре һәм легендалары.
2. Казан шәһәре салыну белән бәйле риваятьләр һәм легендалар.
3. Пугачев исеме белән бәйле риваятьләр.
4. Сезнең төбәктә иҗат ителгән топонимик риваятьләр.
5. Зоогоник легендалар.
6. Көнкүреш легендаларының тематикасы.

## ТЕМА № 7. МӘЗӘКЛӘР

**Т**атар халык иҗатында мәзәк жанры шактый тирәнтен өйрәнелгән өлкә булып санала. Әлеге жанрны өйрәнүгә Каюм Насыйри, Хәмит Ярми, Абдулла Әхмәт, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Альберт Яхин, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов һ.б. гаять зур өлеш керткән.

Татар халык иҗаты әсәрләрен жанр ягыннан төркемләү буенча беренче тәҗрибәләр К.Насыйри исеме белән бәйле. XX йөз башында татар фольклорының жанрлар составын билгеләү мәсьәләсе инде күп кенә күренекле әдипләрнең игътибарын җәлеп итә. Г.Ибраһимов халык әдәбиятын “эчке хосусиятләре, мәгънә вә мөндәриҗә (эчтәлек) ягыннан” җиде төргә бүлә (бәетләр, җырлар, әкиятләр, мәкальләр, табышмаклар, такмаклар, такмазалар). Тагын Хуҗа Бәдигый, Габдрахман Сәгъди, Гали Рәхим тарафыннан эшләнгән классификацияләр бар. Әмма боларның берсендә дә әле мәзәк жанры телгә алынмый. Бары тик 1926 елда гына М.Васильев һәм Г.Рәхим төзегән «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма»да мәзәк беренче мәртәбә мөстәкыйль жанр итеп күрсәтелә. Аңа: «Көлкеле характердагы бик кыска хикәятләргә анекдот (ләтифә) диләр», - дигән билгеләмә дә биреп үтелә.

Узган гасырның 60нчы елларына кадәр жанр турында бер генә махсус тикшеренү дә күренми. Г.Бәшировның «Туксан тугыз мәзәк» (Казан, 1960) һәм «Мең дә бер мәзәк» (Казан, 1963) җыентыкларында урнаштырылган «Мәзәк турында бер-ике сүз», «Мәзәк ничек туган?» исемле мәкаләләрдә мәзәкнең жанрлык билгеләре, аның барлыкка килүе, идея-эстетик кыйммәте турында әһәмиятле фикерләр әйтелде. Аннан соңгы елларда жанрны өйрәнүгә Ф.Хатипов тарафыннан зур гына өлеш кертелде. Аның «Эпик жанрлар» монографиясендә (Казан, 1973) «Мәзәк жанры турында» дигән аерым бүлек бирелә. Шушы ук китапның «Новелла. Хикәя» исемле бүлегендә мәзәк белән новелланың үзара бәйләнеше анализлана. 1979 нчы елда 12 томлык «Татар халык иҗаты» җыйнамасының бер томы буларак «Мәзәкләр» томы басыла. Томны төзүчеләр Хуҗиәхмәт Мәхмүтов һәм Айсылу Садыйковалар кереш мәкаләдә мәзәкләрне өйрәнүнең тарихы, жанрның төрле хасиятләре турында бик бай мәгълүмат бирәләр.

Татар халык авыз иҗатында мәзәк жанры төп сыйфатлары белән рус фольклорындагы анекдотка якын тора. Анекдотка «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә А.Әхмәдуллин түбәндәге билгеләмә биргән: «Анекдот- (грекча –«басылмаган», «сөйләм жанры» мәгънәсен аңлата) – элегрәк заманнарда нинди дә булса тарихи шәхес тормышындагы кызыкла вакыйгаларны хикәяләү, мәзәк. XIX гасыр урталарыннан, анекдот дип, көтелмәгән ахыры булган кыска көлке хикәяләргә әйтә башлыйлар. Татар халык иҗаты мәзәкләргә бай. Мәзәкләрнең жанр үзенчәлеге итеп башта

бирелгән тезистагы мәгънәне киресенә әйләндерү исәпләнә».[Әхмәдуллин, 1990:16]. Грек теленнән алынган «анекдот» сүзе башка күп кенә халыклар фольклорындада кабул ителгән һәм үзенә күрә бер интернациональ атама булып әверелгән. Шуның белән бергә, бу жанрның җирле, башкача әйтсәк, аерым халыкта гына кулланыла торган атамалары да бар. Мәсәлән, украинлылар анекдотны «усмешка», башкортлар «көләмәс», төркмәннәр «шорта сөз» дип йөртәләр [Мәхмүтов, 1979:11].

Революциягә кадәр татар матбугатында мәзәкләр «хикәят» исеме белән басылганнар. Шулай ук «ләтифа» һәм «мәзәк» (мэзах) атамалары да киң кулланылган. Гарәп теленнән кергән бу сүзләр бездә «көлкеле кыска хикәя» дигән мәгънәдә йөргәннәр [Гарәпчә-русча алынмалар сүзлеге, 1965:244, 303, 360].

Күренекле рус фольклорчысы В.Е.Гусев билгеләмәсе: «Анекдот дип без ачык күренеп торган кульминацияле һәм көтелмәгән чишелешле бер эпизодка корылгансатирик яки юмористик эчтәлекле эпик әсәрне атыйбыз». [Гусев, 1967:127]. Әдәбият галиме Ф.Хатипов исә: «...Мәзәк дигәннән барыннан да бигрәк шаян рухлы, көтелмәгәнчә тапкыр, көлкеле җыйнак вакыйганы хикәяләп биргән жанрны аңлыйбыз» дигән аңлатма бирә [Хатипов, 1973: 12].

Әлеге билгеләмәләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясап була: мәзәкнең (анекдотның) кечкенә күләмле, чәчмә формадагы көлкеле (сатирик я юмористик) эчтәлекле әсәр булуы, аның тапкыр һәм көтелмәгән чишелеш белән тәмамлануы жанрның үзенчәлекле билгеләре булып танылa. Әлбәттә, мондый билгеләр, аерым-аерым алганда, башка төр фольклор әсәрләре өчен дә хас. Мәзәкләрнең бигрәк тә әкиятләр белән якынлыгы зур. Шуңа күрә дә кайбер фольклорчылар әле һаман да мәзәкләрне әкиятләрнең бер төре итеп карау ягында торалар. Һәм, киресенчә, мәзәкнең мөстәкыйль жанр булуын яклаучылар барыннан да элек аны әкияттән аера торган билгеләрне табарга омтылалар.

Мәзәкләрнең «төше», йомгак өлеше тормышта еш кына мәкаль, хикмәтле сүз ролен үти. Ягъни, мәзәктән мәкаль туа. Ләкин бу процесс үзе ике яклы. Кайбер очракларда мәзәкләр үзләре нинди дә булса мәкальнең эчтәлеген тирәнрәк ачу, аның мәгънәсен иллюстрацияләп күрсәтү максатында махсус рәвештә уйлап чыгарылалар. Мондый мәзәкләрнең кызыклы, көлкеле ягы шуннан гыйбарәт: мәкаль тексты, мөстәкыйль кулланылганда, образлы, күчерелмә мәгънәдә файдаланыла. Инде мәкальне мәзәк итеп җәйгәндә, вакыйга текстның туры мәгънәсенә нигезләнә. Нәтиҗәдә, мәзәк герое бик сәер, кәмит ситуациягә килеп эләгә. Мәсәлән, каракның бүреге яна дигән мәкаль бар. Аны кеше берәр сүзе йә хәрәкәте белән үзенең гаепле булуын фаш иткән очракта әйтәләр. Мәзәк шушы ситуацияне булган хәл шикелле итеп тасвирлый:

Татар халык мәзәкләре дә, башка күп кенә халыклар фольклористикасында кабул ителгәнчә, дә берничә төрле принцип

нигезендә төркемләнәләр. Х.Мәхмүтов мәзәкләрне персонажлары буенча төркемләргә һәм идея-тематик яктан бүлеп карарга тәкъдим итә. Ә М.Бакиров, көлү объектына бәйле рәвештә, мәзәкләрне иҗтимагый-сәяси эчтәлекле мәзәкләргә һәм һәм тормыш-көнкүреш мәзәкләренә бүлеп карарга тәкъдим итә.

Х.Мәхмүтов классификациясендә беренче төркем – мәзәкләрне персонажлары буенча төркемләү, ягъни танылган мәзәк геройлары турындагы әсәрләрне аерым цикллар итеп туплау. Болай эшләгәндә татар фольклорында түбәндәге зуррак мәзәк цикллары булуын күрәбез:

1) Әкмәли мәзәкләре;
2) Рәхми мәзәкләре;
3) Мокыт мәзәкләре;
4) Мәнди мәзәкләре;
5) Гыйбеди мәзәкләре;
6) Әшти белән Мәшти мәзәкләре;
7) Мөҗип дивана мәзәкләре;
8) Зирәк килен Үлмәс Сылу мәзәкләре;
9) Ялкау килен Пәриха мәзәкләре;
10) Җирәнчә Чичән мәзәкләре;
11) Хуҗа Насретдин мәзәкләре һ.б.

Хуҗа Насретдин, Җирәнчә Чичәннәр татар халкының үзе тарафыннан тудырылган образлар булмасалар да, алар безнең фольклорда нык үзләшеп, милли персонажлар булып киткәннәр. Хуҗа Насретдин татарлар арасында аеруча популяр. Бу урында Хуҗа мәзәкләрен җыю һәм матбугатка чыгару буенча язучы Абдулла Әхмәтнең зур эшчәнлек күрсәтүе ихтирамга лаек.

Билгеле, Хуҗа турындагы мәзәкләрне татар халкы үз репертуарына иҗади үзләштереп кабул иткән. Бу мәсьәләгә кагылып, М. Васильев болай дип яза: «Безнең текстларда төрекчә текстларны эшкәртү барыннан да элек түбәндәгеләрдә чагыла: 1) вакыйга бара торган обстановканы җирле көнкүреш шартларына яраклаштырып үзгәртүдә; 2) көлүнең тупаслыгын һәм хәрәкәтләрнең дорфалыгын йомшарта төшүдә, геройны гадиләштерүдә; 3) дингә мөнәсәбәттә ирония элементлары кертүдә» [Мәхмүтов, 1979: 22].

Хуҗа Насретдин мәзәкләренең татар фольклоры составында җирләшүе башка фактларда да күренә. Әйтик, Хуҗа исеме белән билгеле булган байтак мәзәкләр бездә башка персонажларга бәйләп сөйләнелә. Һәм, киресенчә, кайбер мәзәкләрдә элекке геройлар Хуҗа Насретдин белән алмаштырыла.

Мәзәкләрне төркемләүнең икенче ысулы – аларны идея-тематик яктан карап бүлү. Бу очракта без мәзәкләрне ике төп төркемгә аера алабыз:

1. Сыйнфый-иҗтимагый эчтәлекле мәзәкләр.
2. Көнкүреш, гаилә, әдәп-әхлак темасына караган мәзәкләр.

Беренче төркемгә керүче мәзәкләр изүче сыйныф вәкилләренең (ханнар, патшалар, вәзирләр, бәкләр, сәүдәгәрләр, байлар, казыйлар, муллалар һ.б.) залимлеген, гаделсезлеген, ахмаклыгын, комсызлыгын, саранлыгын. әхлакый бозыклыгын, шулай ук антогонистик җәмгыятьтә хөкем-идарә, укыту-тәрбия эшләрендәге төрле җитешсезлекләрне фаш итәләр.

Социаль эчтәлекле мәзәкләрдә антипод образлар- бер яктан, хезмәт халкы һәм, икенче яктан, изүче сыйныф вәкилләре бәрелешкә керә ( Хуҗа Настретдин һәм Аксак Тимер, Рәхми Тылмач һәм миллионер Озын Ибрай, хезмәтче һәм бай, мужик һәм мулла һ.б.). Күпчелек әкиятләрдән аермалы буларак, мәзәкләрдә тискәре геройлар физик җәзага дучар ителмиләр. Уңай геройның төп коралы- тапкыр сүз. Шуның ярдәмендә ул үзенең дошманнарын мәсхәрә итә, аларны көлкегә калдыра.

Мәзәкләрнең икенче тематик төркеме, инде әйткәнебезчә, әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Алар аерым кешеләрнең көнкүрешендә, холкында, үз-үзен тотышында очрый торган төрле җитешсезләрне һәм тискәре сыйфатларны (ялкаулык, наданлык, ахмаклык, аңгыралык, саранлык, шапшаклык, ялганчылык, сүз җае, эш рәте, ашау-эчү әдәбе белмәү һ.б.) тәнкыйтьлиләр.

Хәтта көнкүреш мәзәкләрнең үз эчендә дә, геройның кем булуына бәйле рәвештә, көлүнең дәрәҗәсе үзгәрергә мөмкин. Шапшаклыкны, мәсәлән, халык бигрәк тә яшь киленнәр өчен гаеп сыйфат итеп күрсәтә. Сүзгә мокытлык, ашау-эчү әдәбе белмәү кебек кимчелекләрдән аеруча үткен көлү үрнәкләрен кияүләр турындагы мәзәкләр арасыннан табарга була.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, мәзәкләр, кайсы төркемгә керүләренә карамастан, тормыштагы комик, көлкеле ситуацияләрне тасвирлыйлар икән. Көтелмәгән чишелешне укыган яки ишеткән кеше мәзәк хөкеменә нигезләнеп, үзе өчен нәтиҗәләр ясый ала.

Соңгы елларда мәзәкләр даими рәвештә төрле газета-журналларның махсус сәхифәләрендә басылып килә. Мәзәкләр нигезендә телевизион тапшырулар төшерелә. Шул ук вакытт аерым төбәк белән бәйле мәзәкләрне җыентык итеп чыгару эше башлануын да әйтергә кирәк. Бигрәк тә Т.Нәҗмиевның бу өлкәдә зур эш алып баруын әйтәсе килә. Аның тарафыннан әзерләнгән “Саба мәзәкләре” җыентыгы өч том булып басылды. Билгеле бу бик матур күренеш. Җыентыклар басыла икән, димәк аларга ихтыяҗ бар. Ә ихтыяҗ бар икән, халыкның күңелендә юмор һәм елмаю яши дигән сүз.

### *Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:*

1. Халыкның комик һәм үткен фикерләү формасы буларак мәзәкләр. Мәзәк жанрының табигате.

2. Мәзәкләрне персонажлары буенча төркемләү, ягъни танылган мәзәк геройлары турындагы арым цикллар, яки идея-тематик якка карап бүлү (социаль-иҗтимагый эчтәлектәге мәзәкләр, көнкүреш, гаилә, әдәп-әхлак темасына караган мәзәкләр).

3. Хуҗа Насретдин мәзәкләре. Төрки халыклар фольклорында бу персонажның урыны. Хуҗа мәзәкләренең әдәбиятка йогынтысы.

4. Мәзәкләрнең төзелеше, поэтик үзенчәлекләре. Мәзәкләрнең башка жанрлар белән уртак һәм аермалы яклары.

5. Мәзәкләрне җыю һәм өйрәнү тарихы. К.Насыйри, Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, А.Әхмәт, Х.Мәхмүтов һ.б. бу өлкәдәге эшчәнлеге.

6. Бүгенге көндә мәзәк жанрының яшәеш формалары.

**Студентларга укып анализлау өчен мәзәк текстлары**
**Хуҗа Насретдин мәзәкләре**

Бервакыт күршесе Хуҗа Насретдинны тезләнгән халәттә җирдән нидер эзләвен күрә.

- Нәрсәңне югалттың, Хуҗа,- ди ул аңа.
- Ачкычымны,- дип җавап бирә тегесе.

Ярты сәгать тирәсе вакыт уза һәм күршесе тагын ишегалдына чыга. Ә Насретдин исә һаман “дүрт аякта” йөрүен дәвам итә.

- Кайда югалттың соң син аны,-дип сорый ул.
- Өйдә.
- Соң шулай булгач ник аны ишегалдыннан эзлисең?
- Чөнки монда яктырак.

***

Бер яшүсмер Хуҗа янына килә дә, акыллы булып җитешү өчен күпме вакыт кирәк булуы белән кызыксына.

-Синең соравыңа җавап бирер алдыннан мин сине үзем белән алып барырга телим. Мин курайда уйнарга өйрәнү өчен музыка укытучысы янына барам,- ди ул.

Музыка укытучысы янына килгәч, Хуҗа түләү турында сүз кузгата. Тегесе исә:

- Беренче айга 3 көмеш тәңкә, ә аннары ай саен берәр көмеш тәңкә,- дип җавап бирә.
- Бик яхшы!- ди Мулла Насретдин. – Мин бер айдан килермен!

***

Бервакыт үзенең көймәсе ярдәмендә Хуҗа кешеләргә елга аша чыгарга булыша. Ул көймәсенә гарәп грамматикасын бик яхшы белүче берәүне утырта һәм аңа нидер әйтә. Әлеге сүзләр теге адәмгә грамматик яктан хаталы булып ишетелә.

- Синең беркайчан да гарәп телен өйрәнгәнең булмадымы әллә? – дип сорый теге адәм киная белән.
- Юк,- дип җавап бирә Насретдин.

- Ваемсыз! Димәк син ярты гомереңне бушка уздыргансың!

Берничә минуттан көймә ниндидер чыгып торган бер агач ботагына килеп бәрелә һәм чатный.

- Синең берәр вакыт йөзәргә өйрәнгәнең булдымы? – дип сорый Насретдин.
- Юк, - ди, галим
- Бәхетсез! Димәк син бөтен гомереңне әрәмгә уздыргансың, - ди Насретдин һәм суга сикерә.

***

Бервакыт Хуҗа кибеткә керә.Кибет хуҗасы сәүдә хезмәте күрсәтү өчен Насретдин янына килә. Хуҗа аңа:

- Син минем кибеткә кергәнемне күрдеңме? – ди.
- Әлбәттә,-дип җавап бирә хуҗа.
- Ә моңа кадәр синең мине берәр тапкыр күргәнең булдымы?
- Үз гомеремдә беренче тапкыр күрүем.
- Соң шулай булгач, син МИН икәнне каян беләсең?

***

Насретдинны тезләнгән хәлдә яр кырыенда күреп алалар. Ул суга каймак сала торган була. Аңа сорау бирәләр:

- Хуҗа, син нишләргә телисең?
- Минем каймак ясыйсым килә.
- Ләкин син бит мондый ысул белән каймак ясый алмаячаксың.
- Беләм. Ә бәлки килеп чыгар!

***

Хан палачларга Хуҗаны “Хәзер үк асыгыз!” — дип боерган. Палачлар Хуҗаны сөйрәп асарга алып килгәннәр. Хуҗа бер сүз дә дәшмәгән. – Синең соңгы минутларың җитте. Актык сүзеңне әйтеп кал,– дигән хан.

– Актык сүзем юк. Бик кечкенә генә бер үтенечем бар.

– Нинди үтенеч?– дигән хан.

– Минем муеныма кагылсалар, кытыгым килә, билемнән ассыннар,– дигән Хуҗа.

***

Беркөнне Хуҗа ишәген югалткан. Эзләп йөргәндә бер кешене очратып:

– Әфәндем, минем ишәгемне күрмәдеңме? – дип сорагач, теге кеше, аннан көлмәкче булып:

– Мин аны күрше шәһәрдә казый булган дип ишеттем, – дигән.

Хуҗа:

– Булыр, булыр, чөнки мин шәкертләргә дәрес биргәндә колакларын торгызып бик ихлас белән тыңлап тора иде, – дигән.

***Укырга***

***Төп әдәбият:***


1. Бакиров М. Мәзәкләр / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф,

2008. – 359 б. Б. – 146-159.

2. Мәхмүтов Х. Татар халык мәзәкләре // Татар халык иҗаты. Мәзәкләр. – Казан: 1979. – Б. 5-26.

3. Бәширов Г. Мәзәк турында бер-ике сүз // Сов. әдәбияты. – 1959. - № 9. – Б. 108-118.


***Өстәмә әдәбият:***


1. Мәхмүтов Х. Көлкенең хикмәте бар // Күңел ачкычы: Мәзәкләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 3- 8.


***Фольклор әсәрләре текстлары:***


1. Көлкенең хикмәте бар // Күңел ачкычы: Мәзәкләр (Төзүчесе Х.Мәхмүтов). – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 3- 8.
2. Мең дә бер мәзәк. (Төзүчесе һәм әдәби эшкәртүчесе Г.Бәширов). – Казан:Тат.кит. нәшр., 1963.
3. Нәҗмиев Т. Тагын... Саба мәзәкләре. Казан: Матбугат йорты нәшрияты. – 2001.
4. Нәҗмиев Т. Тагын... тагын... Саба мәзәкләре. Казан: Тат. кит. нәшр. – 2001.
5. Татар халык иҗаты. Мәзәкләр (Төзүчеләр Мәхмүтов Х.Ш., Садыйкова Х.Ш., кереш мәкалә авторы Х.Мәхмүтов). Казан: Тат. кит. нәшр., 1979.- 380 б.
6. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.
7. Туксан тугыз мәзәк (Төзүче һәм әдәби эшкәртүче Г.Бәширов). Казан: Тат.кит.нәшр., 1960. -182 б.
8. Хуҗа Насретдин мәзәкләре / Төзүче А.Әхмәт.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1966.- 210 б.
9. Хуҗа Насретдин мәзәкләре: Мәзәкләр. Төзүчесе Н.Вәлитова. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1992.
10. Яхин А., Бакиров М. Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан: КДУ нәшр., 1979. – Б. 3-81.

**«Татар халык мәзәкләре» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. Татар халык мәзәкләрен өйрәнү тарихы.
2. Татар халык мәзәкләренең тематикасы.
3. Төрки халыкларның популяр мәзәк персонажы – Хуҗа Насретдин.
4. Татар халык мәзәкләренең популяр персонажлары.
5. Халык мәзәкләренең бүгенге көндә яшәеше.

## ТЕМА № 8. ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Җыр – сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруны күздә тотып иҗат ителгән әсәр. Функцияләренә, иҗтимагый вазифаларына бәйле рәвештә татар халык җырлары дүрт жанр төркеменә бүленә: йола җырлары, тарихи җырлар, уен һәм бию җырлары, лирик җырлар.

Йола җырлары халык авыз иҗатының иң борынгы төрләреннән санала. Татар халык җырларын өйрәнгән галим И.Надиров бу төр поэзияне өч төркемгә бүлеп карый: 1) мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган шигъри сүз үрнәкләре, ырымнар; 2) ел фасылы (календарь) белән бәйле поэтик иҗат үрнәкләре; 3) туй йоласына караган җырлар.

Мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган шигъри сүз үрнәкләре, ырымнар. Йола поэзиясенең тарихи нигезләре, бер яктан, шигъри-музыкаль жанрның башлангычы буларак, халыкның хезмәт эшчәнлегенә, икенче яктан, аның дини күзаллауларына, борынгы ышануларына барып тоташа. Борынгы кеше табигать алдында көчсез булган, әйләнә-тирәдәге үзгәрешләрне аңлый алмаган. Әмма ул сүзнең һәм хәрәкәтләрнең сихри көченә ышанган һәм алар ярдәмендә, үз хезмәтен җиңеләйтеп, аның нәтиҗәлелеген күтәреп, көндәлек тормыштагы дошманнарны, табигатьтәге каршы көчләрне, көнкүрештәге бәла-казаларны җиңеп була дип ышанган. Шундыйлардан ниндидер авырулардан котылу нияте белән башкарылган «Теш бакасы теле», «Кан теле», «Елан теле», «Чир куудан» һ.б. текстлар булуы билгеле. Бу текстлар йола җырлары жанрына кертеп өйрәнелсә дә аларны җыр дип атавы кыен. Алар шигъри формадагы сүз тезмәләре генә.

Ел фасылына караган әсәрләр яңа елны каршылау, җир эшкәртү, иген үстерү, урып-җыю кебек аграр-гамәли ихтыяҗга бәйле рәвештә формалашкан йола-бәйрәмнәрдә башкарылган шигъри сүзләрдән һәм «келәүләр” дип аталган йола үрнәкләреннән тора. Турыдан-туры ел фасылына бәйле булган конкрет йола текстлары күп түгел. «Нардуган», «Нәүрүз», «Карга боткасы» һ.б.

Гаилә-көнкүреш йолалары (бәби туе, исем кушу, өй туе, өйләнешү туе, кешене соңгы юлга озату) белән бәйле материаллар шактый күп тупланган. Әлеге төр йолаларның иң әһәмиятлесе һәм катлаулысы: никах туе белән бәйле йолалар һәм аларны башкару вакытында яңгыраган җырлар. М.Бакировның «Туй йолалары һәм аларга бәйләнешле поэтик әсәрләр» дип аталган мәкаләсендә бу төр җырлар унике төркемчәгә бүленә: кыз елату җырлары – сыктаулар, «яр-яр» җырлары, «Ишек бавы» җырлары, кияү егетләре җырлары, туй табыны(мәҗлесе) җырлары, кода җырлары, тау итү җырлары, авызландыру алкышлары, арбаулар, өй бизәгәндә башкарыла торган җырлар, бүләк багу җырлары, бөркәнчек-бит ачу җырлары.

Уен һәм бию җырлары − җырларның гамәли вазифа үтәүгә бәйле булган һәм башкарылу формасы ягыннан борынгы чорны хәтерләткән төрләре. Аларның халык арасында киң таралуы чагыштырмача соңгырак чорга – узган гасырның 30нчы-50нче елларына туры килсә дә, барлыкка килүләре һәм формалашулары бик борынгы дәверләр белән бәйле. Бу җырларын конкрет бер вакытта гына һәм билгеле бер коллективта гына башкарып була. Икенчедән, әлеге җырларның функцияләре бик үзенчәлекле: алар әлеге уеннарны һәм биюләрне оештыруда хәлиткеч роль уйныйлар. Уенсыз һәм биюсез аларның эчтәлеген төгәл генә аңлатып булмый.

Халык җырларын һәм профессиональ җырларны өйрәнүгә багышланган күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы, галим К.Миңнуллин билгеләвенчә, уен-бию җырларының тарихы ерак гасырлардан килә. Җырлар һәрвакытта да диярлек үз чоры йолаларына, аларның эчтәлегенә, уен-хәрәкәтләренә тыгыз бәйле булган, аларга юнәлеш биргәннәр, ритмнарын көчәйткәннәр. Бу төр җырлар йоланың аерылгысыз өлеше саналганнар, аның гамәли вазифасын башкаруга ярдәм иткәннәр. Шуңа күрә әлеге җырларның тематикасы да шактый тар.

Уен җырларының үзенчәлеген уенның төрле элементлары (текст, көй, хәрәкәт) арасында урнаша торган табигый функциональ бәйләнеш билгели. Җыр йола һәм аңа бәйле уен хәрәкәтләреннән аерылгач, аның эстетик роле киңәя, эчтәлеге дә мөстәкыйльләшә, гомумиләшә бара. Җыр-биюләрнең нигезен тәшкил иткән йола һәм гореф-гадәтләрнең көндәлек тормыш белән бәйләнеше югала барган саен, бу төр сүз иҗаты эчтәлек һәм форма ягыннан төрләнә, байый, яңа бәйрәмнәр белән кушылып китә. Яшьләр арасында уеннарның күп төрләре тарала. Алар гадәттә яшьләр җыелган урыннарда − элек«аулак өйләрдә», кичәләрдә, соңрак клубларда уйнала. Күмәк уенарның бер төрлесе фант җыешлы һәм җәза бирле уеннар тәшкил итә, икенчеләре җырсыз гына уйнала. Уеннарның тагын бер – җыр һәм такмаклар белән кушылып бара торган төре – кара-каршы тезелеп («Җимчәчәк», «Челтәр элдем читәнгә» һ.б.) һәм пар-пар булып («Агыйдел күпере», «Вагоннар, эшелоннар» һ.б.) уйнаудан гыйбарәт. Татар яшьләре

арасында иң таралганы- әйлән-бәйлән уеннары. Мондый уеннарның төп үзенчәлеге аларның күмәк җыр һәм бию белән үзара үрелеп башкарылуында. Бу уеннардагы җырлар структур яктан ике өлештән – күмәк башкарыла торган җырдан һәм бию такмагыннан (кушымтадан) тора.[Миңнуллин, 2003:56].

Уен-бию җырларының бер өлешен бию такмаклары алып тора. Бу күп кенә халыклар иҗатында урын алган бик борынгы жанр. Такмакларның вазифасы биюгә өндәү-кыстау, биючегә мөрәҗәгать итү, аның хәрәкәтләрен хуплау, осталыгына соклану яисә шаяртып көлү, тексттагы шаян сүзләр аша бәйрәмдә катнашучы берәр кешегә әйтер сүзне җиткерүдән гыйбарәт. Такмакларның рифмалары һәм ритмнары бик төгәл.

Тарихи җырларга хас төп үзенчәлек – халык, ил тормышындагы зур тарихи вакыйгаларны, күренекле шәхесләрне сәнгатьчә чагылдыру. Аларның аерым төр буларак барлыкка килүе XIII- XV йөзләргә караса да, чәчәк ату дәвере XIX йөзгә туры килә. Татар халык җырларын өйрәнүгә бик күп фәнни хезмәтләр багышлаган галим И.Надиров фикеренчә: «Кагыйдә буларак, аларда сурәтләнгән күпчелек вакыйгаларның реаль конкрет җирлеген, ә шәхесләрнең прототипларын ачыкларга мөмкин. Шуның белән бергә жанр өчен уйдырмалылык та хас. Тарихи җырлар арасында шигъри хыял ярдәмендә иҗат ителгән вакыйгалар да, персонажлар да очрый» [Надиров, 1988: 6].

XIV гасыр урталарында татар халкы тарихының фаҗигале бер чоры башлана. Шушы катлаулы, каршылыклы тарихи чорда булган вакыйгалар халык җырларыннан читә калмый, тирән иҗтимагый эчтәлекле җырлар тууга сәбәп була. «Суар кешеләре җыры», «Болгар ятимәләре», «Шәһре Болгар» кебек әсәрләр әнә шундыйлар. Казан ханлыгы чорында иҗат ителгән тарихи җырлар нигездә Казан ханлыгының таркалуы һәм Сөембикә исеме белән бәйле.

Тарихи җырларда 1773-1775 еллардагы крестьяннар сугышы, аның җитәкчесе Е.Пугачев, милли каһарманнар Салават Юлаев белән Бәхтир Канкаевлар, 1812 елгы Ватан сугышы чоры вакыйгалары да кереп калган.

XIX йөздә иҗат ителгән качкыннар турындагы җырлар да тарихи җырлар төркеменә карый. «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын», «Ташкай» кебек җырларда сүз ачлык-ялангачлыктан, патша армиясеннән, алпавытларның эзәрлекләвеннән качып, урманнарда гомер кичерүче бәхетсез кешеләр турында бара.

Тарихи җырларның соңгы төркемен Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы турындагы әсәрләр, Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр тәшкил итә.

Халык лирикасының төп өлеше хис-кичерешләр агышына, психологик сюжетка нигезләнә. Ә тарихи җырларның нигезендә вакыйга сюжеты ята. Ягъни тарихи җырда конкрет тарихи шәхес тормышында булган вакыйгалар турында хикәяләү, халык дастаннарындагыча, эпик

планда алып барыла. Тарихи җырларга хас бу үзенчәлек аларның башка төр җырлар белән чагыштырганда зуррак күләмле булуларында да чагыла. Лирик җырлар, гадәттә, өч, дүрт яки биш куплеттан торсалар, тарихи җырлар сигез, ун унике куплетлы була. Аерым җырларның күләме егерме-утыз куплетка да җитә. Шуңа күрә тарихи җырлар фольклорның лиро-эпик төрләреннән санала һәм татар халык иҗатында үзенчәлекле урын алып тора.

Җырларның иң киң таралган төре исә – лирик җырлар. Алар – кешенең аерылгысыз юлдашы буларак, теләсә кайсы вакытта, төрле урында башкарылып, аның күңеленә гаять якын торып, һәрвакыт юатып, тирән кайгы-хәсрәтен һәм кичерешләрен уртаклашучы җырлар. Бу төр әсәрләр халык арасында бүген дә популяр. Алар, күләмнәренә бәйле рәвештә лирик озын җырлар һәм лирик дүртьюллыклар дигән ике төркемгә бүленәләр. Аларның саны бик күп, берничә дистә меңгә җитә. Бу ике төрнең дә яшәү һәм таралу даирәсе киң, анда сурәтләнгән темалар да күптөрле. Лирик җырларда халыкның патша заманындагы иҗтимагый тигезсезлеге, читкә китеп мал, бәхет эзләп йөрүе, хатын-кызның авыр тормышы, хокуксызлыгы, дуслык-туганлык мөнәсәбәтләре, мәхәббәт һәм башка темалар үзәктә тора.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

1. Йола җырлары. Календарь йолалар белән бәйле җырлар. Гаилә йолалары белән бәйле җырлар (туй йоласы җырлары).

2. Лирик җырларның тематик төрлелеге: социаль тормыш, хәсрәтле дөнья турында, читкә китеп бәхет эзләүчеләргә, хатын-кызның авыр язмышына багышланган җырлар, мәхәббәт җырлары, дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары. Лирик озын һәм кыска җырлар. Аларның поэтик табигате. Лирик җырларда традицион образлар.

3. Жанрның уен үзенчәлегенә бәйле төрләре: кара-каршы тезелеп яки парлашып башкарыла торган җырлар (Җимчәчәк, Челтәр элдем читәнгә, Чума үрдәк, чума каз); әйлән-бәйлән яки түгәрәк җырлары (Ай йолдызым, И дүдәме, дүдәме, Их, су алулары, Кәрия-Зәкәрия, Наза, Уфа-Чиләбе), һөнәр күрсәтү уеннарына бәйле җырлар (Җыр әйтешү, Ялтыр-йолтыр, Сөясеңме-сөймисеңме? )

4. Уен-бию җырларының такмак жанры белән керешеп китүе, уен һәм бию такмаклары (Әпипә, Әнисә, Бие-бие, Хәйбулла, Бас-бас, каты бас һ.б.).

***Укырга***

***Төп әдәбият:***

1. Бакиров М. Ел фасылларына бәйләнешле йола-бәйрәмнәр һәм әсәрләр (48-60 б.); Туй-йола поэзиясенең поэтикасы (82-87 б.); Лирик җырлар (160-176 б.); Тарихи җырлар (176-197 б.); Уен-бию җырлары һәм

такмаклары (325-336 б. ) / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

2. Бакиров М.Х. Халык хәтере. Тарихи җырларыбыз һәм бәетләребез турында // Мирас. — Казан, 1992. — № 10. — Б. 33-38.

3. Бакиров МХ. Лирик җырлар // Мирас. — 1998. — № 8. — Б. 74-82.

4. Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз җыры. — Казан: Мәгариф, 2003.

5. Урманче Ф. Тарихи җырлар (175-182, 246-249 б. ); Лирик җырлар (287-306 б.) Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2002.

6. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1967.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Җамалиева Л.Ф. Фольклорда уртаклык мәсьәләләре. – Казан: Алма-Лит, 2003.- 64 б.

2. Исхакова-Вамба Р. Татарское народное музыкальное творчество. Казань: Тат. кн. изд., 1997.

3. К вопросу классификации и жанровых особенностей татарской народной песни // Итоговая научная сессия Казанского института языка, литературы и истории АН СССР за 1963 год. — Казань, 1964. — С. 32-37.

4. Мәһдиев М.С. Татар халык җырларының поэтикасы // Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе: фәнни хезм. җыент. — Казан: Казан ун-ты нәшр., 1982. — Б.65–110.

5. Надиров И. Надиров И. Халыклашкан җырлар тарихыннан // Совет әдәбияты. — I960. — № 2. — Б. 88-95.

6. Надиров И. Поэтические особенности исторических и лирических песен // Поэтика татарского фольклора. — Казань, 1991.— С. 5-22.

7. Надиров И. Традиционные образы татарской народной лирики / // Развитие гуманитарных наук в Татарии. — Казань, 1977. — С.130-139.

8. Надиров И. Халык һәм җыр.— Казан: Тат. кит. нәшр, 1961.

9. Надиров И.Н. Взаимосвязи песенного фольклора народов Среднего Поволжья и Приуралья // Межэтнические общности и взаимосвязи фольклора народов Поволжья и Урала: сб.ст. — Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1983.— С. 49-55.

10. Нигмедзянов М.Н. Татарская народная музыка.— Казань: Магариф, 2003.

11. Поэтика татарского фольклора (Сост. Х.Махмутов). Казань, 1991.

12. Ягъфәров Р. Такмакларның поэтикасы турында // Фольклор теле-шигърият теле. Казан: Фикер, 2001. – Б.36-44.

***Фольклор әсәрләре текстлары:***

1. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (кереш мәкалә авторы И.Надиров). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1976.

2. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. (кереш мәкалә авторы Н.Надиров). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1980.

3. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар (кереш мәкалә авторы И.Надиров). - Казан: Тат. кит. нәшр., 1988.

## Укып фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган җыр текстлары

**Чыганак:** Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.

## Йола һәм уен җырлары

### Мәҗүсилек һәм борынгы шигъри сүз үрнәкләре

### Зыяндаш теле

### Зәхмәт теле

Җир асты – җирән сакал,
Су асты – суган сакал,
Җир анасы – сынлы бикә,
Җир кендеге – бер,
Су кендеге – бер,
Җирдән килсәң – җиргә кит;
Судан килсәң – суга кит,
Минем кулым түгел,
Имчеләр, картлар, карыйлар кулы,
Гайшә – Фатыйма кулы,
Тфү, тфү!

## Ел фасыллары белән бәйле шигъри иҗат

### Нәүрүз мөбарәкбад

Ач ишегең, керәбез
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер – дога кылабыз,
Аш – сый көтеп торабыз,

Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә;
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәкбад.
Нәүрүз мөбарәкбад.
И Иш бабай, Иш бабай,
Пич башыннан төш, бабай,
Капчык авызын чиш, бабай,
Нәүрүз мөбарәкбад.
И Иш бабай, Иш бабай,
Пич башыннан төш, бабай,
Бер тиен бирсәң аз булыр,
Нәүрүз мөбарәкбад.

## Келәүләр
## Яңгыркаем, яу, яу!

Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Илгә ачлык килмәсен,
Ачтан халык үлмәсен,
Чума чире йөрмәсен!
Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Иген – ашлык күп булсын,
Башаклары тук булсын,
Кибән – эскерт зур булсын!
Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын;
Сөтле сыер абзарда,-
Бар да булыр яуганда,
Яңгыркаем, яу, яу, яу!

## Туй йоласы җырлары
## Эртергә килгән мин
## Яучы җыры

Ефәк баулы былбыл кош
Бардыр синең илендә.
Каеш баулы лачын кош
Бардыр минем илемдә.
Өер – өер айгырдан
Җайдак булып килгәнмен.
Чаптар атым чаптырып,
Чыңлап сиңа килгәнмен.
Бохардан ияр алган мин.
Юлым сиңа ярган мин,
Каеш сиңа ярган бар,
Былбылыңа килгән мин;
Тимер булсаң, мин – күмер,
Эртергә килгән мин.

## Ишек бавы

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын;
Җылыныйм дисәң, бер алтын
Бир, җизни,– тыш бик салкын.
Саранланып чак түгел,
Бир, җизни, комсызланма;
Акча бирми кертмибез,
Тукта, сабырсызланма.

Синең җаныең булса,
Ул – кайнеңнең апасы;
Без билетсыз кертмибез,
Бу бит җәннәт капкасы.
Безне разый кыйл, җизни,
Без каршында ризванбыз[55];
Хур янына илтәбез:
Без вилданбыз, гыйльманбыз[56].
Зур дәүләт ич, җизни, бу,-
Тагын моннан зур ни бар?
Торма малың кызганып,
Җан бирсәң дә урны бар!
Бирсәң – күп бир син безгә,
Без разый түгел әзгә;
Яудыр алтын, көмештән:
Бакыр төрмә кәгазьгә.

[55] Ризван-оҗмах сакчысы.
[56] Вилдан, гыйльман-оҗмахтагы хезмәтче егетләр.

Безнең апай гәүһәрдер[57],
Тәннәре чын мәрмәрдер;
Ләгыль, якут, гәүһәрдер,
Аузы балдыр, кәүсәрдер[58].

## ТАРИХИ ҖЫРЛАР

### Сөембикә китеп бара

Идел ага яр кагып,
Уңга-сулга чайкалып.
Ут көймәсе китеп бара
Сөембикәне алып.
Сөембикә ак яулыгын
Тоткан учлап кулына.
«Хуш, Казаным, каласын»,– дип
Үкереп елый буена.
Ия башын,түгә яшен,
Казанга таба карап;
Миннән башка ничек итеп
Көн итәрсез дип аяп.

### Пугачау

Пугача патша бар диләр,
Постау бишмәтләре тар диләр,
Җаек та буе яу җирләрен
Айкап  та йөргән шул диләр.
Пугачау патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

### Пугачау явы

Олы гына юлның тузаны,
Бөркелеп тә килгән яу бугай;
Олы гына юлдан ду китереп
Эркелеп тә килгән яу бугай.
Олы гына юлың тузаны,
Чаң бөркетеп гаскәр узганы;
Пугачау ла патша үз дошманын
Куй – сарыктай итеп кырганы.
Алда гына торган Петр тавы,
Петр тавы – ирек, җир тавы;
Шуннан узган  Казан ягына
Ил шаулатып Пугачау явы.

### Япон сугышлары яман икән

Эчләрем пошса, мин чыгамын
Гөлләр чәчәк аткан бакчага.
Сары чәчәк ата көнбагыш,
Ерак та ла, ерак Порт-Артурга
Тимер юллар киткән сузылып.
Сары чәчәк ата көнбагыш,

[57] Ләгыль,якут,гәүһәр- кыйммәтле ташлар.
[58] Кәүсәр- баллы ширбәт.

Яман япон сугышлары бетеп,
Кайчан туар безгә куаныч?

Ике күзем нуры – ялгыз балам
Солдат булып китте патшага.
Сары чәчәк ата көнбагыш,
Яман япон сугышлары бетеп,
Кайчан туар безгә куаныч?

Яман япон сугышлары бетеп,
Кайчан туар безгә куаныч?

Япон сугышлары яман икән,
Йөрәк маем кайтсын котылып.
Сары чәчәк ата көнбагыш,
Яман япон сугышлары бетеп,
Кайчан туар безгә куаныч?

## ШАЯН ҖЫРЛАР
### Җизнәкәй

– Аякларың ник кәкере, җизнәкәй?
– Тишек итек кигәнгә, балдызым- ялгызым.
– Бу билләрең нигә нечкә, җизнәкәй?
– Ашау такыр булганга, балдызым – ялгызым.
– Бу йөзләрең ник саргайган, җизнәкәй?
– Сине өзелеп сөйгәнгә, балдызым – ялгызым.
– Балдыз сөю язык диләр, җизнәкәй?
– Язык казык башында, балдызым – ялгызым.
– Ярма булып коелырмын, җизнәкәй.
– Әтәч булып чүпләрмен, балдызым -ялгызым.
– Балык булып суга агармын, җизнәкәй.
– Кармак булыр тотармын, балдызым- ялгызым.
– Апай сизсә эшләр харап, җизнәкәй.
– Курыкма, үзем юллармын, балдызым – ялгызым.
– Әткәй сизсә, ни әйтермен, җизнәкәй?
– Урлармын да качармын, балдызым – ялгызым.
– Алар мине каргарлар бит, җизнәкәй?!
– Каргышы карга башына, балдызым- ялгызым.
– Сакалларың нигә җиткән, җизнәкәй?
– Кырырга вакыт юклыктан, балдызым- ялгызым.
– Ә нигә соң вакытың юк, җизнәкәй?
– Синең арттан йөргәнгә, балдызым- ялгызым.
– Нигә соң арттан йөрисең, җизнәкәй?
– Сине өзелеп сөйгәнгә, балдызым – ялгызым.
– Әгәр без бергә кавышсак, җизнәкәй...
– Рәхәт яши бирербез, балдызым – ялгызым.
– Ә кайда соң без торырбыз, җизнәкәй?
– Землянкә казып керербез, балдызым-ялгызым.

– Алай булса кавышыйк сон, җизнәкәй.
– Кавышсак, кавышырбыз, балдызым -ялгызым.
– Халык хәйран калыр инде, җизнәкәй.
– Күзне йомып узарбыз, балдызым - ялгызым.

## УЕН-БИЮ ҖЫРЛАРЫ

### Ал итә, итә, итә

Их дускаем, син икәнсең,
Күрмәдем килгәнеңне;
Тулган айларга охшатам
Елмаеп көлгәнеңне.
К у ш ы м т а:
Ал итә, итә, итә,
Гөл итә, итә, итә,
Гармунчылар гармуннарына
Таянып ял итә.

Үзе су буйларында,
Гармуны кулларында;
Су төбенә карап уйный, -
Кем икән уйларында?
Башыңдагы яулыккаең
Кайсы дустың бүләге;
Бүләк булса көн дә бәйлә,
Янсын дошман йөрәге.

## КЫСКА ҖЫРЛАР

### Дүртьюллыклар

Газиз башлар, газиз башлар;
Бәләкәй туры ат юл башлар;
Бз озын гомерләр эчендә
Әллә ни күрер бу башлар.

Ак күлмәккәйләрем ак түгел,
Ак күлмәккәй кияр чак түгел;
Уйнар идем, көләр идем,
Әллә нигә күңлем шат түгел.

Алма гына чәчтем – гөл бетте,
Гөлнең яфракларын җил түкте;
Бирмәсә Ходай бирмәс икән,
Күпме теләкләрем буш китте.

Үрдәк кенә күлләрдә булыр,
Лачын кошлар чүлләрдә булыр;
Кайгырма, җанашым, үкенмә,
Әллә рәхәт көннәр дә булыр.

Һавалардан килә ике асыл кош,
Артларыннан куа карчыга;
Бу да хәсрәтләрнең бәласеннән
Йөрәк бәгырьләрем талчыга.

Самавыр куйдым эчәргә,
Әстерханнан килгән кешеләргә;
Исәпләп баксам – исем китә,
Башкынаемнан үткән эшләргә.

Сандык та сандык багалма,
Сайласам да чыкмый бөтене;
Эчемдә ялкын, тышым салкын,
Дөньяларда чыкмый төтене.

Утырдым көймә түренә,
Карадым суның төбенә;

Иманлеккә утлар салдым,
Асманнарга менде төтене;
Әллә болай булмас идем,
Шулайдыр Алла хөкеме.

Тимерле арба, төзек юл,
Барыр җирем ерак җир;
Михнәт чигеп маллар таба
Безнең кебек фәкыйрь ир.

Һавадан аккош очадыр
Агыйдел буе камышка;
Үлмәсә кеше үлмәс икән
Күкрәге тулы сагышка.

Су төпләрендә һич кара юк,
Хода кушкан эшкә чара юк.

Җитен дә чәчтем – булмады,
Бер буразнасы тулмады;
Һичберәүгә үпкәләмим,
Үз бәхетем булмады.

Сары сандугач баласын
Күрмәдем күмелгәнен;
Ник тулмасын күңелләрем,
Үтте яшь гомерләрем.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Сызлып таңнар атса да;
Яшь гомерләр ике килми,
Сулар үргә акса да.

## ЛИРИК ҖЫРЛАР

### Иске кара урман

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә.
Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым куш каен,
И- и, аерылмаек, дускаем.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус- иш кирәк дөнья көтәргә.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И- и, аерылмабыз дус булсак.

Кара да гына елан, ай, түз башлы,
Йөридер лә камыш буенча.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым куш каен,
И- и, аерылмаек, дускаем.

Ялгыз гына башым, юк юлдашым,
Йөримен лә язмыш буенча.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар усак,
И- и, аерылмабыз дус булсак.

### Кондырык болыннары

Кондыракта җиләк җыйдым
Печәнлек арасыннан;
Йөрәкләргә рәхәт була
Хуш силе һавасыннан.
Бигрәк күңелле
Кондырак болыннары,
Җәйнең матур кичләрендә
Бигрәк күңелле
Кондырак болыннары,
Җәйнең матур кичләрендә
Яңгырый тальян моңнары.
Җәй көннәрендә Кондырак
Чәчәкләргә күмелә;
Туган якның болыннары

Яңгырый тальян моңнары.
Шул Кондырак болыннарын
Якын күрә йөрәгем;
Көндез исләремнән чыкмый
Төнлә төштә күрәмен.

Мәңге якын күңелгә.
Бигрәк күңелле
Кондырак болыннары,
Җәйнең матур кичләрендә
Яңгырый тальян моңнары.

## Студентларның фольклор практикасы вакытында тупланган җырлар

### ЙЫР

**Информант:**Сибгатуллина Әнисә (1929 елгы)
**Язып алучы:**
Патршина Альминур Сагадатдин кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы Түкүз авыл, 1994 ел

Утырмайца пулмас инте, пулмас инте
Койма койылган йергә.
Йырламайца пулмас инте, пулмас инте
Туслар йыйылган йертә.
Мәңке сүнмәс утлар йана, утлар йана
Шахты күмерләрентә.
Перкемем юк, пер сес кенә, пер сес кенә
Минең күңелләремтә.
Сайрап торган сантугацлар, сантугацлар,
Пер сайрый та, ял итә.
Пы төньяның шансы кыен, шансы кыен,
Туганнартин сар итә.
Сайрап торган сантугацның, сантугацның,
Айагынта ла туты пар.
Йәш пулмасак та песнең эцтә, песнең эцтә
Мәңге сүнмәс утлар пар.

### Солы пәйете (Лирик җыр)

**Информант:** Сагататдинов Камалетдин Сагадатдин улы,1944 елгы
**Язып алучы:**
Патршина Альминур Сагадатдин кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы Түкүз авыл, 1994 ел

Ургыларым килә вай урактин
Ургылып лай үскән солыны,
Төнъякларны өц айланып йөртем,
Тапматым лай синтәй сылуны.
Пәлән тә генәй йертә пер мәцет пар,
Өсте генә ләй мәрмәр, асты таш.
Еракта гына лай песнең ярлар,
Күкрәк тәртле генә ләй, күсләр йәш.
Агым суларта, әй сал пара,

Турманкасы пелән мал пара.
Пылай гына сөеп ташлап китсәң
Ике күсем кемгә ләй ялвара.
Пәлән генә йертә пер мәцет пар
Оцы та гынай сөйәк, төбе таш,
Әтекәем – шикәр, әнкәем – пал,
Аларитин ләй татлы сөйгән яр.

Мәцет манарасының әй ишеге,
Тутый кошлар кунмай ацылмас.
Йәш егеткәйләрнең вай йөрәге,
Кыс куенына кермәй пасылмас.

## ШАЯН КЫСКА ҖЫРЛАР

**Информант һәм язып алучы:**
Патршина Альминур Сагадатдин кызы
Төмән өлкәсе, Вагай районы Түкүз авыл, 1994 ел

Манталин кулларымта,
Киттем урам пуена.
Йегетләр миңа ашыйк пула
Тал цыбыктай пуема.

Пөген айга нейөәсе
Унөценце кицәсе,
Минең тә пулгым киләте,
Гармонистның пицәсе.

Манталинең таллый-таллый
Таллый пулса та йарый.
Сиңа инте йегет нигә
Картлац пулса та йарый.

Каен янсын, каен янсын,
Каен янсын ут алсын.
Ялынырлык ярлар түгел,
Пүскәй ятларга калсын.

***

**Информант һәм язып алучы:** ТДСПА студенты
Хәбибуллина Наилә Наил кызы,
Төмән өлкәсе, Вагай районы Сөләйман авылы, 2006 ел

Әнә килә машинә,
Машинәтә Патимә.
Патимәнең аягынта,
Пиш тәнгәлек патинкә.

Песнең авыл кыслары,
Клеш цалвар кияләр.
Клеш цалвар кияләр тә
Порыннарын цөяләр.

Син тә матур үсеңә,
Мин тә матур үсемә.
Шакка төшкән тавытаен
Күренәсең күсемә.

Иртән тороп, тышга цыксам,
Сыйырлар кар көриләр.
Ике куян мылтык тотоп,
Пүре атып йөриләр.
***

**Информант:** Абдразакова Маһира Халитулла кызы, 1933 елгы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Абдразакова Разалия Раил кызы
Төмән өлкәсе, Ярков районы, Иске-каикүл авылы, 10.10.2008

Песнең урам тар пулса та,
Көн тә уса машинә.
Агылсыслык, сабырсыслык-
ларым йетә пашыма.

***

**Информант:** Рыханова Роза Раил кызы, 1969 елгы
**Язып алучы**:ТДСПА студенты
Ташбулатов Валериан Әкрам улы

Җәй көнендә ямьле була
Болыннарда йөргәндә.
Яшь кызларга ямьле була,
Яшь егетләр булганда.
Тырнакларың алсу-алсу,
Алсуга мандыңмәллә?
Җырлыйсың да елыйсың
Кияүсез калдыңмәллә?

Ләцекнеңке каенлыгы
Балда сапка ярамый.
Ләцек авылы кызлары
Киленлеккә ярамый.

Билең нечкә, билең нечкә,
Кара каеш ник будың?
Эш эшләргә ярамагац

Бу дөньяга ник тудың?

Татар әйтә тары ярма,
Урыс әйтә пышана.
Сезнең кебек кызыл авыз,
Алам дисәң – ышана.

Атка салган пүрәнә,
Авыр булып сүрәлә.
Бу саманның кызлары,
Йөз гырамнан үрәнә.

**«Татар халык җырлар» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. Татар халык җырларын өйрәнү тарихы.
2. И.Надировның татар халык җырларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.
3. Лирик җырларның поэтик үзенчәлекләре.
4. Татар халык җырларының образлар системасы.
5. Йола җырларының функциональ табигате.

## ТЕМА № 9. ТАТАР ХАЛЫК БӘЕТЛӘРЕ ҺӘМ МӨНӘҖӘТЛӘРЕ

Бәет – нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган, татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Бәет тормышта булып узган вакыйгаларны суынмаган эзләреннән тасвирлый. Шуңа күрә ул хис-кичерешләрнең иң киеренке вакытларында туа. «Бәет» атамасы гарәп телендә ике юллык строфа төрен белдерүче «бәйт» сүзеннән алынган дип исәпләнелә.

Бәет җанры фаҗигале һәм героик вакыйгалар, шулай ук гыйбрәтле һәм гадәттән тыш хәлләр уңае белән чыгарылган әсәрләрне берләштерә. Аларның тексты шигъри формада була һәм телдән әйтелә яки көйләп башкарыла. Ләкин көйләп башкарылган бәетләргә карата да халыкта «бәет җырлау» дигән гыйбарә кулланылмый, ә «көйләп бәет әйтү» яки «көйләп бәет уку» диләр. Бу, күрәсең, әлеге жанрның «язма китап культурасы» һәм электән килгән «көйләп китап уку» традициясе белән бәйләнештә туганлыгын күрсәтүче бер дәлил [Бакиров 2008: 262].

Бәетләрне иҗат итүдә халыкның барлык сыйнфый катлау вәкилләре: эшчеләр һәм крестьяннар, укымышлылар, ягъни мәдрәсә шәкертләре дә катнашкан. Халык күңеленә ошаган, аның игътибарын җәлеп иткән күп кенә бәетләр телдән телгә күчеп йөрү юлы белән генә түгел, бәлки халык авыз иҗатының башка төрләре, мәсәлән, җырлар, табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәрнең кайберләредәй, дәфтәрдән дәфтәргә күчерелеп алыну юлы белән дә сакланып килгәннәр.

XV йөзнең икенче, XVI йөзнең беренче яртысыннан алып XX йөзнең урталарына кадәр бәет Идел буе татарларының лиро-эпик иҗатында төп һәм иң нык таралган жанр булган. Бәет тарихын өйрәнүче галимнәр бу мәсьәләдә татар халкының күренекле тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләренә таяналар [Урманчеев 1974: 7].

Бәетләрнең мөстәкыйль жанр буларак формалашуы кинәт булган кыска вакытлы гына күренеш түгел, ә катлаулы һәм дәвамлы процесс. Билгеле поэтик система барлыкка китергәнче, бәетләрнең булачак асыл сыйфатлары шактый озын үсеш юлы үткәннәр. Безнең эзләнү нәтиҗәләренә караганда, ул сыйфатларның иң тирән катламдагылары башта бүтән жанрлар эчендә туганнар һәм аерым элемент буларак гәүдәләнгәннәр.

Халык әдәбиятының үзенчәлекле жанры буларак, бәетләр күп еллардан бирле татар, рус һәм чит ил галимнәренең игътибарын тартып киләләр. Нәтиҗәдә бәетләрне җыю һәм бастыру өлкәсендә бик күп эш башкарылган.

Татар халык бәетләренең үзенчәлекләре турында беренче булып Каюм Насыйри үзенең Казан календарьларында һәм «Фәвакиһел җөласа

фил әдәбият» исемле китабында язып чыккан. Алга таба бәетләр Николай Катанов, Хуҗа Бәдигый, Гали Рәхим, Гомәр Толымбай, Хәмит Ярми, Фатих Урманче, Флора Әхмәтова, Марсель Бакиров, Котдус Хөснуллин һәм башкаларның хезмәтләрендә тикшерелә.

Галимнәр бәетләрне үз эчендә берничә типка бүлеп карыйлар: тарихи вакыйгалар һәм шәхескә багышланган бәетләр, авыр замана, ирексез хезмәт, хатын-кызларның михнәтле язмышын чагылдырган бәетләр, җир, ирек өчен көрәшне гәүдәләндергән бәетләр, шәхси фаҗигаләргә багышланган, сыйнфый-социаль фаҗигалеккә нигезләнгән бәетләр һ.б.

Бу бүленештә,Россиядәге тарихи вакыйгалар һәм сугышлар турындагы бәетләр, һичшиксез, беренче урында торалар. Иң борынгы бәетләр дә – сугыш бәетләре («Рус-француз сугышы бәете» һ.б.). Сугыш бәетләрендә халык Россиянең көчен, аның патриотик горурлыгын беренче планга һәм төп момент итеп куя. Мондый бәетләрнең барысында да дошманны тар-мар итү теләге, халыкның сугышка теләп баруы, илне илбасарлардан сакларга кирәклеге бик ачык чагыла. Ул бәетләрдә халык үзенең җиңү тантанасын җырлый. Ә соңгы елларда ил тарихында булган сәяси вакыйгалар, Әфганстан һәм Чечня сугышларында да йөзләрчә егетләр башларын салып калдылар. Бу төр бәетләр берьяктан тарихи, икенче яктан шәхси фаҗига бәетләре дип карала аллар.

Бәетләр арасында хезмәт ияләренең авыр хәлен һәм иҗтимагый хәрәкәтен яктырткannары да шактый зур урын ала. «Мужик бәете», «Ялчылар бәете» кебекләрендә хезмәт ияләренең авыр тормышы, капитализм тудырган социаль тигезсезлек, ярлыларның байлар тарафыннан изелүләре тасвирлана.

Хезмәт халкының патша тарафыннан эшләнгән ысулларга, җәберләүләргә каршы көрәшләрен һәм сәяси аң дәрәҗәләре үсүен күрсәтү ягыннан «Урта Тигәнәле», «Ышна», «Чыңлы» бәетләре аеруча характерлы. Бу бәетләрдә крестьяннарның җир һәм ирек өчен булган күтәрелешләре сурәтләнә. Патша түрәләренең, жандармнарның ерткычлыклары һәм халыкны төрлечә мәсхәрәүләре, хурлауларын халык авыр кичерә һәм бәетләрдә моны ачык чагылдыра.

Элеккеге заманнарда татарлар гына түгел, бәлки Россиядә яшәүче барлык милләтләрнең хезмәт ияләре солдатка алынуны зур бәхетсезлек итеп санаганнар. Халыкның менә шул ризасызлыгы җырларда, бәетләрдә чагыла килгән. Мисал өчен элеккеге вакытларда халыкта киң таралган «Солдат бәетләре», «Никрут зары» һ.б. бәетләрне күрсәтергә була. Боларның барысында да халыкның шул вакытлардагы законнардан, тәртипләрдән ризасызлыгы, солдатка алынучыларның бәхетсезлеге чагылыш тапкан.

Жанрның иң зур төркемнәреннән берсен **хатын-кызлар турындагы** бәетләр алып торалар. Күпчелек бәетләрнең эчтәлеге өчен фаҗигалелек

хас. Шулай ук революциягә кадәрге бәетләрдә хатын-кызларның шәхси кайгысы турында гына сөйләмиләр, ә аларның хокуксызлыгын, социаль тигезсезлеген дә күрсәтеп торалар. Чөнки мондый тәртипләр ислам дине, шәригать законнары белән кертелгәннәр һәм якланганнар, хөкүмәт законнары белән дә ныгытылганнар.

Бәетләрнең авторлыгын билгеләгәндә, аларның бер әдәби үзенчәлегенә вакыйгаларның күпчелек очракларда беренче зат исеменнән сөйләнүенә игътибар итәргә кирәк. Бу алым хәтта һәлак булган кешеләр турындагы бәетләрдә дә саклана. Вакыйганы үлгән кеше исеменнән сөйләтү, бәетне чыгаручы үлгән кешенең әнисе яки якын кыз туганы булганда психологик яктан күбрәк аклана. Өлкән яшьтәге хатын-кызлар арасында бәет чыгаручылар һәм аларны оста итеп башкаручылар хәзерге вакытта да очрап тора. Бәетләрнең тууында һәм таралуында хатын-кыз авторлар әһәмиятле роль уйнаган.

Татарларда тагын бер төрле фольклор әсәрләрен “бәет” дип йөртәләр. Алар инде фаҗигале классик бәетләрдән **сатирик яки юмористик** эчтәлекләре белән аерылып торалар. Мондый бәетләр чынбарлыкны комик-эстетик мөнәсәбәт аша гәүдәләндерәләр, аерым тормыш күренешләрен стира һәм комизм принцибыннан чыгып бәя бирәләр.Мисал өчен «Уңмаган килен» «Сеңел белән түтәй», «Кашык бәете», «Шәрәф мулла», «Кәҗә бәете».

Бүгенге көндә бәетләрне өйрәнү, студентлар тарафыннан оештырылган фольклор практикасында җыелган материалларга нигезләнә. Ел саен югары уку йорты тарафыннан оештырылган студентларның фольклор практикасы барышында бик күп бәетләр язып алына.

Текстлардан күренгәнчә, бүгенге көндә бәетләрнең күпчелеге шәхси фаҗигагә нигезләнеп язылган. Шулай ук тарихи вакыйгаларга багышланган һәм сәяси сугышларны гәүдәләндергән бәетләр дә бар. Аларда Әфганстан һәм Чечня сугышларында вафат булган яшь солдат егетләр тасвирлана. Шулай ук хәрби хезмәт үтәү барышында фаҗигагә юлыккан егетләрнең язмышы сурәтләнә.

Хатын-кызларның авыр язмышын чагылдыручы, аналарның язмышын сурәтләүче бәетләр дә, ни кызганыч, елдан-ел арта бара. Бүгенге көндә татар хатын-кызларының җәмгыяттә үз урыннарын булдырулары турында әйтеп була, әмма хатын-кыз ни өчендер үз хокукларын әле дә тиешенчә яклый белми. Моңа мисал итеп «Хәдичә бәете»н китереп булыр иде. Ире кыйнавына түзә алмыйча 30 яшьлек Хәдичә үз-үзенә кул сала.

Шәхси фаҗигане сурәтләгән бәетләрне анализлау вакытсыз үлемнең сәбәпләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Беренче урында юл-транспорт һәлакәте фаҗигасе. Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләре сакланмау сәбәпле дә үләчеләр байтак. Сирәк булса да, буранда адашып, яки суга батып үлүчеләргә багышлап чыгарылган бәетләр дә очрый. Замана

бәетләре геройларның яшь үзенчәлегенә килгәндә, фаҗигагә очраучылар, күп очракта 30 яшькә дә җитмәгән яшьләр.

Сатирик бәетләргә килгәндә, алар җәмгыятьнең әхлак нормаларын саклый, гадәттән тыш яисә гайре табигый бер хәлгә карата коллективның тәнкыйди мөнәсәбәтен күрсәтә. Мондый иҗат гасырлар дәвамында яшәгән тотрыклы бер күмәклекнең, әйтик, бер авыл кешеләренең үтемле тәрбияви чарасы буларак урын алса, икенче бер очракларда бу төр бәетләр үзләре фаҗигале ситуацияләргә дә китерүе мөмкин. Кызганыч, бәетләрнең әлеге төре бик сирәк иҗат ителә, әмма ул бүгенге көндә дә яши. Норлат районы Колбай Мораса авылыннан Мингалимова Җәвидә Җәүдәт кызы (1946 елгы) «Жевачка бәете» иҗат иткән (Язып алучы − Киямова Ләйсән, Норлат районы Колбай Мораса авылы).

Билгеле бер жанр үрнәкләренең поэтикасын ачыклау асылда әлеге жанрның үзенчәлекләрен дә ачыклау дигән сүз. Жанрның һәм, гомумән, шул жанрга керүче әсәрнең поэтик системасы шактый катлаулы һәм күпкырлы. Алар арасында күчерелмә мәгънәгә нигезләнгән төрле троплар да, лексик сурәтләү чаралары һәм поэтик синтаксис фигуралары да, конфликт структурасы һәм сюжет-композиция элементлары да , художестволы вакыт һәм пространство факторлары да һәм, ниһаять, ритм һәм интонация берәмлекләре дә бар.

Барлык компонентларны да үзенә буйсындырып торган төп әйдәүче көч, әлбәттә, эчтәлек үзе. Традицион бәетләр фаҗигале вакыйга яки хәлгә халык мөнәсәбәте булып тора. Фаҗига компонентын, һичшиксез, аның әсәрдәге функциясе белән бәйләп карарга кирәк. Билгеле булганча, фаҗигале бәет һич тә гадәти тормыш кайгыларына багышланып чыкмый, димәк, ул теләсә нинди үлем-кайгы турында халыкка җиткерүне максат та итеп куймый. Менә шуңа күрә бәет структурасындагы фаҗига компоненты да, табигый, трагик-драматик характердагы вакыйга яки хәлне гәүдәләндерүгә кайтып кала һәм, шул турыда хәбәр итеп, замандашларында кызгану-тетрәнү хисләре уятуны максат итеп куя.

Болардан тыш бәетләрнең ике мөһим компоненты бар: башлам һәм бетем өлешләре. Алар әсәрнең эчке структурасыннан, ягъни тулы эчтәлегеннән чагыштырмача мөстәкыйль булулары белән аерылалар. Әмма алар, да эчке компонентлар кебек үк, әсәрдә оппозицион пар тәшкил итәләр (берсе бәетне башлый, икенчесе тәмамлый) һәм бәетнең гомуми структурасында зур роль уйный [Яхин, Бакиров 1979: 153].

Традицион башлам өлешендә, гадәттә вакыйганың елы (яки ае-көне) күрсәтелә, сүзнең кем-нәрсә турында баруы белдерелә. Яки «бисмиллаһи вә биллаһи» сүзләре белән башлану да мөһим булып тора. Мондый күренешләр борынгы кабер ташларында да очрый, димәк, алар еллар аша бәетләргә күчкән булуларына тагын бер мисал. [

Соңгы елларда традицион булмаган башламнар да бик күп. Ләкин аларда, нигездә, бәетнең багышламасы (кем-нәрсә турында сүз баруы)

саклана. Аерым алганда, алар геройны яки вакыйганы атау һәм тасвирлау белән башланып китәләр, я булмаса геройның эндәшү алымына корылалар.

Бетем өлешенең дә үз принциплары һәм үз традицион формулалары бар. Шулардан иң таралганы геройның саубуллашуы яки бәхилләшүе рәвешендә гәүдәләнә. Саубуллашу алымы шулай ук теләк белдерү, васыять әйтү формасын да алырга мөмкин.

Бәетләрнең эчтәлек катламына караган мөһим компонентын фаҗигале вакыйга дидек. Аларның яшәү һәм үлем фәлсәфәсе дини мотивларга үрелеп киткән. Бәетләрдәге фаҗигале язмыш турыдан-туры язмышка-тәкъдиргә бәйләп яктыртыла. Бу читен хәлләр Алладан дип әйтү еш күзәтелә.

Бәетләрнең эчтәлек структурасы, гомумән алганда, өч мөһим компоненттан тора: 1) фаҗига (фаҗигале вакыйга яки хәл); 2) фаҗигаләрнең нәтиҗәләре, нинди югалтуларга китерүе; 3) фаҗига тудыручыны һәм фаҗига сәбәпләрен социаль инкарь итү. Соңгысы ике төрле – эмоциональ һәм көч белән инкарь итү формаларында гәүдәләнә.

Бәетләрнең зур өлеше шәхси фаҗигаләр белән бәйләнгән. Ә андый хәлләр, кызганычка каршы, әле анда, әле монда көн саен диярлек булып тора. Әнә шундый фаҗигаләр уңаеннан халык арасында күп санлы бәетләр иҗат ителә. Дөрес, аларның барысы да ниндидер әдәби кыйммәткә ия дип булмый. Бу төр бәетләр нигезендә жанрның прогрессив үсеше турында сөйләү кыен. Чөнки алар аерым гаиләләрдә үзешчән әдәби иҗат үрнәге булып, шул гаилә истәлеге буларак кына яшиләр. Аларның нинди дә булса да иҗтимагый, аеруча әдәби һәм тарихи әһәмияте хакында сөйләп булмый. Бары тик жанрның көчле традицияләре турында гына сүз алып барырга мөмкин. Халык зур ул, көчле ул, бай ул диясе генә кала. Дөньялыкта кеше ниләр күрми, бәетләрдә әнә шулар чагылыш таба.

Бәетләрдә халык иҗаты һәм язма әдәбият традицияләре берләшә. Аларның килеп чыгышы ягыннан әкият-мифология һәм героик эпос, халык лирикасы һәм язма әдәбият белән бәйле элементлары бар.Әгәр халык эпосы белән бәйле элементлар нигездә зур тарихи вакыйгаларга багышланган бәетләр өчен характерлы булса, халык лирикасы элементлары тормыш-көнкүреш бәетләрендә ешрак очрый.

Бәетләрнең стиле өчен күптөрлелек хас. Бүгенге көн бәетләрдә зур тарихи вакыйгаларны сурәтләгәндә кулланылган киң эпик тасвирлау да, фаҗигале хәлләрне чагылдырган киеренке драматик хикәя дә, авыр рухи кичерешләр хакында сөйләгән җитди лирик зарланулар да, кайгы-хәсрәт төсмерләрен эченә алган монолог та булуын күрдек.

Бүгенге көн бәетләренең торышы турында сүз алып барганда, халык арасында аларны иҗат итеп, туплап таратучылар турында әйтеп үтми булмый. Алар һәрбер җирлектә, авылларда булалар һәм үзләренең изге эшләре белән авылдашларын сөендереп торалар.

***Студентларга гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

1. Бәет жанрына билгеләмә бирергә, төркемчәләрен санарга, мисаллар белән дәлилләргә.
2. Үзегезнең төбәктә иҗат ителгән бәет текстларын язып алып килергә.
3. Җыелган бәетләрне укып, анализлап, тематик бүленешкә нигезләнеп таблицалар тутырырга.
4. Соңгы елларда иҗат ителгән бәетләрнең поэтик үзенчәлекләрен чагыштырма планда тикшерергә (алдан бирелгән бәет текстлары нигезендә).
5. Мөнәҗәтләр, аларның тематик төркемчәләре.
6. Мөнәҗәтләрнең поэтик үзенчәлекләре.

***Укырга:***

***Төп әдәбият:***

1. Әхмәтова Ф., Надиров И., Ягъфәров Р.Татар халкының бәетләре һәм мөнәҗәтләре // Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. – Б. 5-22.

2. Бакиров М. Бәетләр / М.Бакиров // Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 262-299 б.

3. Башкурова-Садыйкова А.Х.Ислам һәм татар халык иҗаты / А.Башкурова-Садыйкова. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2005. – 232 б.

4. Урманче Ф. Бәетләр / Ф.Урманче. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. –Казан: Мәгариф, 2002.– 335 б. – Б. 166-171, 217-221,239-246, 265-271.

5. Урманчеев Ф. Халык авазы: Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар / Ф.Урманчеев. – Казан, 1974.

6. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты/ Х.Ярми. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1967.

***Өстәмә әдәбият:***

1. Бакиров М. Бәет эволюциясенә бер караш // Татар фольклоры жанрлары. — Казан, 1978. — Б. 51–69.

2. Надиров И. Бөек Ватан сугышы чорында халык иҗаты // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1959. – 1 чыгарылыш. – Б. 214-249.

3. Урманче Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: Основные проблемы изучения баитов/ Ф.Урманчеев. – Казань:Татар.кн. изд-во, 2002.

4. Хөснуллин К. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр / К.Хөснуллин.− Казан: Раннур, 2001.

***Фольклор әсәрләре текстлары:***

1. Татар халык иҗаты. Бәетләр (кереш мәкалә авторлары Ф.Әхмәтова, И.Надиров, Р.Ягъфәров). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983.

2. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.

3. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр (Төзүчесе Ф.Урманче). – Казан: Мәгариф, 2000.

## Соңгы еллардагы фольклор практикасы вакытында тупланган бәетләр:

## Фатыйма бәете

**Язып алучы**:
ФһСИ студенты Илсинә Фазлыева,
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе районы 2010 ел

Әнкәй, сиңа рәхмәт инде,
Гел үзеңне акладың,
Сандыктагы малларыңны
Нәзирәгә сакладың.

Рыбныйга дип чыгып киттем
Ике капчык йон асып.
Үләселәрем килмәде
Үтерде машина басып.
Бер аягым киенүле,
Берсендә оек иде,
Шул үләсем көннәремдә
Күңелем боек иде.
Туганнарым җыелырлар
Каберемне казырга.
Ике балам ялгыз калды,
Калдырмагыз ялгыз ла.
Үле сөягем кайткан чакта
Күтәрелде давыллар.
Балаларым ятим калды;
Онытмагыз туганнар!
Авылымнан чыккан чакта
Күңелем берни сизмәде.
Рыбныйларда җаным чыкты,
Туганнарым күрмәде.
Иртән торып су китердем
Челтерәп аккан җиреннән.
Үле сөягем үтеп китте

Чәчегезне тарагыз, - дип
Инде кемнәр сүттерер,
Үгиләрне мин үстердем,
Минекен кемнәр үстерер.

Машина килеп бәргән чакта
Бик авыртты бит башым;
Караңгы гүр, тар ләхеттә
Ята бит ялгыз башым.
Капкаларны ачу белән
Күтәрелде җеназам,
Дөнья шулай була икән...
Калды бит ике балам...
Кибетләрдән лента алдым
Балам чәчен үрергә,
Бик күп балчыклар каплады –
Булмый сезне күрергә.
Ике толымлы итеп
Чәчегезне үрмәдем.
Сезне үстереп җиткереп
Рәхәтегезне күрмәдем.
Киемнәрем бик күп иде
Балам кисен, кимәгез;
Төрле вакытлар булгандыр –
Начар иде димәгез.
Рыбныйга дип киткән чакта
Аш булмады ашларым.
Яшьли гүргә барып керде

Туган, үскән җиремнән.
Унбер елны эшләп йөрдем
Укмас басуларында.
Исән киттем, үле кайттым
Актык кайтуларымда.

Минем газиз башларым.
Туган авылым, су буйларым,
Сау булыгыз, киттем мәңгегә!
Хуш, туганнар! Сау Булыгыз!
Онытмагыз мине мәңгегә!

**Сәлимә апа бәете**

**Язып алучы**:
ФһСИ студенты Илсинә Фазлыева,
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе районы 2010 ел

Без кисәсе урманнарда үсә диләр ак каен
Үлсәм үләм шаһит китәм, кала ялгыз апаем.

Биш фисметр кисәр өчен ашкына күңелләрем
Бигрәк кыска булган икән, дусларым, гомерләрем.

Мине агач басты, дуслар... Сез дә шулай булмагыз;
Сәлимә бәете әйтәм, колак салып тыңлагыз.

Сәлимә иртә белән әз ашады ашларын,
Каен дигән каты агыч ашады аның башларын.

Сәлимә, агач төшкәч, тезләнде ул тезенә,
Лимон сарылары иңде Сәлимәнең йөзенә.

Сәлимәнең өсләрендә чәчәкле күлмәкләре;
Газиз апасы ишетсә – өзелер үзәкләре.

Апам, керләремне усаң, агымсуда юарсың;
Минем күкләр уйнар, көләр – шул чакларда еларсың.

Авылдан чыккан чакта борылдык без чатларны
Апам, бәгърем, күрмәдең бит агач баскан чакларны.

Урманнарга барган чакта бәйләдем билләремне
Исән китеп, туганнарым, үлеп кайттым илемә.

Иптәшләрем еладылар минем янга тезелеп,
Минем апам көтеп тора үзәкләре өзелеп.

Авыз, борын эчләреннән акты минем каннарым;

Җомга көнне, сәгатҗ унда чыкты минем җаннарым.

Аклы ситсы күлмәгемне чөйдән чөйгә йөртмәгез
Кайтыр җиргә китмәдем, кайтыр диеп көтмәгез.

Апам, сиңа шул бүләгем – яшел ситсы күлмәгем;
Тшрбиялэп үстердең дә, рәхәтемне күрмәдең.

Өстемдәге куфайканы элеп куйдым чөйләргә;
Иптәшләрем кайтып китте минем хәлне сөйләргә.

Башларыма каен төшкәч акты минем каннарым;
Кайтасы көннәрдә генә чыкты минем җаннарым.

Ак Иделнең буйларын көймә белән буйладым;
Яшьтән гүргә керер өчен үскән икән буйларым.

Безнең урман уртасында үсә диләр туера;
Башымнан аккан каным куерганнан куера.

Атлар килә атлап-атлап, урман ташларын таптап;
И, дусларым, китәм инде якты дөньяны ташлап.

Аклы ситсы күлмәгемне кимәгән булыр идем,
Үләсемнәремне белгән булсам – килмәгән булыр идем.

Аклы ситсы күлмәгемә дегет салып куйганнар;
Минем зифа буйларымны ярып тегеп куйганнар.

Без ападан бишәү калдык – Вәсимә дә, Зәйнәп тә,
Нургазиз дә Зыятдин... Сәлимәнең ачык йөзе күренә идеерактан.

Апа, ыланнар күрмәдегез – алсу иде каннарым,
Бирсут урман эчендә чыкты минем җаннарым.

Эшкә чыгып барган чакта утырдым мин атларга;
Бер кеше дә кызганмады агач баскан чакларда.

И, апаем, соклandыңмы минем кара кашыма?
Миһербансыз иптәшләрем җитте минем башыма.

Агачларны кисмәс идем – сажиныбыз булмады;
Газиз җаным чыккан чакта апакаем булмады.

И, апаем, син күрдеңме минем аккан канымны?
Бер минут эчендә алды газраил җанымны.

Минем калган тарак белән чәчләреңне тарарсың,
Бик сагынган көннәреңдә каберемә карарсың.

Агач килеп төшү белән дусларым җыелдылар,
Атка алып салган чакта яшьләрем коелдылар.

Унҗиде яшькә җиткәндә әҗәл җитте безләргә;
Бер генә сүз дә әйтә алмадым и, дусларым, сезләргә.

Агач килеп төшкәндә күрмәде ике күзем.
Слабата больницасында кундым, апам, ялгызым.

Апам, минем каннарымны сабын белән юыгыз;
Төрле вакытлар булгандыр – риза, бәхил булыгыз.

Врачлар, прокурорлар мине карый калдылар;
И, апаем, син күрмәдең – өстән йозак салдылар.

Авылларны чыккан чакта борылдык без чатларны;
И, дусларым, онытмагыз бергә булган чакларны.

И, апаем, күрә алмадың минем кара кашымны;
Яшь башымны урман турап ашадым башларымны.

Урманнарга барган чакта, апаем, бик туңдым;
Урманны турап бетереп кайтыр көннәрдә үлдем.

И, туганнар! Сез юарсыз – каным күп күлмәгемдә;
И, апаем бик сагындым үләсе көннәремдә.

И, абыем, больницада тоттылар беләгемнән,
И, апаем, мәңгелеккә китәмен йөрәгеңнән.

Эшкә барган чакларымда каеш будым билемә;
Абый мине мәет итеп алып кайтты илемә.

И, апаем, үсеп җиттем, күрмәдегез туемны;
Гүр туфраклары каплады минем зифа буемны.

## Халисә бәете

**Информант:** Фәрдәния Шәфигуллина,1978 елгы
**Язып алучы:** ФhСИ студенты Алия Рәхмәтулина
Татарстан Республикасы
Тәтеш районы Олы Томы авылы, 2010 ел

Заманалар бик үзгәрде,
Укымыйлар гаетен.
Без язабыз,сез укыгыз,
Халисәнең бәетен.
Иртән торып чыгып киттем,
Мәктәбемә барырга.
Төшләремә дә кермәде
Юлда үлеп калырга.
Матур сумка сатып алдым
Алты сум чамасына.
Утырмаган булыр идем
Трактор чанасына.
Көндәгедән дә иртәрәк
Чыгып киттем ашкынып.
Чана кагылып китте дә,
Төшеп калдым атылып.
ин китүгә кош кычкырган
Шомлы авазын салып,
Мине дә алып кайтканнар.
Чанага сузып салып.
Үсеп җиткәч, ирешергә
Хыялларым зур иде.
Әнкәй,бәгърем,сабырлар ит,
Язмышларга түз инде.
Әнкәем,тагын кичләрен
Барча балаң җыелыр.
Арагызда мин булмагач,
Күз яшьләрең коелыр.
Дусларым мәктәпкә барыр
Тауның итәкләреннән.
Ачы үлем аерды бит
Мине иптәшләремнән.
Шундый язмыш булганга
Әнкәй,гафу итәрсең.
Дусларым гөлләр утырткан-
Мине шуңа тиңләрсең.

## Манара бәете

**Информант:**Рәхимова Рәсимә Гасыйм кызы, 1969 елгы
**Язып алучы**: ФhСИ студенты Киямова Ләйсән Илгиз кызы,
Нурлат районы Колбай Мораса авылы.

Әй, манара, исемеңне
Бигрәк матур кушканннар;
Әгәр телгә килгән булсаң,
Куркыр иде дошманнар.
Әй, манара, син утырдың
Ничә еллар нур булып;
Сине кисеп төшергәннәр
Йөределәр хур булып.
Әй, манара, үзеңне кем
Кискәнен бит белмәдең;

Бер ходадан әмер булып,
Нигә телгә килмәдең.
Әй, манара, син утырдың
Яман халык җыелгандыр,
Бар да мәчет сүтәләр,
Мәчетләрдә фәрештәләр

Мөэминнәргә билгегә;
Сине кисеп төшергәннәр
Хур булдылар мәңгегә
Әй, манара, син булмагач
Яңгыр яумый күкерәп;
Сине кисеп төшергәндә
Җирләр торды тетерәп.
Әй, манара, таң тугач та,
Азан тавышы көттек без;
Азан тавышы ишетмәгәч,
Мәхрүм булып беттек без.
Әй, мәчетем, әй манарам,
Сагына сине мөэминнәр,
Уку да юк, намаз да юк
Зәгыйфьләнде адәмнәр.
Манараны кисәбез дип,
Күп халыклар килделәр;
Фәрештәләр саф- саф булып
Җир йөзенә иңделәр.
Әй, мөэминнәр,барчагыз да
«Вәлгасыр»ны укыгыз.
Манара әйтә, авам- авам,
Кисәләр бит тотыгыз!
Бар да тәсбих әйтәләр.
Мәчет әйтә: «Әй, халыклар,
Мине ашыгып сүтмәгез;
Минем яннан үткән чакта
Дога кылмый китмәгез!»
Әй, манара, ай урагың,
Каршы икән кыйблага;
Ничә еллар әйттек синдә
Зәкер тәсбих Аллага.

* * *

Әй, манарам , күтәрелдең,
Күрде сине мөэминнәр;
Йөрик анда, кылыйк гамәл –
Сафлансыннар күңелләр.
Әй,манара, сине күреп
Шатланабыз без бүген;
Чөнки синдә гает укый,
Барча мөэминнәр бүген.
Иман белән сугарылган
Нигезеңнең һәр ташы
Нурлы аең иман чәчсен,
Күкләргә ашсын башы.

## РАФИКЪ БӘЕТЕ

**Бәет авторы**: Альберт Габдрахманов
**Язып алучы**: ФһСИ студенты
Илмира Шәйхетдинова,
Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, 2010 ел

Галләмов Рафикъ Исмәгыйль чокырында буранлы көндә адашып үлгән. Безнең арабыздан яшьли киткән егет икенче авылдашыбыз, Рафикның туганнан туган энесе Габдрахманов Альберт аның истәлегенә бәет чыгара. Ул бу бәетне 1976 елда армия сафларында хезмәт иткәндә яза. Бу бәет халык кулына 1987 елда эләгә һәм әле дә булса халык күңелендә саклана.

Салкын кышлар узып, яз житәрәк
Февраль ае узып китәрәк.
Авыр кайгы төште күңелләргә,
Йөрәкләребезне телгәләп.
Кичен кояш күмелеп баеганда,
Һаман килеп-килеп тешләде.
Шул ярларны узам-узам диеп,
Каршылады салкын төннәрне.
Салкын буран һаман күмә торды,
Алга таба барыр юлларны.
Ярдан менәм диеп тырыша-

Ыңгырашты буран кырларда.
Бу бәетне язам яшьләй үлгән
Авылдашым Рафикъ турында.
Кар-бураннан юлны ярам диеп,
Тракторга утырып юл чыкты.
Салкын буран җиңде тимер атны,
Кинәт сүнде аның маторы.
Кабинадан чыккач салкын буран,
Аяк-кулны бик тиз туңдырды.
Кайту кирәк иде кире диеп,
Ул авылга таба борылды.
Көчле буран, һаман кубарылып,
Атлар юлны күмеп ташлады.
Күзен ачып карый алмады ул
Авыл табан төшкән юлларны.
Кайтыр юллар ерак тоелдылар,
Барыр юлны буран каплады.
Ах, югалттым килгән юлымны дип,
Ул сукмактан читкә атлады.
Атлады ул иркен басу буйлап,
Калтыранды туңып куллары.
Адаштырды аны шул буранда
Кишәңгернең басу юллары.
Җитәм инде, җитәм инде дигән кебек
Ул ашкынып алга атлады.
Тик каршында җәелеп ята иде,
Кишәңгердә Исмәгыйль яры.
Салкын буран барыбер җиңәм дип,
Аны тирән ярга атлатты.
Түбән төшкәч, тирән тоелдылар
Кишәңгернең тирән ярлары.
Бит алмасын салкын буран җиле,
тырыша
Арды аның аяк-куллары.
Менә алмам микән ярны диеп,
Югарыга таба сузылды.
Узалмады тирән ярның төбен,
Кискән нарат кебек егылды.
Шул чак туңган аяк-кулларымны
Ял иттерим диеп утырды.
Утыргач та гәүдәм оер диеп,
Һич кенә дә уйлый алмады.
Тырышса да, кире басам диеп,
Тыңламады аяк-куллары.
Күкрәк тутырып сулыш ала алмады,
Буылдылар сулыш юллары.
Кайнар җаны салкын гәүдәсеннән
Калдырырга аны ашыкты.
Соңгы тапкыр зәңгәр күкне күрде,
Һәм туктады йөрәк тибеше.
Сүнде ялкын, өзелде бер чәчәк
Кышкы төннең таңы атканда.
Бер яшь йөрәк өзелеп җанын бирде,
Кишәңгернең тирән ярында.
Таңнар атты, үле гәүдәң синең
Ятты хәрәкәтсез ярларда.
Өсләреңнән буран улап узды,
Теләп сине каплап узарга.
Ник кайтмый соң, кайда балам диеп,
Газиз әнкәң көтте тилмереп.
Өзгәләнде аның өзелеп күңеле,
Җаның чыккан чакта өзелеп.
Минем балам кайда, белмисезме?
Диеп өзелде ул көннәрне.
Сизде ана кайнар йөрәгеннән,

Өзелгәнен алсу гөленең.
Үле гәүдәң синең туңган иде
Хәрәкәтсез иде күзләрең.
Җылы өйгә алып кайткачтын да,
Елмаймады көләч йөзләрең.
Шашкан диңгез кебек газиз ана,
Туңган йөзләреңә үрелде.
Туңган кулларыңнан үбә-үбә,
Сине дәштерергә теләде.
Килде аның йөрәк җылысын биреп,
Синең күңелеңне җылытасы.
«Ник дәшмисең газиз балам?»– диеп,
Салкын гәүдәңне ул саклады.
Кайнар битен куеп битләреңә,
Сине җылытырга теләде.
Син дәшмәгәч, шашкан моңлы ана,
Үле икәнеңне аңлады.
Шашып өзгәләнде горур ана,
Күңелләре яшькә төрелде.
Ник соң иртә киттең дөньядан дип,
Бөтен туганнарың өзелде.
Бик күп яшьләр акты күңелләрдән,
Синең яшьлегеңне кызганып.
Ак кәфенгә төреп салгач та син,
Яттың хәрәкәтсез сузылып.
Сине соңгы юлга озатырга дип,
Җыелдылар туган, дусларың.
Сине мәет диеп атаганда,
Елаштылар якын дусларың.
Капкаларны иркен ачып куеп,
Күтәрделәр сине иңнәргә.
Үле килеш сине теләмәде,
Озатырга йомшак җилләр дә.
Сиңа таба сузды кулларын.
Шул чак өзгәләнде, шашты йөрәк,
Күреп туганнарың моң-зарын.
Чал кояшлы якты бу дөньядан,
Инде соңгы тапкыр узасың.
Акрын җил дә авыр шаулап куйды,
Зиратның авыр таллары.
Ник соң иртә сүндең икән Рафикъ
Көтмәенчә якты язларны.
Туңлы җирне балта белән чокып,
Казыдылар сиңа каберне.
Гомерлеккә шунда калды диеп,
Авыр тойгы өзде күңелне.
Салкын икән кабер, һәм караңгы,
Ләхетләре булды тарырак.
Калдырганда сине шунда салып,
Күңел өзгәләнде калтырап.
Авыр туфрак басып кабер өстен,
Капландылар кояш нурлары.
Гомерлеккә сине калдырдылар,
Кыйблага салып башыңны.
Тыныч йокла, Рафикъ, тыныч йокла,
Җиңел булсын авыр туфрагың.
Җылы өең булып калды хәзер,
Зираттагы моңсу каберең.
Якты язлар җиткәч, яфрак ярып
Кабереңдәге таллар җилфердәр.
Яткан урыныңнан эзли-эзли,

Минем балам, калдырыгыз диеп,
Өзгәләнде газиз әнкәең.
Ник тиясез минем балама дип,
Туганнарың сине көтәрләр.
Онытылмассың һич тә күңелләрдән,
Яшьләй өзелдең бит гүзәл гөл.
Җаның ятып калды тирән ярлар,
Хәтерләтеп торыр сине гел.
Шушы ярларның сусаганда,
Ятып эчтең суларын.
Исмәгыйль чокырларында
Чыкты синең җаннарың.

Нигә тирән булды икән,
Кишәңгер чокырлары?
Яшьләй җаныңны өшетте,
Шуның салкын җилләре.
Газиз әнкәй эзләгәндер,
Шушы ярдан узганда
Сине сагынып яше агар,
Челтерәп суы акканда.
Бу бәетне укыганда,
Моңланыр шат күңелегез.
Бигрәк авыр була икән,
Яшьләй сынса гөлегез.

## АЗАТ БӘЕТЕ

**Бәет авторы**: Гөлнур Зарипова
**Язып алучы**: ФһСИ студенты Илмира Шәйхетдинова,
Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, 2010 ел

Бакчаларга чәчәр идем,
Бәхет бакчада үсми.
Иркә үскән балаларның,
Бәхете буламыни?
Сигезенче бала булып,
Дөньяларга килдем мин.
Яраткан малаем дип,
Кадерләп үстердең син.
Карап үстергән малаең,
Гомере кыска булган.
Каргаган бөтен каргышың,
Минем башларга булган.
Әни каргый күрмә башка,
Каргыш төшә икән ул.
Азапланып җан бирә алмау,
Үзәкне өзә лә ул.
Әни, сине гаепләмим,
Ачу килгәч каргаган.
Мине болай ятар диеп,
Төшкән,– диде– каргышың».
Мине күргәч елый идең,
Аңлап үзең ялгышың.
Кара әле, әни, бәгърем,
Абыйларым, апалар.
Мин шушылай китеп баргач,
Алар мине аңларлар.
Абыйларым, апаларым,
Болай була күрмәгез.
Газиз балаларыгызны,
Миндәй рәнҗетмәгез.
Каргама син, әни бәгърем,
Синнән үтенеп сорыйм.
Унтугыз яшь вакытымнан,
Тар каберләрдә черим.
Үлүләре бигрәк авыр,
Дусларым, туганнарым.
Сигез балаң арасында,
Ризыксыз бала булдым.

Уйлап та карамаган.
Күремчеләргә дә йөрдек,
Больнисларга да кердек.
Миңа каргыш төшкәнлекне,
Күремче аша белдек.
«Иң яраткан балаңа

Күзләреңә карап саубуллаштым,
каргышны.
Бик күп җирләргә йөреттең,
Үзгәртеп булмый шул язмышны.
Түзә алмагач минем сыкрануга,
Алып бардың больницага.

Яшьле күзләремнән күрмәдең.
Башкаларга теләгән каргышың,
Миңа төшәр дип белмәдем.
Бик борчылдың, бик күп яшьләр түктең,
Алып булмый төшкән
Үлем килүләрен көтә-көтә,
Була яздым чистый дивана.
Больниц бусагасы биек-биек,
Аяксыз менү авыр.
Мин кала дип өметләнмә,
Җанымны басты тамыр.
Минем белән больницада,
Бик күп көннәр кичердең.
Больница кушеткасында,
Елый-елый тилмердең.
Кушеткалары бик тар,
Мендәре дә булмады.
Әни, синең күзләреңә,
Йокы заты кермәде.
Син газап чиккәнне күргәч,
Йөрәкләрем калтырый.
Мин авыртуны каратып,
Ходай сине газаплый.
Бик карадың мине әни,
Соңгы сулышка кадәр.
Авырый күрмә, кайгы күрмә,
Соңгы көнеңә кадәр.
Әни нигә тапкансың,
Ходай ник яраткандыр?
Абау, аллам, бу авырту,

Егерме дә тулмады.
Унтугыз яшемдә үк,
Газраил очрады.
Газаплады Газраил
Башта аягым алды.
Аннан эчемне ярдырып,
Ярты җанымны алды.
Газаплады, өзгәләде,
Йөрәк бәгырьләремне.
Кабат-кабат больницада,
Йөртте йөрәккәемне.
Нигә газаплады икән,
Җаннарым алыр булгач.
Алды соңгы сулышымны,
Ел ярым газаплагач.
Ходай сиздергәнме миңа
Уналтыда өйләндем.
Зинһар, гафу ит, бәгърем,
Ялгыз каласың белмәдем.
Безнең кебек бу дөньяда
Яратканнар бар микән?
Сиңа миннән, миңа синнән
Аерылырга язган икән.
Синең белән бергә чакта
Мин бик бәхетле идем.
Күз яшьләрең сөртә-сөртә,
“Бәгърем”,- дия идең.
Бик яраттың син дә мине,
Күрә идем бәгърем.
Миңа күрсәтмичә елап,
Кызара иде күзең.
Кара күзләреңдә күз яшьләре,

Кабергә дә барадыр.
Аллам нигә алдың икән,
Рәхәт күрер көннәрем?
Ник ходаем җәлләмичә,
Газаплап үтерәсең?
Гомерем кыска булды,
Тама иде йокы күрмичә.
Үлеп китәм, гафу ит, бәгърем,
Сезне бәхетле дә итмичә.
Мин бәхетсез иттем инде,
Калды газиз балам да.

Бик яраттым бит мин аны,
Тәмле иде балдан да.
Балам, бәгърем, җәйгә чыккач,
Каберемә килерсең.
Әниең белән бергә,
Чәчәкләргә күмерсең.
Мин сине көтәрмен балам,
Зират киртәләрендә.
Башларыңнан иркәләрмен,
Һәрбер иртәләреңдә.

Сулыш йөрер юлларымны,
Кара тамыр чорнады.
Минем бәхет юлларымны,
Кара болыт каплады.
Мин китәм бит, бик елама,
Бәгърем ялгыз каласың.
Бергә чакларны сагынсаң,
Балабызга карарсың.

## Бәрәңге бәете

**Информант:**
Мингалимова Җәвидә Җәүдәт кызы,1946 елгы,
**Язып алучы**: ФһСИ студенты
Киямова Ләйсән Илгиз кызы
Нурлат районы Колбай Мораса  авылы 2011

Башымны да кыралар,
Койрыктан да кыралар.
Бер умачлык оннары юк
Миңа ышанып торалар.
Иртә дә мин, кич тә мин,
Казанда мин, мичтә мин,
Бу хурлыкка  түзә алмам –
Асылынам кичкә мин.
Болай мыскыллап торсагыз,
Сезнең белән тормыймын.
Барганда алып барырмын,
Кайтканда ышандырмыйм. Үпкәләмәс идем әле
Тәртипсез тотмасагыз.
Мин ачтан үтермәгәнне
Ярар онытмасагыз.

Тарих, йә әйт әле
Шушы бәрәңгегә ни дисең.
Ачлыкны җиңә алдың, батыр диеп
Куяр идем сиңа зур исем.
Көзен кырда калган, туңган бәрәңгенең
Язын крахмалын ташыдык.
Кем әйтмешли, шуңардан да
Тәмле кабартма пешереп ашадык.
Халык белән авырлыклар күрдең
Халык дөрес диеп санаса.
Орден – медаль бирер идем бәрәңгегә,
Валлаһи,бирергә яраса.

**Жевачка бәете**
**(сатирик бәет)**

**Информант:**
Мингалимова Җәвидә Җәүдәт кызы,1946 елгы,
**Язып алучы**: ФһСИ студенты
Киямова Ләйсән Илгиз кызы
Нурлат районы Колбай Мораса авылы 2011

Языйм әле, языйм әле
Жевачка бәетләрен.
Хайван кебек сагыз чәйни
Кешенең ахмаклары.
Алты айга бер килен-малай
Хезмәт хакы алганнар.
Бер тартма сагыз алырга
Кибеткә дип барганнар.
Барганнар дим,валлаһи дим,
Тәки шуны алганнар.
Әй чәйниләр оныкларым
Берсеннән –берсе узып.
Берсе суалчаннар ясый
Авызыннан алып сузып,
Берсе авызын бүлтәйтеп,
Шар чыгара һавага.
Шул сагыз имеш кешене
Ясый икән дивана.
Автобуста табак битле
Чәйни абзый, апалар.
Базарда да шул сагызны
Күрдем сатып яталар.
Оныклар тиргәмим хәзер
Тиргим мин хөкүмәтне.
Нинди ахмак җитәкчеләр
Бар икән дим, шул хәтле.
Кече оныгым дисбем тартып
Ябыштырган чугына.
Лач-лоч сагыз чәйни бар да,
Җитми иде шул гына.
Кич җиткәндә анда сагыз,
Монда сагыз ябышкан.
Аптырадым,тинтерәдем
Шул бер табыштан.
Намаз укыйм диеп утырсам
Күлмәк чабуында да,
Намазлык почмагында да ,
Ыштан балагында да,
Юып карыйм,кырып карыйм,
Ябыша бара сагыз.
Нинди чара күреп була
Әйтегезче,тапсагыз,
Чәчне пеләш калдыра дим,
Сагыз чәйнәгән балага.
Икеле тоттыра дим,
Свердлауда сагыз чәйнәп.
Үлгән ди кырык бала.
Агитмасса җиңә алмый
Хет нәрсә әйтеп кара
Хөкүмәтне тиргим инде
Гаепле дим хөкүмәт,
Оныкларым туктамыйлар
Тәмле ахыры шул зәхмәт.
Хөкүмәткә җибәрегез
Срочно телеграмм:
Әллә берегез башында да
Акыл юкмы бер грамм.
Сагыз алып,сагыз сатып

Кайсы хөкүмәт байый?!
Акылыгыз булса, уйлагыз
Сагыз нәрсәгә ярый,

Җитәкчеләр,депутатлар
Нәрсә карап торасыз
Зиһен бетә,акыл йотыла
Нигә авыз ерасыз.
.Кәтигәричне сүгәмен,
Туктатыгыз чәерне.
Китап укып,тырышып эшләп
Үсү илгә хәерле.

**Кайгы бетми**

**Информант:** Турушев Рашид Абдульмучин улы
**Язып алучы:** ТДСПА студенты Аллабердеева Нелли Йосыф кызы
Түмән өлкәсе, Вагай районы, Вершинский авылы, 2008 ел.

Чичнә якларыннан иртә-кичен,
Әни кеше көтә баласын.
Кем уйлаган әти-әнисенең,
Җан баласыз ятып каласын.
Әнә, тимер сандык эчләрендә
Кайтып килде синең җан балаң.
Ул күзләрен инде бер дә ачмас
Әнием, сагындым, диеп тә кочмас.
Көннәр, еллар үтеп китсәләр дә
Кайгы бетми, яши йөрәктә.
Инде әйтүче дә булмас ахры,
Синең улың, диеп, еракта.
Агытбашның якын зиратында
Йомшак урын булды кабере.
Каен башында яз кошлары
Сайрар, сүнмәсен, дип, кадере.
Җанга авыр япь-яшь балаларның
Вакытсыз лай сүнсә гомере.
Йөрәгендә саклар әти-әни
Сүнеп бетмәс аның кадере.

**«Бәетләр һәм мөнәҗәтләр» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. Татар халык бәетләрен өйрәнүнең тарихы.
2. Хатын-кызларның авыр язмышы тасвирланган бәетләрдә күтәрелгән проблемалар.
3. Соңгы елларда иҗат ителгән бәетләрнең тематикасы.
4. «Сак-Сок» бәете ,аның поэтикасы.
5. Сатирик бәетләргә хас төп үзенчәлекләр.
6. Мөнәҗәтләрнең Ислам дине белән бәйләнеше.
7. Мөнәҗәтләрнең поэтик үзенчәлекләре.

# ТЕМА № 10. АФОРИСТИК ЖАНРЛАР

Татар халык иҗатының ***мәкаль, әйтем*** һәм ***табышмак*** кебек төрләрен афористик жанрлар яки паремияләр дип йөртәләр. Афоризм – грек теленнән, «***aphorismos*** - әйтелгән сүз, әйтем» дигәннән алынган. Халык иҗаты жанрларыннан аермалы буларак, афоризмның авторы һәрвакыт билгеле була. Афоризм – билгеле бер автор, галим, язучы, философ, халык телендә - чичән тарафыннан кыска, соң дәрәҗәдә камил җөмлә белән әйтелгән, гаять тирән фикергә, барыннан да элек көтелмәгән эчтәлеккә ия булган сүзләр тезмәсе. Тирән бер фикерне көтелмәгәнчә матур, оста, үзенчәлекле итеп әйтү – афоризмның асылы.

Халык афоризмнары арасында һәм әдәби-эстетик кыйммәте буенча, һәм сан ягыннан төп урынны, һичшиксез, мәкальләр алып тора. ***Мәкаль*** атамасы безгә гарәп теленнән кергән. Аның мәгънәсе «сөйләү, әйтеп бирү» дигәнгә туры килә.

Н.Исәнбәт, мәкальләргә түбәндәге билгеләмә бирә: «Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә һәм дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре **мәкаль** дип әйтелә» [Исәнбәт, 1959: 16-17].

Н.Исәнбәт 1959, 1963, 1967 елларда үзенең күпьеллык эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак «Татар халык мәкальләре» җыентыкларын бастырып чыгара.

Татар халык мәкальләренең хосусый якларын ачыклаганнан соң, ул аларны өч зур төркемгә бүлә: 1) хезмәт һәм табигать дөньясы, аны тану, сынау, үзгәртү турындагы мәкальләр; 2) гаилә тормышы, тән тереклеге турындагы мәкальләр; 3) тарихи-иҗтимагый һәм рухи-әхлакый мәкальләр.

Мәкальләр – халык авыз иҗаты әсәрләренең кыска төре. Алар бик борынгы заманнардан бирле яшәп киләләр, телдән телгә күчеп таралалар һәм хәзерге вакытта да бик актив иҗат ителәләр. Мәкальләр күләме белән кыска, тирән мәгънәле, тәмамланган фикерне аңлата торган, рифмага салып әйтелгән җор сүзләр була. Алар халыкның күпьеллык тәҗрибәсе нигезендә, сыналган эшнең нәтиҗәсе буларак туалар.

Мәкальләр – халыкның күпьяклы тормышын, әхлакый карашларын, кешедәге уңай якларны һәм тискәре сыйфатларны сәнгатьчә сурәтли торган кыска әсәрләр. Халык үзенең мәкальләрендә тормыштагы җитешсезлекләрне, яраксыз күренешләрне аяусыз тәнкыйтьли.

Мәкальләр сурәтләү чараларына бай, аларда фикер тасвирлап бирелү сәбәпле, кешегә бик үтемле, көчле тәэсир итүчән була: «Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың»мәкалендә фикер читләтеп әйтелә.

Фольлорчы галимнәр мәкальләрне төрлечә төркемли. Н.Исәнбәт һәм Хуҗиәхмәт Мәмүтовлар мәкальләрне тематикалары һәм нинди

төшенчәдәнясалуларына карап төркемләсәләр, Альберт Яхин аларны функциональ үзенчәлекләренә һәм хөкем-текст төзелешенә карап төркемли. Мәкальләрне тематик төркемләү уңайлырак, нигездә мәкальләр тупланган җыентыклар да шушы принципта төзелә. М.Бакиров мәкальләрне түбәндәгечә төркемләргә тәкъдим итә:

1. Ил, халык, Ватан.
2. Мәмләкәт һәм идарә.
3. Тарих һәм заман.
4. Эш-хезмәт һәм ял.
5. Мал-мөлкәт.
6. Әдәп-әхлак.
7. Гаилә һәм туганлык.
8. Әдәбият һәм сәнгать.
9. Фән-белем.

Мәкальләр белән бер үк җыентыкларды әйтемнәр дә урын ала. Алар мәкальләр белән бик охшаш. Х.Мәхмүтов: «мәкаль шикелле үк, әйтемгә дә текстның тотрыклы булуы хас, ул да сөйләмне сәнгатьчә бизәү, аның эмоциональ көчен арттыру өчен хезмәт итә» [Мәхмүтов, 1987:27]. Тик әйтемнәрдә мәкальләрдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә чыгару әйтемдә булмый. Н.Исәнбәт моны; «Мәкаль булса, иң элек ул гомуми бер хөкем, уртак төшенчә була, әйтем булса, ул хосусый бер нәрсәнең билгеле бер ягын гына әйтү була»[Исәнбәт, 1987:27]. Мәкальләр белән чагыштырганда, әйтемнәрнең формасы, күләме дә, димәк, вазифалары да гадирәк. Күп очракта алар бер кыска җөмләдән торалар. Алар тел бизәге буларак, кемнең дә булса сүзен-фикерен көчәйтеп җибәрү өчен кулланылалар. Әйтемнәр, гадәттә мәкальләр кебек үк тематик принципка нигезләнеп төркемләнәләр һәм җыентыкларда да шул рәвешле урын алалар.

Табышмак ул – предмет яки күренешне читләтеп, кинаяле итеп сурәтләүгә корылган һәм тыңлаучыдан шуның нәрсә булуын эзләүгә исәп ителгән образлы гыйбарә яки башваткыч. Табышмак бер әйбернең исемен алмаш исем белән атаучы, яки атамыйча бу әйбернең сыйфатларын санап, тасвирлап бирүче поэтик әсәр. «Табышмак» сүзе «тап», «табу» сүзеннән ясалган. Аның «йомак» дигән атамасы да бар.

Табышмаклар ике өлештән тора. Беренчесе нәсәнедер сурәтли яки сорау бирә, икенчесеаның җавабын белдерә. Табышмакларны метафорик, сорау һәм арифметик дигән төрләргә бүлеп карыйлар.

Эчтәлекләре, нәрсәне гәүдәләндерүләренә карап, табышмакларны М.Бакиров түбәндәге төркемчәләргә бүлеп карарга тәкъдим итә:

1) кеше, аның эшчәнлеге һәм көндәлек тормышы;
2) табигать дөньясы;
3) материаль культура предметлары һәм төшенчәләре;
4) рухи культура предметлары һәм төшенчәләре;

5) галәм,аның объектлары һәм күренешләре

Табышмаклар көндәлек тормышта актив кулланылмасалар да, аларны бүгенге көндә мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларны логик һәм поэтик фикерләргә өйрәткәндә, аларның тапкырлыгын, зирәклеген үстерүдә мөһим бер алым буларак файдаланырга мөмкин.

***Гамәли дәрескә әзерләнү өчен сораулык:***

1. Канатлы сүзләр. Аларның чыганагы, төп үзенчәлеге. Тукай шигырьләрендә канатлы сүзләр.
2. Сынамышлар. Барлыкка килүе, функциясе, эчтәлеге. Сынамышларның тел-стиль үзенчәлеге. Аларның көнкүрештә, хуҗалык эшләрендә ориентир ролен үтәве. Килеп чыгышына карашлар.
3. Ышанулар (юраулар). Аларның төп вазифасы. Ышану-юрауларның мифологик-мистик карашларга нигезләнүе. Юрауларның эчтәлеге.
4. Алкышлар (изге теләкләр). Аларның төп эчтәлеге, тематикасы. Төп үзенчәлеге. Алкышларның төп вазифасы.
5. Каргышлар. Аларның төп вазифасы. Кайбер каргышларның нигезен билгеле бер вакыйга, легенда тәшкил итүе.
6. Им-том сүзләре, ырымнар. К.Насыйри хезмәтләрендә аларның афористик жанрлар арасында аерым төркем итеп күрсәтелүе. Функцияләре.
7. Антлар. Төп вазифалары. Борынгы нигезләре.
8. Әзер җаваплар һәм җор сүзләр. Аларның тапкыр сүзле кешеләр телендә очравы. Төп үзенчәлеге. Төзелеше.

*Укырга:*

*Төп әдәбият:*

1. Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында / Татар халык мәкальләре. Өч томда. 1 том. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1959.
2. Исәнбәт Н. Татар табышмаклары турында // Татар халык табышмаклары. – Казан: Тат.кит.нәшр, 1970. – Б. 7- 95.
3. Мәхмүтов Х. Ел тәүлеге – 12 ай (халык календаре битләреннән). – Казан: Тат. кит.нәшр., 1991.
4. Мәхмүтов Х. Татар халкының афористик иҗаты / Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. – Б. 5-36.
5. Мәхмүтов Х. Язылмаган кануннар (Фольклорда әдәп-әхлак мәсьәләләре). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995.
6. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. — Казан: Мәгариф, 2002.
7. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1967.

*Өстәмә әдәбият:*

1. Ярми Х. Мәкаль һәм әйтемнәр турында // Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1960 – Б. 3- 11.

2. Исәнбәт Н. Отканга – мәкаль, тапкырга – табышмак. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1973.

3. Мәхмүтов Х. Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVIII йөз төрки-татар ядкарьләрендә афоризмнар). — Казан, 2002.

*Фольклор әсәрләре текстлары:*

1. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр (кереш мәкалә авторы Х.Мәхмүтов) Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.

2. Татар халык мәкальләре (кереш мәкалә авторы һәм җыючысы, төзүчесе Нәкый Исәнбәт). Өч томда. - Казан: Тат.кит. нәшр., 2010.

3. Татар халык иҗаты: Хрестоматия (Төзүчеләре, кереш мәкалә, аңлатмалар һәм библиографик күрсәткечләрне әзерләүчеләр – Ф.Урманчеев, К.Миңнуллин). – Казан: Мәгариф, 2005.

4. Татар халык иҗаты. Табышмаклар (кереш мәкалә авторы Х.Мәхмүтов). Казан: Тат. кит. нәшр., 1977.

## Студентларның фольклор практикасы вакытында тупланган афористик жанр үрнәкләре:

- Уң цигәң кысса – мактайтылар, ә сул цигәң кысса – яманлайтылар.
- Кербегең оссон пулса, комерең кыска пула.
- Ике каш арасы ерак пулса, кыслар алыска кейәүгә цыгатылар, йегетләр ерактан алатылар.
- Куш еләк йэйсәң, игес пала табасың.
- Өстәлгә менеп ултырма – үсмәссен, кецкенә калырсың.
- Цайыңны түгеп эцсәң, кийәвең пур пулыр.
- Кецкенә авыслы кыс мактаулы пулаты.
- Пит кыцытса, яңкырга.
- Көске алтында еймә, матурлыгың йеп китерсең.
- Юлны кара мешәк киссә; ир кешенең алтына хатын-кыз кисә цыкса; юлында кугыз бәдрәле хатын-кызга оцрасаң – юл уңмайты.
- Кеше юлга цыкса, суңыннан су цацып калырга, кер юарга, итән себерергә, юарга, көл түгәргә ярамый.
- Юлга цыгар алдыннан тегенергә, цыккан юлдан берәй нимәңне онытып кире кайтырга ярамайты – юл уңышсыз була.
- Әгәр дә каршыңа сулы пәдрәле кеше очраса, яки өйдән цыгып кына берәй ир кешене күрсәң – юл хәерле була.
- Кәвек (күке) авыл өстеннән очканда, кычкырса, күңелсез хәл

була.

- Эт уласа – күңелсез хәл була.

**Мәкальләр һәм әйтемнәр**

- Пелем пеләккә көц пирәте.
- Пелем – йосак, ацкыцы – сорау.
- Пелем – пер сүс, пеләмен – ике сүс.
- Сүз сүздән таба.
- Алтын канат атаң бар, Көмеш садак анаң бар.
- Ата – беләк, ана – йөрәк.
- Яман бала өйгә сымас, өйдән чыкса, илгә сыймас.
- Бала яхшы булса – дәүләт, яман булса – имгәк.
- Эйелгәннең пашы цавылған.
- Кемнең кулынта – аның авысынта.
- Мөкрөнө қәбер генә турлайтыр.
- Төрөс сүс таш яра.
- Савыр пулған – моратына ирешә.
- Пөгөн аның урамынта пәйрәм.
- Алтыннан арты матур.
- Теләнцегә йел отро.
- Турәнең авысы қыйыш пулса та, сүсе туры.
- Цын тороп йыласаң, суғырның күсеннән тә йәш цығар.
- Қара йыланның қойроғына пассаң, қаты цағар.
- Эцең таса пулса та, аны йарып күрсәтерлек түгел.
- Тау пелән тау күрешалмайты.
- Ақ этнең пәләсе қара эткә.
- Алдынның астына түшәк йәймәйтеләр.
- Чукчаны алтын өйгә кергессәң тә пыцратырға өлгөрә.
- Алтынға та куак йәвешә.
- Теләгән йылан итен та ашар .
- Қыл яқшылық – көт йаманнык.
- Тус көйтөрөп әйтер, тошман көлтөрөп әйтер.
- Перәүнең йер күтәрмас қайваны пар, перәүнең ат күтәрмәс таны пар.
- Кешетән күреп сикергән – пашын сынтырган.
- Қысмәтнең тире ацы, йемеше татлы.
- Қышғы көн йәйне әйтәте, йәйге көн шайны әйтәте.
- Қыйра қайта – сүс анта.
- Пөтөн нимә пеләм тигән, пернимә эшләй пелмей.
- Кемнең сыйыры пар, аның сыйы пар.
- Қайта қурғак йуғалтаты, анта патыр табаты.

- Аш қәтерен ац пеләр, тун қәтерен йаланғац пеләр.
- Патыр яута күренер, курғак таута пеленер.
- Пүрене нейғәтәр ашантырма, ул пәребер төскә қарайты.

**Табышмаклар**

- Тау ишек төбөнтә пиш пәйләүле кол йатыр (себертке).
- Кечкенә генә бөкере, бөтен кырны бетерде (урак).
- Урамда урынсыз, кырда койрыксыз (җил)
- Павай ак көйләк кигән, пашы түвәгә тигән (мөец).
- Тей тисәң, теймәйте, теймә тисәң – тия (ирен).
- Аттан пиек, эттән түмән (ияр).
- Атасы аягын кигәнче, баласы урамга чыгып китә (ут, төтен).
- Кечкенә генә көчек, өрмәйте, капмайты, өйгә бушатмайты (йозак).

**Информантлар һәм язып алучылар:**
**ТДСПА студенты Краморова Диана Владимировна,**
**Төмән өлкәсе, Түбән Тәүде р-ны, Киндерле ав.**
**ТДСПА студенты Камалова Гузель,**
**Төмән өлкәсе, Төмәне р-ны с. Юрты Андреевские**
**ТДСПА студенты Хабибуллин Динар Наилевич**
**Төмән өлкәсе, Вагай р-ны Сөләйман ав.**
**ТДСПА студенты Сулейманова Маргарита Исхаковна,**
**Төмән өлкәсе, Тубыл р-ны Тахтагул ав.**
**ТДСПА студенты Сагидуллина Елена Юмалиевна**
**Төмән өлкәсе, Вагай р-ны Одинарские ав.**

**«Афористик жанрлар» темасы буенча тәкъдим ителә торган реферат һәм курс эше темалары**

1. Н.Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләр»өчтомлыгы.
2. Татар халык табышмакларының поэтикасы.
3. Халык мәкальләренең тәрбияви әһәмияте.
4. Татар фольклорында сынамышлар.
5. Алкышларның тематикасы, вазифалары.

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш.............................................................................................3
Тема № 1. Фольклор һәм аның үзенчәлекләре. Татар фольклористикасы тарихы.............................................................5
Тема № 2. Мифлар һәм ырымнар……………………………………33
Тема № 3. Йола фольклоры. Календарь йола иҗаты...........................57
Тема № 4. Эпос- дастаннары.................................................................76
Тема № 5. Татар халык әкиятләре.........................................................91
Тема № 6.Риваятьләр һәм легендалар.................................................137
Тема № 7. Мәзәкләр.............................................................................151
Тема № 8 Татар халык җырлары..........................................................158
Тема № 9. Татар халык бәетләре һәм мөнәҗәтләре............................173
Тема № 10. Афористик жанрлар……………………………………192

**САЙФУЛИНА ФЛЕРА САГИТОВНА**
**ЗАМАЛИЕВА ЛУИЗА ФИРДУСОВНА**

# УСТНОЕ НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

Учебно-методическое пособие

Лицензия на издательскую деятельность
ЛР № 040287 от 25 июля 1997 года

Отпечатано с оригинал-макета. Подписано в печать:
Усл. печ. лист 9,86. Формат 60х87. Заказ № Тираж 500 экз.

---

Отпечатано в типографии редакционно-издательского отдела
ТГСПА им. Д.И.Менделеева
626150, г. Тобольск, ул. Знаменского, 58